**ТИМЕР ЗАҺИТ**

# ДӨНЬЯ БИТ УЛ

**Казакъстан Республикасы**
**Алматы 2017 ел**

**ӘОЖ 821 (574)**
**КБЖ 84(5каз=тат)**
**Т 41**

**Т 41 Тимер Заһит.**
**Дөнья бит ул.-** Алматы: «Таугуль-Принт» нәшрияты, 2017 ел.- 492 бит.

ISBN 978-601-06-4338-3

«Дөнья бит ул» дип исемләнгән шушы китап - авторның байтак еллар дәвамында язылган шигъри әсәрләре җыентыгы. Алар Тимер Заһитның (Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллинның) 1997-2016 елларда басылып чыккан «Дусларымның уйлары һәм моңнары», «Сүзләрем сиңа кала», «Комда калган эзләр», «Татар дигән халык», «Гомер йомгагы», «Юлга чыктым», «Елларым минем, кайда сез?» исемендәге китапларыннан сайлап алынган.

Шигырьләр «Милләтем, бердәнберем», «Туган-үскән якларым», «Хәтер янчыгын актарганда», «Яшьлегем кайтавазы», «Киләчәккә хатлар», «Әйдә, дустым, җырлап җибәр», «Шаярып, көлеп кенә» дигән бүлекләрдә урнаштырылган. Шул ук бүлекләрдә «Газиз халкым- татарым», «Таһир бабай» поэмалары да бирелгән.

Алдынгы елларда басылып чыккан кайбер мәкаләләр «Шәхесләр» дигән аерым бүлектә урын алган. Мәкаләләр авторга якын таныш булган әдәбият әһелләренең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган.

Китап киң катлам укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Китапның эчтәлегенә карата фикерләрне griftim@mail.ru адресы буенча җибәрергә була.

**ӘОЖ 821 (574)**
**КБЖ 84(5каз=тат)**

**ISBN 978-601-06-4338-3**
© Тимер Заһит, 2017

*Рабит Батулла,*
*Татарстанның халык язучысы,*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

## ҖИРСҮ

(Тимер Заһитның «Татар дигән халык» исемле китабына кереш сүз)

«Татар дигән халык» исемле бу китапка Тимер Заһит тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр, мәкаләләр тупланган. Китап Казан каласының меңьеллыгына багышлана. Беренче өлештә Тимер Заһитның татар милләтенең узганы һәм бүгенгесе белән горурланып язылган әсәрләре булса, икенче кисәктә исә шигырьләрдә күтәрелгән мәсьәләмилләтебез мәсьәләсе алга куела; мәкаләләр авторның шигырьләрен шәрехләп бирә кебек. Тормыш тәҗрибәсе туплаган, тормышның ачысын-төчесен татыган Тимер Заһит (ул фәннәр докторы, профессор, атказанган укытучы) бер маузуг белән «авырый», ул милләтпәрвәрлек. Бу китабында да автор гел милләтебез, гел халкыбыз турында яза.

Татарстаннан еракта яшәп ятучы татар баласының рухын ерак аралар гына халкыннан аера алмый, ул халкы өчен яна-көя, бәргәләнә, сөенә, «хаталары» өчен көенә. Шушы ике хис аны каләмгә тотынырга мәҗбүр иткән. Тимер Заһит җирен, ватанын сагына һәм бу хисләр шагыйрь йөрәгенең тибеше булып, кулыбыздагы шушы һәм башка китапларга языла барган: «Сүзләрем сиңа кала»(2000), «История татар» (1998), «Комда калган эзләр» (2004).

Татарстанда яшәп тә үз милләтенең узганы, киләчәге турында уйлап та бакмаганнарга үрнәк итеп куярлык бер китапка ия Тимер Заһит!

*Казан, 2005 ел*

*Роберт Миңнуллин,*
*Татарстанның халык шагыйре,*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

## СӘЙЯР ҖАНЛЫ ГАЙЯРЬ ТАТАРЫБЫЗ
(Галим Гриф Хәйруллин язмышында милләтебез язмышы чагыла)

Татарлар, барыбызга да мәгълүм, яһүдиләрдән кала дөньядагы иң күчмә халыкларның берсе. Аларның иксез-чиксез Евразияне иңләгән бөек тарихы шул хакта сөйли. Бөек күченеш чорлары күптән ерак тарихта калган, инде акрын-акрын гына XXI гасырны да ваклап барабыз. Югыйсә, тынычланырга, утрак тормышка күнегергә да вакыттыр. Әмма, юк шул, сәйяр җанлы милләттәшләребездә әле һаман да шанлы-данлы чорларда дөньяны тетрәтеп яу чапкан, батырларча көрәшкән һәм җиңгән каһарман бабаларыбызның каны уйный, аларның күңелен һаман да яңа җирләр, яңа кыйтгалар тартып тора. Моның ачык бер мисалы – милләттәшебез Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллинның хәл-вакыйгалар, табышлар һәм югалтулар белән тулы гыйбрәтле дә, сокланырлык та язмышы. Бер караганда, болар барысы да Гриф Тимерзаһит улының беркемне дә кабатламаган үз гомере, үз яшәеше. Икенче караганда, бу язмыш – татарыбызга гына хас милләт язмышы да. Татарның сәйярлеге, тиктормаслыгы, тынгысызлыгы ерак тарихларга барып тоташа: патшалар заманында да шулай булган, совет чорында да шушы ук күренеш иде. Шушы вәзгыять әле дә дәвам итә. Бу – милләт фаҗигасымы? Әллә инде милләтне төрле кысрыклаулардан, төрле афәтләрдән коткарып калучы бер күренешме? Ул кадәресен кем белсен инде... Без моңа «татарлык» дип кенә бәя бирик. Грифны язмышы

шулай йөрткәнме, әллә инде совет системасы аркасында шулай килеп чыкканмы? Авылында гына калса ниләр булыр иде... Дөнья гизеп гомер кичерүләре акланганмы? Югалтулары күпме дә табышлары ни дәрәҗәдә?.. Болар хакында хәзер инде ул үзе дә еш уйланадыр, мөгаен. Әйдәгез, без дә күздән кичерик әле...

Гриф Тимерзаһит улы 1937 елны Башкортстанның Дүртөйле районында дөньяга килгән. Димәк, минем якташым була инде. Илеш белән Дүртөйле күршеләр генә. Без яшьрәк чакта икесе бер район булып та тордылар. Шунысы кызык, ул Башкортстанның Казакълар дигән авылында туган, бүген дә мөстәкыйль Казакълар Илендә яши. Шулай туры килүен кара әле син! Монда ниндидер бер мистика да бар шикелле. Әтисе Тимерзаһит Хәйрулла улы шул авылда колхоз оештыручыларның берсе булган. (Грифның бер китабында әтисенең фотосурәте бар. Ул аны 1944 елны Казан госпиталендә төшкән булган. Гимнастеркадан, зур кара күзләр, максатчан, яндырып ала торган караш, Буденныйныкы кебек куе мыек... Әкият батырларына гына хас сокланырлык кыяфәт, йөзеннән чибәрлек һәм гайрәт ташып тора... Исеме җисеменә туры килсә дә килер икән! Чыннан да, чын Тимер Заһит! Югыйсә, авыр яраланган, сугышта бер аягын югалткан солдат бит әле... Менә кемгә охшаган икән Гриф!) Бөек Ватан сугышы алдыннан ул Казакълардан өч чакрым ераклыктагы Яндыз авылы колхозында хисапчы (счетовод) булып эшли башлый. Әнкәсе Мәккә Вәлиәхмәт кызы – тугыз бала анасы. Кызганыч, ул балаларның бишесе генә үсеп җитә...

Грифның биографиясендә тагын бер кызыклы факт бар. Сугыштан яраланып кайткан Тимерзаһит абзыйны Миңеште авылына эшкә җибәрәләр. Гриф шунда укый башлый. 1951 елда Миңештенең җидееллык

авыл мәктәбен Мактау грамотасы белән тәмамлап, Бөре шәһәрендәге татар педагогика училищесына укырга керә. Ә Миңеште, үзегез беләсез, Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗминең туган авылы. (Нажар ага белән якын дуслар булганлыктан, шуңа күрә ул авылда элек тә, хәзер дә еш булырга туры килгәнлектән, Миңеште миңа да бик якын һәм кадерле! Хәер, шигырь сөюче татар белән башкортның бик күбесенә шулайдыр ул!). Димәк, Гриф бөек шагыйрьнең турыдан-туры авылдашы булып чыга. Сугыштан соң авылына еш кайтып йөргән, әтисе кебек үк фронтовик Хәбибнаҗар абыйсын әле аның күргәне дә булгандыр. Шагыйрь абыйсы малайның аркасыннан кагып та узгандыр. Аның шигъриятькә тартылуы да, шагыйрь булып китүе дә Миңеште туфрагыннан, Миңеште суыннандыр, мөгаен... Җитмәсә, янәшәдә генә, күз күреме ераклыкта гына атаклы Агыйдел агып ята. Өстәвенә, Агыйдел буйларына ямь өстәп, Н.Нәҗми шигырьләрендә еш кабатланган Кандаулы тау сузылган... Шушындый илаһи табигать кочагында үскәчтен, теләсәң-теләмәсәң дә, шагыйрь булырсың шул...

1955 елда Бөредәге училищены кызыл диплом белән тәмамлап, Гриф Байкыбаш (хәзерге Караидел) районындагы Тайкаш җидееллык мәктәбендә мөгаллимлек итә башлый. Бер елдан соң Бөредәге педагогика институтының физика-математика факультетына укырга керә. 1959-60 уку елында Бөре районының Иске Базан авылында укытучы була. Шул ук уку елында читтән торып институтның дүртенче-бишенче курсларын тәмамлый, бу юлы да кызыл диплом иясе була.

1960 елда язмыш аны көтмәгәндә генә Үзбәкстанның Ангрен шәһәренә илтеп ташлый. Биредә дә мәктәп укытучысы булып урнаша. Өйләнеп җибәрә, җәмәгате Әминә Сабит кызы белән ике ул, бер кыз үстерәләр. Уку-

га мөкиббән киткән, һәрвакыт белемгә омтылган Гриф 1963-66 елларда Тула шәһәрендә аспирантурада укый. Укуы беткәч, Ангренга яңадан кайта, мәктәп-интернат директоры, педагогика институтында кафедра мөдире, факультет деканы, урта мәктәп директоры булып эшли.

Тынгысыз җанлы Гриф 1976 елда гаиләсе белән Казагыстанга, Алма-Ата шәһәренә күченеп яши башлый. Монда эшләгән эшләре дә мәгариф белән бәйләнгән: урта мәктәптә завуч, директор, укучыларның хезмәт тәрбиясе һәм профориентация комбинаты директоры, район һәм шәһәр мәгариф бүлекләрендә инспектор...

Гриф Тимерзаһит улының тормыш юлы, беренче карашка, бик шома гына барган шикелле: бернинди каршылыкларсыз гына шәһәрдән-шәһәргә, эштән-эшкә, фатирдан-фатирга күчүләр... Юк шул, Грифны тормыш шактый или, кыйный, чыныктыра, утлардан алып, суларга сала. Күренекле, абруйлы галим булып өлгергәнче аңа бик күп киртәләр аша узарга туры килә. Бер генә гыйбрәтле мисал китерим. Аспирантура тәмамлаганнан соң ул математика буенча диссертация әзерли, аны Ташкент университетындагы кафедрага тәкъдим итә. Ни кызганыч, аның хезмәтен кире кагалар. Аннары ул Ташкент педагогика институтында башка темага өр-яңа диссертация язып яклый. Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, анысын Мәскәү кире бора... Башка берәү булса, барсына да кул селтәр иде, төшенкелеккә бирелер иде... Әгәр дә шулай булса, ул Гриф Хәйруллин да булмас иде шул!

Кандидатлык диссертациясен ул барыбер яклый, педагогика институтына укытучы булып эшкә урнаша, соңрак факультет деканы булып эшли. Докторлык диссертациясен яклап, педагогика фәннәре докторы, аннары професссор дәрәҗәсенә лаек була. Нәтиҗәдә, аңа докторлык буенча диссертацияләр советы рәисе ва-

зыйфасын ышанып тапшыралар, Казагыстанның Югары Аттестация Комитеты президиумы әгъзасы итеп тәгаенлиләр. Шулай ук ул Халыкара информатизация академиясенең һәм Халыкара акмеология фәннәре академиясенең академигы булып сайлана. Бүгенгесе көндә Гриф Тимерзаһит улы - Казакъ милли педагогика университеты профессоры. «Татарстанның атказанган укытучысы», «Үзбәкстанның мәгариф отличнигы», «Казагыстанның почетлы мәгариф хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәре дә бар аның. Медальләрен, Казагыстан Президенты тапшырган Мактау грамотасын, «Казагыстанда фәнне үстерүдәге казанышлары өчен» билгесен әйтеп тә тормыйм. Күрәсез, кайсы илдә, кайсы төбәктә яшәсә дә, намус белән эшләгән, хезмәтләрен күргәннәр, югары бәяләгәннәр...

Мин югарыда милләттәшебезнең төп хезмәте – галимлеге, мөгаллимлеге, мәгариф, педагогика өлкәсендәге ихлас эшчәнлеге турында кайбер сәхифәләрне барлап чыктым. Әлеге тырыш хезмәтләре, шуның өстенә матур кешелек сыйфатлары аны хезмәттәшләре алдында, җәмәгатьчелек алдында абруйлы, дәрәҗәле иткән. Бу – бик мөһим! Бу - Гриф Хәйруллинның үзенең генә абруе түгел, татар милләтенең дә дәрәҗәсен күтәрү дигән сүз...

Казаннан ерактарак яшәгән татарлар күпкә милләт җанлырак дигән хакыйкатькә мин торган саен ныграк ышана барам. Бу – чыннан да шулай! Моны Гриф мисалында да ачык күрергә мөмкин. Ә бит ул данлыклы университетка укырга керергә дип Казанга да килә. Тулай торакка урнаша алмаганлыктан, әлеге хыялдан баш тартырга туры килә. Казанда калган булса да, Гриф, әлбәттә, югалып калмас иде. Үзенең тырыш, максатчан холкы белән, һичшиксез, зур белгеч булып өлгерер иде. Ә менә милләтпәрвәр була алыр иде микән? Кистереп кенә әйтүе

кыен. Бүген исә ул милләтебезнең йөзек кашы булырлык, бар яктан да камил, иң кыйммәтлесе, «милләтем» дип җан атып яшәүче олуг шәхесебез. Милләткә хезмәт итү һәркемнән фидакарьлек, бирелгәнлек һәм ихласлык сорый. Кайчандыр университетына укырга керергә хыялланып та керә алмаган Казанына Гриф Хәйруллин 1992 елда татарның олы бер шәхесе булып, Казагыстандагы татарларның милли-мәдәни хәрәкәтендә җанытәне белән актив катнашучы буларак, Бөтендөнья татар конгрессының тарихи беренче съездына сайланган делегат сыйфатында килде. Шуннан бирле аның бер генә съездны да калдырганы юк шикелле. Конгресс эшендә ул һәрчак актив катнаша. Әле дә хәтеремдә, бөтендөнъя татарларының соңгы корылтаенда да Гриф Казагыстан делегатлары исеменнән ялкынлы чыгыш ясады. Иң эчтәлекле, иң эмоциональ чыгыш аныкы булды шикелле. Шактый шаблон, төссез сүзләрдән соң Грифның әйткәннәре делегатларны уятып, төгәлрәк итеп әйтсәк, тетрәндереп җибәрде. Калын кысалы күзлек артына яшеренгән янып торган үткен караш, шактый гына агаруына да карамастан, бөдрәләрен югалтмаган, дулкынланып торган калын чәчләр, матур тембрлы, гөрелдәп торган ышандырырлык калын тавыш! Иң мөһиме, акыллы, саллы һәм күңелләргә үтеп керерлек сүзләре белән ул залны әсир итте. Хәтта президиумдагылар да аның милләт язмышына кагылышлы эшлекле тәкъдимнәрен игътибар белән тыңлап, баш кага-кага куәтләп утырдылар. Зал аның чыгышын алкышларга күмде, президиумда утырган Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов, урыныннан торып, җылы сүзләре белән аның кулын кысты. Мин инде ул чакта эчемнән генә якташым өчен горурлык хисләре кичереп утырдым. «Күрдегезме безнең якташларны!» - дип, бергә утырган күршемә мактанып та ал-

дым бугай әле. Ул чакта съезд көннәренең каһарманына әверелгән иде безнең Грифыбыз...

Ә Грифның бөтен татарлар җыелган олуг мәҗлеснең биек мөнбәреннән сөйләрлеге дә бар. Чөнки ул башка фикердәшләре, хезмәттәшләре белән бергәләшеп татар өчен янып яши, Казагыстандагы татар тормышының уртасында кайный, татар өчен күрсәткән хезмәтләре җитәрлек, татарның проблемаларын белә, аңлый, шулар турында башкаларның күңелләренә сеңдерерлек итеп сөйли белә. Чөнки ул иҗат кешесе дә: үзешчән артист-җырчы да, нәшир-журналист та, публицист та, шагыйрь дә. Милләттәшләребез аны башта Алматы өлкәсенең татар-башкорт мәдәни үзәге рәисе итеп, аннары «Казагыстандагы татар һәм башкорт ассоциациясе» президенты итеп юкка гына сайламадылар. Әйтергә кирәк, бик тә абруйлы, шул ук вакытта җаваплы да вазыйфалар! Анда бит эшләргә, тир түгәргә кирәк; оештырырга, берләштерергә кирәк! Башкаларны тыңлата да белергә, үз артыңнан ияртә дә алырга кирәк! Ә аның өчен акыл, түземлек, сабырлык, кыскасы, талант кирәк! Әнә шундый талант бар Грифта. Ул бит әле ике дистә ел дәвамында Алматыда чыгып килгән «Фикер» («Фикер-Өмет») исемле татар басмаларының баш мөхәррире дә булган кеше. Соңгы елларда Казагыстанда татар телендә «Фикер» исемле яңа республика гәзите чыга башлады. Мин аны даими укып барам. Дөресен әйтим, бик зәвыклы, тирән фикерле, бай эчтәлекле җитди басма. Аннан үзеңә Казагыстанда яшәүче милләттәшләребез, аларның тормышлары турында бик күп кызыклы мәгълүматлар таба аласың. Чөнки, ни дисәң дә, әлеге газетаның да баш мөхәррире Гриф Хәйруллин.

Гриф Тимерзаһит улы һәрвакыт халык арасында, җәмәгатьчелекнең күз алдында: татарлар, башкорт-

лар белән дә, казакълар белән дә, үзенең студентлары, хезмәттәшләре белән дә даими аралашып тора, оештыра, гәзит чыгара, мәкаләләр яза, чыгышлар ясый... Басылып чыккан китапларының, басмаларының, мәкаләләренең саны гына да 250 дән артып киткән. Татар һәм башкорт халыкларының теленә, тарихына, мәдәниятенә багышланган «Татар теле дәресләре» (Алматы, 1996), «Татары» (соавторлыкта, Алматы, 1998), «История татар» (Алматы 1997, 2010, Саарбрюккен-Германия, 2012), «Традиционная культура татарского народа» (Алматы, 2000), «Очерки истории и культуры башкирского народа» (Астана, 2004) кебек китаплары аеруча игътибарга лаек.

Кыскасы, бик актив рәвештә һәм иҗтимагый, һәм гыйльми, һәм милли тормыш белән яши, ат кебек җигелеп эшли ул. Ләкин күңел дигән нечкә бер әйбер бар бит әле. Андагы изге, самими хисләрне теләсә кайда, теләсә кайсы вакытта, теләсә кем алдында чәчепсибеп йөреп булмый. Грифның бай күңеле дә шигырьгә генә сыя торган тойгылар, уй-кичерешләр белән тулы. Аларның күбесе «Дусларымның уйлары һәм моңнары» (Алматы, 1997), «Казанга хат» (Алматы,1998), «Кызык дөнья» (Алматы, 1999), «Сүзләрем сиңа кала» (Алматы, 2000), «Комда калган эзләр» (Алматы, 2004), «Татар дигән халык» (Казан, 2005), «Гомер йомгагы» (Алматы, 2009), «Юлга чыктым» (Алматы, 2012) исемле китапларда Тимер Заһит тәхәллүсе белән дөнья күрде. Мин аларның кайберләре турында ТНВ телеканалыннан үзем алып барган «Китап» тапшыруларында да сөйләгәнем булды. Аннары шунысы да кыйммәтле: алар бит Казаннан читтә, ерак Казагыстанның атаклы Алматы шәһәрендә басылып чыккан Татар Китаплары!

Милләтенә җаны-тәне белән бирелгән, туган җирен сагынып яшәүче, ярата белүче, ихлас күңелле шагыйрьнең

шигырьләре тупланган әлеге китапларда. Анда күңелләрне тетрәндерерлек мәхәббәт шигырьләре дә җитәрлек. Бигрәк тә бу фани дөньядан вакытсыз киткән хәләл җефете Әминәгә, шулай ук бик иртә киткән икенче мәхәббәте Фирдәвескә багышланганнары шундыйлардан. Сагына шагыйрь, сагына: сөекләләрен дә, туган авылын да, бала чакларын да, туганнарын да... «Юлга чыктым» китабының кереш сүзендә мондый юллар: «Китапның «Ата-бабам нигезе» дип аталган бүлеге татар халкының язмышына, аның телен һәм үзенчәлекле гореф-гадәтләрен саклау мәсьәләләренә багышланган... «Мин һаман гашыйк синә» бүлегендә саф мәхәббәт хисләре, аерылышу сагышы, яшьлекне сагыну тойгылары тасвирлана». Шигырьләрнең барысы да мөһаҗир шагыйрьнең уй-хисләре, үз укучысына, үз халкына, үз якыннарына чын күңелдән әйтергә теләгән ихлас сүзләре. Шул яклары белән кадерле дә алар безгә...

Гриф Тимерзаһит улы белән еш булмаса да очрашкалап торабыз. Алматыда да күрешкәнебез булды. Атаклы рәссамыбыз Камил Муллашевның өендә бергә кунак булган идек. Җае чыккан саен үзе дә Казанга килгәли. Уртак дустыбыз Илдус Тарханов Татарстанның Казагыстандагы илчесе булып эшләгән чагында миңа аталган кучтәнәчләрсез кайтмый иде. Алар әле дә якын дуслар! Илдус Габдрахман улы миңа аның сәламнәрен, изге теләкләрен һәрчак җиткереп бара. Гриф миңа үзенең яңа чыккан китапларын да җибәреп тора. Аларга, әлбәттә, автограф та язылган була. Мәсәлән, аның «Татар дигән халык» исемле китабына укытучыларга гына хас матур хәрефләр белән (педагогия училищесын тәмамлаганы әллә каян күренеп тора!) «*Кадерле якташым Роберт Миңнуллинга - зур ихтирам белән автор. 19.09.2004. Алматы.*» дип язып куелган. Рәхмәт аңа! Якташымның

ул китапларын мин кадерләп саклыйм. Аларны кулыма алган саен сәйяр җанлы якташым, дустым, фикердәшем, казакъ җирендә гомер кичерүче мәшһүр милләттәшем Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллинны искә төшерәм һәм эчемнән генә аңа озын гомерләр, сәламәтлек, җан тынычлыгы телим!

*«Кызыл таң» гәзите (Уфа),*
*№16(24870), 11.02.2016.*

# МИЛЛӘТЕМ, БЕРДӘНБЕРЕМ

## Ата-бабам

Ата-бабам булгар булган,
Ата-бабам татар булган.
Изге мирас итеп безгә
Ил калдырган,
Җир калдырган.

Тәкъдирләрендә язылган
Үз юлларын үзе үткән.
Безгә иркен тормыш теләп,
Якты дөньялардан киткән.

Ата-бабам
(Хәзер белдем !)
Тарихлары данлы икән.
Дошман явыз булганлыктан
Гомерләре канлы икән.

Ата-бабам батыр булган,
Куркып читкә тайпылмаган.
Туган җирен яклаганда
Үз җанын да аямаган.

Ата-бабам  тырыш булган,
Матур-матур йортлар салган,
Авылларын гүзәл кылган,
Олы-олы шәһәр корган.

Ата-бабам оста булган:
Тимер, агач эшен белгән;
Итек-читек теккән, чиккән,
Сәүдә итеп дөнья гизгән.

Ата-бабам мал караган,
Киң далада көтү көткән.
Җирне ипләп сукалаган,
Үз илендә иген иккән.

Ата-бабам корт үрчеткән,
Урманда аучылык иткән,
Балык тоткан-
Һөнәрләре
Җитмештән дә артып киткән.

Ата-бабам белем сөйгән,
Укымышлы, галим булган;
«Ялкау,- дигән наданнарны.-
Сукыр булыр укымаган».
Әллә шуның өчен микән,
Ата-бабамны белгәннәр,
Хәйран калып, «Бу татарга
Толмач кирәкмәс»,-дигәннәр.

Ата-бабам динле булган,
Намус белән дөнья көткән.
Тырыш эштә көне үткән,
Үз малы үзенә җиткән.

Моңлы җырларын җырлаган,
Изге туган телен сөйгән.
Телсез халык югаласын
Бабаларым яхшы белгән.

Хәзер татар балалары
Бөтен дөньяга таралган,
Ата-бабасын күпләре
Танымас та булып калган.
Кайбер имансызлар бүген
Татарча сөйләшү түгел,
Татарлыгын  инкяр итә.
Татар дисәң, татар түгел !

Юл табар микән адашкан ?
Уйланыр микән саташкан ?
Әллә «татар» дигән халык
Тусын микән яңа баштан ?
Очраклы йөкмени татар
Олы тарих арбасында ?
Югалсынмыни соң эреп
Башка милләт арасында ?

Күп гасырлы татар юлын
Читкә тибү кемгә файда ?
Милли рухы исән калган
Татарлар,
Сез хәзер кайда ?

Без дә тарих җимешедер.
Дөньядан югалса татар,
Шул акылсыз балаларын
Ата-бабам җаны каргар !

Уян, уйлан, оял, татар !
Һәркем үз милләтен яклар.
Милләтен таныган кеше
Телен, динен, җырын саклар.

Үткән гасырлар аркылы
Ата-бабам карап тора.
«Бу дөньяда ничек яшим?» –
Дип алардан киңәш сора.

Ата-бабам рухларыннан
Яшәү көче алыйк, туган !
Алар бит бик батыр, галим,
Оста, тырыш, эшчән булган.

Ата-бабам төрки булгар,
Татар, кыпчак, хазар булган.
Идел, Чулман буйларында
Иркен, азат тормыш корган.

## Бөркет баласы

*Бөркетләрдән генә бөркет туа,*
*Тилгәннәрдән бөркет туган юк.*
*Әхәт Нигъмәтуллин*

Бөркетләргә тиңдәш булган икән
Ерактагы ата-бабалар.
Азат бөркет булып очкан алар,
Иңләп-буйлап иркен далалар,
Якын итеп ерак аралар.

Бөркетләрдән бөркет туа, диләр,
Туды микән һәрчак бөркетләр?
Әллә бөркет оясында бөркет
Тик санарлык микән бөртекләп,
Бөркет түгел микән бик күпләр?

Бөркет көчен югалтмадык микән,
Гайрәт бармы күккә менәрлек?
Әллә югалганмы бөркетлек тә,
Каршы искән җилне җиңәрлек,
Бөркет нәселе без, диярлек?

Бөркет булып күккә омтылыйк без,
Киң канатлар шунда киерелер.
Явыз давылларга каршы очыйк,
Усал җилләр безгә бирелер,
Бөркет икәнлекләр беленер.

Менеп кунар өчен без сайларбыз
Биек таулар, булсын кыялы.
Бардыр бездә бөркет омтылышы,
Бөркет җаны, бөркет хыялы,
Бетмәгәндер бит шул чаялык!

## Милләтем

Татар булып килдем бу дөньяга,
Татар- минем килеш-килбәтем.
Язмышыңны синең уйлыйм һәрчак,
Туган халкым, асыл милләтем.

Күпме афәтләрне ерып чыктың,
Беләсеңдер яшәү хикмәтен.
Бәла-казаларга бирешмәдең,
Татар халкы, сабыр милләтем.

Дәрья булып акты кызыл каның,
Җимерделәр синең дәүләтең.
Ләкин башың һаман югарыда,
Сөйгән халкым, горур милләтем.

Ач-ялангач калдырдылар сине,
Талап барлык малың-мөлкәтең.
Бетәр идең.
Кара тирләр түгеп,
Күтәрелдең, тырыш милләтем.

Тараттылар сине, аердылар
Диннән,
Хәтта туган тел ятим.
Илең, динең, телең яңартырга
Көчең җитсә икән, милләтем.

Язмыш сине бик күп орды, сукты,
Калдымәле көчең-кодрәтең?
Яңа гасырларда табарсыңмы
Лаек урын, бөек милләтем?

Сихри акбүз атка менәрсеңме,
Очарсыңмы җилләр җилләтеп?
Киләчәктә татар дигән халык
Яшәр микән, газиз милләтем?
Үз-үзеңне саклап калырсыңмы,
Булдыралырсыңмы, милләтем ?
Булдыралырсыңмы ? !

## Җирдә

Күктән төшмәгәннәр бабаларым,
Шушы Җирдә гомер кичергән.
Шушы Җирдә туган, шунда үскән,
Шушы Җирдә бала үстергән.

Җиргә тирен түгеп эшләгәннәр,
Ялкауланып кырын ятмаган.
Кайнар кызыл канын аямыйча,
Дошманнардан җирен саклаган.

Мең-мең еллар Җирдә яшәгәннәр,
Шушы Җирнең булып хуҗасы.
Менә шунда изге динен тоткан,
Шушы Җирдә булган кыйбласы.

Без килмешәк түгел Җир йөзендә,
Җирдә тирән безнең тамырлар.
Киләчәктә безнең нәселләр дә
Шушы гүзәл Җирдә калырлар.

## Татармын

Хәрәмче зат күпме гасыр буе
Гайбәт сатты татар хакында.
Мин бер кисәкчеге шул кавемнең,
Татар үҗәтлеге холкымда.

Татар болай, я тегеләй, диеп,
Сүз куертма минем артымнан.
Татар булуыма горурланам,
Мин баш тартмам
Туган  халкымнан.

Нахак бәла ягып, мәсхәрәләп,
Яман атын сатма татарның .
Татар булып тудым,
Татар булып үстем,
Татар булып яшим,
Татармын !

## Кыпчак каны

Омтылам мин  һаман кайларгадыр,
Туктап тора алмыйм чак кына.
Тамырымда аккан кыпчак каны
Чал гасырлар  аша  чакыра.

Елгыр аргамагым алып килер
Җилдертеп зур юллар чатына.
Ял  итәр җир түгел юл чаты да,
Кыпчак каны алга чакыра.

Һавадагы азат бөркетләрнең
Очуына күңел ашкына.
Акылга бай чәчән сазы белән
Кыпчак каны мине чакыра.

Киң далада үскән кылганнар да
Селкенмиләр, искән җил тына.
Шунда тулган әрем исе белән
Кыпчак каны кая чакыра ?

Кыпчак каны миндә дулый, ахры,
Атлар кешни сыман якында.
Киң далада җилдәй очармын күк,
Кыпчак каны юлга чакыра.

Ата-бабам каны җир сугарган
Килер буыннарның хакына.
Шушы гүзәл җирне яклар өчен
Кыпчак каны яуга чакыра.

Акбүз атка килә менәсем дә,
Кулларыма кылыч  аласым.
Дошманнарны кырып ташлар идем,
Кем туктатыр кыпчак баласын?!

## Борынгы юлда

Кадим ташлар аяк асларымда,
Юл салганга узган гасырлар.
Кем йөрмәгән дисең шушы юлдан,
Тегесе дә, монысы да булган,
Шушы юлдан үткән батырлар.

Күпме табан юлны шомарткандыр,
Күпме атлар шуннан үткәндер.
Арбага да бу юл тигез, җиңел,
Кылганнар да юл өстендә түгел,
Тик кырыйда гына үскәндер.

Бик күпләргә бу юл хезмәт иткән,
Кайчан, кем йөргәнен карамас.
Тереләргә яшәү өчен терәк,
Бакыйларга китәр өчен кирәк,
Карты белән яше аралаш...

Күз алдымда хасил булды җайдак,
Аргамакта, күннән ияре.
Туган илен яклап чыккан микән,
Азатлыкны дауламакчы микән,
Яугирләре килә ияреп.

Ерак бабам түгел микән соң бу,
Мәрхүм әткәемә охшаган.
Телидер ул туган- үскән илен,
Изге, газиз ата- баба җирен
Коткарырга явыз патшадан.

Кылычында уйный кояш нуры,
Тәвәккәллек- аның карашы.
Халык азатлыгын яулар өчен
Дәһшәтле, кан койгыч еллар кичеп,
Әле озак, ерак барасы.

Үтеп китте гаскәр минем алдан,
Ерак бабам бугай юлбашчы...
Халкым күпме көрәш алып бара,
Күгебездә болыт һаман кара,
Шуңа хәсрәт, сагыш.
Шул ачы.

Басып торам борынгы бер юлда,
Юл ташлары күптән шомарган.
Шушы юлдан килгән бар яуларны,
Иле өчен шәһит батырларны
Беркайчан да истән чыгармам.

## Азатлык каһарманнары

Тарих дәфтәрләрен актарганда
Горурланырга без хаклыбыз:
Коллык  золымына баш имәгән,
Яуга чыккан туган халкыбыз.

Азатлыкны даулап көрәш ачкан
Мамыш Бирде атлы бабабыз.
Гали Әкрам, Сары батырларны
Тарих битләрендә табабыз.

Әхмәт баһадирны, Җан Галине,
Карасакал, Сәет, Батырша,
Алдар тархан, Килмәк кебекләрне
Гөнаһ булыр, әгәр онытсак !

Бер халыкта юктыр безнекедәй
Буын-буын батыр нәселләр.
Теләкәйдән – Күчем, аннан Акай,
Габдулланы халкым хәтерләр.

Канзафар да, Бәхтияр да чыккан
Пугачауның олы явында.
Азатлык, дип, кулга корал  алган
Татар халкы тагын, тагын да.

Менә бүген шушы батырларның
Исемнәрен язып алтыннан.
Аларның да үлмәс җаны, бәлки,
Рәхмәт, дога көтәр халкыннан.

## Изге туфрак

Ата- бабам җирнең  барысын
Саклап торган,  һәрбер карышын.
Туган туфракның һәр бөртеге
Кыйммәт,
Алтыннардан ким түгел.

Ерак бабаларым  аңлаган-
Тамыр көче туфрак- анадан.
Газиз ана- туган туфрагың,
Аннан  кадерле ни бар тагын?

Берзаман, ди, килгән  илчеләр,
Илне күреп йөргән, көнчелләр.
Таң калганнар: җир бай ханлыкның,
Тормышы мул  җирле халыкның.

Һәркем азат торган җирендә,
Иркен яши туган илендә.
Төрле милләт, ә бер җәмәгать,
Үзара дус, илдән канәгать.

Очрашканнар алар хан белән,
Бүләкләре затлы мал белән.
Хан да жәлләмәгән бүләкне-
Алтын-мәрҗән, гәүһәр нихәтле.

Китәр вакыт җиткәч, хушлашып,
Хан  угланы барган озатып.
Ханлык чикләрендә зур дәрья,
Килеп туктаганнар шул ярда.

Читләр көймә белән китмәкче,
Ләкин туктатканнар киткәнче.
Углан белдергән бер үтенеч,
Чик үтүгә шарт бар икән ич.

Углан читләрнең  (һәр кешенең)
Сорап алган итек-читеген.
Табаннарга кунган туфрагын
Каккан, сөртеп алган ул тагын.

Бу хәл бик гаҗәеп булганга,
Сорау биргән болар угланга:
«Итекләрнең, хәтта тузганның,
Нигә сөртәсез соң тузанын?

Бүтән илләрдә без күрмәдек,
Шундый тәртип бар дип белмәдек.
Мондый ихтирам тик безгәме,
Әллә барлык илчеләргәме?»

Углан әйткән:
«Без, -дип, -ханлыкта
Күнеккәнбез эшкә, байлыкка.
Бөтен нәрсә бездә җитәрлек,
Халкым тырыш бит, искитәрлек.

Без бирәбез алтын җәлләми,
Бәһалары булсын әллә ни,
Килгән кунакларга бүләккә.
Затлы мал бирәбез, кирәксә.

Саран түгелбез,
Тик бирмибез
Туган туфрак бөртеген дә без.
Һәркем соңгы юлга җитәдер,
Туган туфрак кабул итәдер.

Газиз ана- туган туфрагым,
Аннан  кадерле ни бар тагын?»

## Давыллар дәвамы

*Бабайларның җаны давыл булган,*
*Без бит шул давылның дәвамы.*
*Ләис Зөлкәрнәев*

Бабайларның җаны давыл булган,
Без аларга лаек дәваммы?
Әллә бер мизгелдә гөлт кабынып,
Шундук көл буласы саламмы?

Әллә акрын гына төтенләгән
Учак калдыгымы, пыскыган?
Әллә куак артларына посып,
Яши микән мескен, мыскыл җан?

Шул борынгы бабайларым белән
Батырларыбыз да киткәнме,
Дошманнарга каршы торалырлык
Көч-гайрәтләр бездә беткәнме?

Газиз туган телне таптасалар,
Үткәрсәләр аны кылычтан,
Тел якларлык бер баһадир юкмы,
Һаман йоклыйбызмы тынычлап?

Ятлар котырганда чыкмыйбызмы
Бердәм булып шулар каршына?
Күпме качып-посып яшәп була,
Җитсеннәрме халкың башына?

Күзачкысыз явыз бураннарга
Каршы куйыйк батыр йөрәкне.
Давыл җанлы халык нәселендә
Давыл җанлы ирләр сирәкме?

Давыл җанлы бабайларга охшап,
Кыяларга менеп басыйк без,
Әгәр булсак чынлап
Азатлыкка
Ерак бабайлардай гашыйк без.

Юктыр, димим, бардыр халкыбызда
Бабайларга лаек батырлар...
Юк итмәсен гүзәл телебезне,
Халкыбызны яңа гасырлар,
Шәфкать-мәрхәмәтсез явызлар...

## Дала

Дала, дала...
Иксез-чиксез дала.
Дүрт як офыкларга җәелгән.
Язгы тургайларның җыры белән
Киң далага тагын җәй килгән.

Әй ургылып үскән куе үлән,
Хуш ис бөрки дала гөлләре.
Чәчләремнән назлап сыйпагандай
Йомшак кына исә җилләре.

Иелешеп гөлләр, әйтерсең лә,
Серләшеп тә ала үзара.
Диңгез дулкыннары чыккан сыман-
Җил үләннәр белән шаяра.

Җил туктаса, үлән селкенми дә,
Бөтен тирә-ягым тын кала.
Бер җан иясе дә юктыр сыман,
Бар дөньяда мин дә киң дала.

Йомарт кояш нурлар чәчеп тора,
Килә минем шунда каласым:
Иркен дала кабул итәр әле
Япа-ялгыз төрки баласын.

Ничә гасыр буе күпме төрки
Шул далада дөнья көткәндер.
Рәхәтен дә, кыенын да белеп
Үзенә хас гомер иткәндер.

Саклый кебек дала төркиләрнең
Борынгыдан калган эзләрен,
Күргән шатлыгын да, кайгысын да,
Әйтеп бетермәгән сүзләрен.

Гасырларны куып гасыр үтәр,
Мәңге булыр сыман киң дала.
Төркиләрнең үткән чын тарихын
Ачып салыр сыман бер заман.
Әй киң дала,
Гүзәл киң далам!

## Атилла

Чал тарихта борынгыдан татар
Исем-атлы,
Шөһрәт казанган.
Күктә кояш,
Җирдә тирә-юньгә
Нур сибелгән Булгар, Казаннан.

Үз иленә үзе хуҗа халык
Иркен гомер сөргән, киң җирле.
Үз дәүләте гөрләп чәчәк аткан,
Данлы булган татар,
Ат-илле.

Атаклы ат, ил-мәмләкәт теләп,
Атилла дип исем куйганнар
Балаларга.
Саклап  газиз илен
Җанын фида кылган туганнар.

Җир йөзеннән юкка чыгарырлык
Афәт илгә ничә кат килде !
Егылса да, татар тагын торды,
Тапсыз исем белән,
Ат-илле ...

Тарихтагы шан-шөһрәтләр безгә
Әйтерсең лә, бүген ят инде.
Атилла да безгә чит зат сыман,
Әллә югалттыкмы ат-илне ?

## Алтын Урда

Күпме дәвер яманатың сатып,
Күпме нахак гаеп тактылар,
Алтын Урда!
Ә син һаман алтын,
Даның гасырларда яңгырар.

Изүче дип атадылар сине,
Кыргый дип тә бәя бирделәр,
Алтын Урда.
Алар үзләренең
Вәхшилеген белми, күрмиләр.

Менә шулар изге мәчетләрең,
Алтын сарайларың җимерде,
Алтын Урда.
Гүзәл калаларың
Бүген хәрабә тик, бер төрле.

Тарих дәшми бит ул, көтә генә
Хакыйкатьнең таңы атуын.
Алтын Урда,
Син дә көткәнсеңдер,
Көч-хәл белән басып ярсуың.

Татар иле, җире, мәмләкәте,
Анда гомер сөргән татарлар.
Алтын Урда,
Мәңге тарихта син,
Әле җир йөзендә татар бар.

Татар барда  аның аңы да бар,
Татарда бар милли хәтерләр.
Алтын Урда!
Бөек шул дәүләтне
Татар балалары хәтерләр.

## И Булгарым

И Булгарым, мөкатдәс җир,
Изге җиргә тәүге басуым.
Эчкә сыймас тойгы, хисләр,
Тыя алмыйм йөрәк ярсуын.

Тезләнәм дә башым иям,
Кулларымда уам туфрагын.
Бәлки монда ерак бабам
Туктаткандыр җитез тулпарын.

Үз учагын, илен яклап,
Күтәргәндер ул көр тавышын.
Баскын явын кырыр өчен
Чыгаргандыр булат кылычын.

Нәкъ менә шул төштә, бәлки,
Җаны шәһит китеп яткандыр,
Ерак бабамның нәкъ шунда
Кайнар кызыл каны аккандыр.

Бәлки, монда җирләнгән ул,
Куелгандыр ядкәр билгесе,
Исеме дә язылгандыр –
Минем өчен иң-иң изгесе.

Хәзер инде истәлек таш
Чиркәү нигезенә тезелгән,
Каберләре юкка чыккан...
Кайнар яшь атылды күземнән.

Бабам җаны көткәндер дә,
Варислары монда булыр, дип;
Чиркәү астындагы ташны
Урынына илтеп салыр, дип,
Башын иеп, дога кылыр, дип.

Учак сүнгән, димәдек тә,
Имансызлар, килмәдек тә
Бабам каберенә юл салып.
Ата-бабасын онытса,
Җирдә юкка чыга шул халык.

И Булгарым, и Булгарым-
Ата-бабам изге туфрагы.
Кабер ташы елап ята...
Бәхет булмас, татар, тагын,
Торгызмасак бабам учагын.

## Олуг Мөхәммәт

Яңа ханлык хасил булгай, чиктем рәхәт,
Изге Булгар җирләрендә бер кәрамәт.
Илтабары - кадерле зат, ул мәһабәт
Олуг Мөхәммәт хан,
Олуг Мөхәммәт.

Гөрләп үскән, чәчәк аткан, булган җәһәт,
Дошманнарын кырып салган бу мәмләкәт.
Үз иленә китермәгән һич һәлакәт
Олуг Мөхәммәт хан,
Олуг Мөхәммәт.

Шәһри Казан - гүзәл мәркәз, күргән хөрмәт,
Яулаган ул тирә-юньдә шан вә шөһрәт.
Татар яклап, саклап, кылгай ул мәрхәмәт
Олуг Мөхәммәт хан,
Олуг Мөхәммәт.

Хак Тәгаләм, укыйм сиңа мең-мең рәхмәт,
Барып җитсен догаларым вә мөнәҗәт.
Бакый дөньяң булсын, димен, тик бер җәннәт,
Олуг Мөхәммәт хан,
Олуг Мөхәммәт.

## Ватаным

Туган илем минем, изге Ватан,
Күпме афәтләргә очрадың.
Бетерергә тырыштылар сине,
Син барыбер юкка чыкмадың.

Халкың тырыш һәм булдыклы иде,
Менә шуңа күпләр көнләште.
Язмыш сиңа бәла-казаларны
Аямыйча, юмарт өләште.

Читләр беләмени кадереңне,
Аңлыймыни газиз җиреңне,
Туган илен яклап, шунда эшләп
Түккән каның, түккән тиреңне?!

Колач җитәлмәслек агачларны
Кистеләр дә, алып киттеләр;
Шаулап торган карурманны кырып,
Ямьсез, буп-буш пеләш иттеләр.

Алтыннардан кыйммәт туфрагыңны
Кемнәр чокый, кемнәр казына?
Үз халкыңа түгел, читкә китә
Җир астыннан чыккан хәзинә.

Кара көчләр һаман яный сиңа,
Телсез калдырмакчы халкыңны.
Бөтенләйгә бетсен бу ил, диеп,
Югалтмакчы исем-атыңны.

Һич бирешмә, илем,
Күп меңьеллык
Горур тарихың бар данлыклы.
Синсез татар да юк!
Бердәм булсак,
Бетерәлмәс бөек халыкны.

Илсез, бер тамырсыз бәндә түгел,
Минем бар тарихи Ватаным.
Эчем пошып, чиксез сагынганда
Чит илләрдән шунда кайтамын.
Әле дә син бар җирдә, и Ватаным,
Әйләнәм дә, сиңа кайтамын!

## Уйгур кардәш

*Бәхтияр Табиевка*
*Солтан Касыймга*

Ни булмаган дисең бу дөньяда,
Асты -өсте ничә әйләнгән.
Зур тарихта эзе калганнарның
Тәкъдирләре бергә бәйләнгән.

Тарих белән бүген дәгъвалашмыйм,
Төрлечә күп гасыр үткән бит.
Язмыштырмы, юкмы,
Вакыйгалар
Кабатланмас булып киткән бит.

Борын-борыннан бербөтен булган
Төркиләрнең газиз уллары
Таралышкан хәзер:
Уйгуры да,
Казахы да, татар-булгары;
Төрекмәне, үзбәк, кыргызлары,
Каракалпак, ногай, башкортлар,
Тагын башкалары.
Барысына
Уртак булган элек җир-йортлар.

Бу төркиләр өчен дөнья йөзе
Ачык булмаган шул гел генә.
Ачы-төчесен күп күргән алар,
Булмый бит ул татлы көн генә.

Ике яктан ике дәһшәтле яу
Басып килгән һәрчак төркигә.
Яуга каршы туган илен яклап,
Башка төркинең дә җирен саклап,
Уйгур, булгар  чиктә көн күргән.

Бәла-казаларның иң авыры,
Афәтләре төшкән боларга.
Көньяк аша килгән уйгурларга,
Көнбатыштан  татар-булгарга.

Төрки җирен талап, дошман яулар
Дәүләтләрне кырып салганнар.
Чиктә гомер сөргән ике халык
Чак-чак  югалмыйча калганнар.

Җиңелсә дә бирешмәгән болар,
Җаннарын да аямаганнар.
Менә шуны олы рәхмәт белән
Искә алыйк, төрки туганнар!

Бир кулыңны миңа, уйгур кардәш,
Без  фидаиларның баласы.
Ата-бабаларның батырлыгы
Зур тарихта мәңге каласы!

Дәгъвалаша  алмыйм тарих белән,
Кире кайтмас  узган гасырлар.
Үткән гасырларда татарның да,
Уйгурның да сүнмәс  даны бар,
Горурланырга чын хакы бар.

## Карлы буран

Бөтерелеп урый карлы буран,
Юлчы ялгыз,
Шуны талый ул.
Туңдырырлык  кытыршы тел белән
Аның бит очларын ялый ул.

Очып килеп ябырыла буран,
Ач бүредәй усал ажгыра,
Уң яктан да килә, сул яктан да,
Егылсын, ди бугай, аңгыра.

Тешләп өзәр өчен урын эзли,
Сыешалмый зәһәр ачуга,
Ухылдый да,
Бәрә-бәрә килеп,
Улап, даң-даң итеп чаң суга.

Куркытмакчы буран бу юлчыны,
Чаңнар сугып,
Өнди туктарга.
Хәзерләп тә куйган йомшак түшәк,
Шунда гына ятып йокларга.

Юк, туктама, юлчы,
Һич туктама,
Әйләнеп тә бакма шул якка!
Әгәр бер туктасаң,
Бер йокласаң,
Башка басалмассың аякка.

Юлчының да юлы,
Милләтнең дә
Кар-бураннар аша үтмәле.
Син йөресен - бүтән берәү йөрмәс,
Үз юлыңны үзең үт әле.

Туктамасаң,
Буран артта калыр,
Мәңге түгел салкын кышы да.
Бураннарны җиңгән милләт кенә
Абруй ала тарих каршында.

Милләт яшәр, әгәр туктамаса,
Алга барса,
Көчем җитә, дип.
Әйдә, туган,
Киттек, туктамыйча.
Йөргән кеше юлны үтә бит.

## Ата -бабам мирасы

Ата -бабам уйлагандыр әле
Килер буыннары турында,
Нәселләргә билге-мазар, димен,
Калдыргандыр берәр урында.

Тау-таш арасында озак йөрдем,
Өметләнеп берчак табарым
Борынгыдан менә шунда калган
Эз-хәбәрен ата-бабамның.

Болыннарда, урманнарда йөрдем,
Табылмады эзләр анда да.
Далаларны айкап, дәрья кичтем,
Юк мин эзләгән беркайда да.

Аптырап бик озак уйлап тордым,
Киңәш кордым яшь һәм карт белән.
Табылды бит шунда бер хәкыйкать,
Күз алдымда эзләр бар, беләм!

Ата-бабам эзе тарихларда,
Үткән юллары да изгеләр,
Әйтемнәре миңа васыятьтер,
Тапкыр сүзләр- миңа билгеләр.

Ата-бабам гүзәл табигатьне,
Бөек татар данын калдырган,
Моңлы җырлар, шанлы тарихын да,
Илемне дә миңа яздырган.

Бик зур мирас калган борынгыдан,
Безгә бурыч итеп куйганнар.
Килер буыннарга түкми-чәчми
Җиткерергә кирәк, туганнар.

Гүзәл телебезне, тарихны да,
Татарга хас күркәм холыкны
Алсыннар да,
Мәңге сакласыннар
Татар дигән бөек халыкны.

## Татар моңы

Нинди генә татар сөйми икән
Үзәк өзгеч милли моңнарны?
Татар моңы кебек йөрәкләргә
Тирән эзләр салган моң бармы?

Хәсрәтләрен, тирән  кайгыларын
Татар моңнар аша  белдергән.
Моңнар белән юаткан да үзен,
Авырлыкны баштан кичергән.

Шул моңнарда явыз гасырларның
Афәтләре тора чагылып.
Бар хисләрен моңга төргән  татар
Туган илен читтә сагынып.

Моңнарына тулган милли хисләр,
Хыялы да моңда халкымның.
Киләчәккә булган өмете дә,
Көткән бәхете дә-  шул моңы.

Моңнарыбыз, моңлы җырларыбыз
Калсын бездән, газиз туганнар.
Үзәкләрне  өзә торган моңнар,
Сагышларны баса торганнар.

Киләчәктә минем варисларым
Шул моңнарны сөеп көйләсен.
Милли моңын сөйгән татарларга
Кайгы һәм җил-давыл тимәсен.

И мөкатдәс гүзәл татар моңы –
Ерак бабаларым мирасы.
Җир йөзендә тик бер генә татар
Калганда да
Моң яңгырасы!
Моңсыз татар булмас, юктыр җирдә,
Моңнар киләчәккә каласы...

## Татар китабы

*Йөзем, телем һәм күземне ачтың,*
*Татар китабы, әй, татар китабы.*
*Айдар Хәлим*

Зур дөньяга чыгар юл күрсәттең,
Мондый нәрсә кайда бар тагы?
Күпме еллар синең белән бергә,
Дус китабым- татар китабы.

Зәңгәр күктә очтым синең белән,
Күргәнемнең юктыр хисабы.
Могҗизалар тулган һәр битенә
Маҗаралы татар китабы.

Алып китә ерак-еракларга,
Анда дәрья, диңгез, Каф тавы.
Серле юллар буйлап алга өнди
Тылсымлы шул татар китабы.

Узган-булганнарның серен ача,
Бу дөньяда яшәү сабагы.
Барлык сорауга да җавап бирә
Галим китап, татар китабы.

Ярсып сөюләр дә, мәхәббәтем,
Сөйгәнемнең кайнар кочагы,
Мәңге үлмәс хисләр-
Барысы да
Синдә, назлы татар китабы.

Күтәренке кәеф белән һәрчак
Гөрләп торсын өчен киң табын,
Кирәк сүзләр синнән табыла бит,
Җырлы, моңлы татар китабы.

Күз өстендә каштай,
Яшь кызларның
Бит очына кунган миң табы,
Шулай кадерле ул татарыма,
Гүзәл китап, татар китабы !

## Татарга дәүләт кирәкме?

Кайберәүләр:
Дәүләт, диләр,
Ни пычагыма кирәк?
Җир йөзендә күпме халык,
Дәүләтлеләре сирәк.
Дәүләт өчен куәт кирәк,
Без, диләр, зәгыйфь халык;
Берләшә дә алмыйбыз бит,
Тик яшибез таркалып.

Күршебез белән очраштык
Олы тарих юлында.
Богау түгел лә, беләзек
Такты ике кулыма.
Күршедән золым күрдекме,
Ул булмас, диләр, кабат.
Дәүләтебезне кырдымы –
Узган эшкә салават.

Бик дуамал булмыйк әле,
Зык куптармыйк юкка да,
Иминлекне уйлыйк, диләр;
Әйдә, җирне сукала,
Иген үстер, маллар кара,
Байлык тап җир астыннан;
Болар безнең кулдан килә,
Татар эштә ярсына.

Дәүләт, дисәң, Рәсәй бар ич,
Төкер үз дәүләтеңә.
Нигә, диләр, безгә гәүдә,
Риза бул шәүләсенә.
Күпме гасыр буе менә
Шул Рәсәйне якладык,
Каныбызны койдык яуда,
Бер дә посып ятмадык.

Шушы дәүләт сиңа җиткән
Үз җирең дә аз хәзер;
Халкың да таралып беткән,
Тупланалмый нигәдер.
Дәүләт кору ай-һай кыен,
Ул эш, диләр, ник кирәк?
Безнең кулдан килмәс, диләр,
Рәсәй - хуҗа, шул терәк!...

Татардан да туар микән
Дәүләт корырдай зирәк?
Андый зат туа сирәк....

## **Тату микән татар?**

*Тату халык миргә таралмас.*
*Ә. Синугыл Куганаклы*

Тату микән татар, түгел микән,
Шул сорауның бармы җавабы ?
Тату халык бердәм, көчле булыр,
Бердәмлекнең бардыр сәвабы.

Тату, бердәм булмагандыр татар,
Үз дәүләтен саклый алмаган.
Күпме гасыр җыйган бар байлыгы
Ятка киткән, илдә калмаган.

Татар тату булса, бергә туплап
Барлык көч- куәтен, гайрәтен,
Дошманнарын кырып салыр иде,
Гөлләндереп татар дәүләтен.

Тату түгелдер шул татар халкы,
Чит якларга күпләр таралган.
Җирси- җирси гомер кичергәндер
Еракларда Идел- Уралдан.

Тату булса, бергә торыр иде
Халкы белән, туган илендә.
Янып пешә чит як эссесендә,
Туңа читнең ачы җилендә.

Тату түгел, ахры,
Әйтәләр бит:
Татар, диеп, ашар татарны.
Үзара гел дошман булып кына
Яши торган халык - татармы?

Татулыкны белмәс халык булып
Яралганмы газиз татарым?
Су тамчысы кибеп беткән сыман
Югалырмы эзе татарның?

Юк, ышанмыйм моңа.
Тарих белә
Татарның да тату чакларын.
Бердәмлектә яши белә бит ул,
Һәрбер татар –туган татарың.

Кайда гына яшәсә дә, татар
Гүзәл туган телен саклаган.
Мөэмин- мөселманны кысканда да,
Изге диненнән баш тартмаган.

Дошман явы илгә килгән чакта
Бердәм татар илен яклый бит.
Нинди генә авыр эшләр булсын,
Татар шунда,
Эштән качмый бит.

Гөрләп тора татар өмәләре,
Эшләр җитез, тату эшләгәч.
Әй күңелле татар сабантуе,
Үзара һич каршы килмәгәч.

Ни эшләсәң, шул уңышлы бит ул,
Әгәр эштә булса татулык...
Ләкин һаман теге сорау борчый:
Тату микән татар?
Татумы?

## Хат язам бүген

*Роберт Миңнуллинга*

Шигырьләреңә сокланам,
Үзеңне дә яратам.
Атаклы шагыйрь,
Тик үзең
Гап-гади, бер карасаң.

Олылап син абый дисең,
Очрашып калган чакта.
Мин дә сиңа энем димен,
Туганнар булмасак та.

Нәкъ татарча бит ул
Абый,
Энем диеп куюлар,
Бер үк милләт балалары
Кардәшлеген тоюлар.

Китапларыңны укыйм мин
Калдырмыйча сүзен дә.
Фикерләрнең уртаклыгын
Шунда күрәм үзем дә.

Синдә бит нәкъ минем сыман
Татар диеп янасың.
Аңлыйсың үз халкыңның бар
Хасталарын, ярасын.

Бәрәкәт тик хәрәкәттә-
Татар аңласын иде,
Мәрткә китеп гасырларча
Йоклап ятмасын иде!

Татар үзен кайгыртмаса,
Ник кайгыртсын бүтәннәр
(Күпме афәт, бәла-каза
Башыбыздан үткәннәр)?

Шуларны син әйтәсең бит
Һәркем белерлек итеп,
Җан ачысы йөрәкләргә
Үтеп керерлек итеп.

Ходай биргән сиңа сәләт,
Син шуны югалтмадың.
Җигә белдең шигърияттнең
Пар канатлы атларын.

Сокланып шул эшләреңә,
Хат язам сиңа бүген.
Китапларың чыгып торсын
Яңадан-яңа, энем.

Кабат әйт син татарыңа:
Юк туктарга хакың дип;
Туктап калган милләт үлә,
Туктый күрмә, халкым дип.

Яз барысын яшермичә,
Яз син тагын, тагын да...
Бәлки татар уяныр да
Безләр исән чагында.

## Ана телем

И мөкатдәс ана телем,
Синдә сизәм газиз халкым, туган илем.

Синең белән сабый чактан
Атам,  анам иркәләгән, назлап кочкан.

Син булганга яши алдым,
Зур дөньяга барыр, йөрер юллар салдым.

Син бит ышанычлы юлдаш,
Дуслар таптым, гүзәл ана телем булгач.

Шатлыгымда кирәк булдың,
Авыр чакта, ана телем, терәк булдың.

Югалмаса ана телем,
Халкым яшәр, якты булыр килер көнем.

И кадерле ана телем,
Син барында үз милләтем кешесемен.

## Туган халкым

Борма-борма булды үткән юлым,
Әле иркен үзе, әле тар.
Адашыр да идем, ялгыз булсам,
Миңа юлдаш туган халкым бар.

Юллар мине шактый күп сынады-
Әле эссе, әле салкын кар.
Пешмәдем дә, бозланмадым да мин,
Ярдәм итәр туган халкым бар.

Дәһшәтле су дулкыннарын ярдым,
Ут ажгыртып  калды ялкыннар.
Явыз хәвефкә дә бирешмәдем,
Таянычым- туган халкым бар.

Ниләр генә күрсәтмәде дөнья -
Әле шатлык, әле моңлы зар.
Изелмәдем кайгы-хәсрәтләрдән,
Юатырга туган халкым бар.

Горурланып, җиргә текә басып,
Баш күтәреп яшәр  хакым бар.
Мин дә татарның  бер улы,
Җирдә
Минем газиз туган халкым бар!

## Мин милләтче бугай

Мин милләтче бугай, бик яратам,
Хөрмәтлимен туган халкымны.
Шуңа берәү нахак бәла якса,
Җенләндерә минем холкымны.

Башка милләтләр дә ошый миңа,
Акыллы да алар, чибәрләр;
Даннар яулап алып, кешелекнең
Алгы сафларына кергәннәр.

Мин ихтирам итәм башкаларны,
Яклыйм сәнгатьләрен, телләрен,
Бөтен милли хокукларын яклыйм,
Таныйм тарихи  җир-илләрен.

Алардан да шундый караш көтәм,
Үз халкыма көтәм ихтирам.
Көткәннәрем килсә,
Милләтчелек
Тумас иде миндә, ихтимал.

Ләкин мәктәптә үк тукыдылар:
Татар-монгол, имеш, изүче.
Янәсе юк, имеш, зур тарихта
Бер генә дә татар изгесе.

Үз җире дә юк ди, бу халыкның,
Юлбасар ди, ләгънәт төшкере.
Теле дә юк, мәдәнияте дә,
Бер кирәксез, юкка теп-тере.

Китап битләрендә гел хезмәтче,
Йә бер явыз уйлы басурман.
Хәтта дине начар икән моның,
Тәре генә мәңге балкыган.

Күпме гасыр шуны сөйләделәр,
Чуалмаган баш та чуалыр.
Булды, җитте,
Чыгырымнан чыктым
 (Милләтчеләр шулай туадыр!).

Татар, дип,
Мин тавыш күтәрмәсәм,
Кем күтәрә, ди, ул тавышны?
Татар юлы  данлы икән, дисәм,
Бүтәннәргә яла ягышмы?

Бүтәннәр бик күтәрә бит мактап
Үз халкының үткән юлларын.
Мин дә мактыйм
Татар тарихын да,
Үз халкымның бөек улларын.

Халкың белән горурланыр өчен
Нигезең бар, татар баласы!
Татармын  дип, сөен.
Бөек халык
Тарихларда мәңге каласы.

Мин милләтче бугай,
Булсам, булыйм.
Һәркем милләтче үз халкына.
Яман сүз әйтмәгез шул татарга,
Җен ябыша тагын холкыма.

## Замандашыма

*Разил Вәлиевкә*

Разил кардәш!
Син халкымның
Кадерле бер газиз баласы.
Бөтен татар дөньясы да белә,
Таный сине авыл, каласы.

Шагыйрь дә син, сәясәтче дә син,
Барысына җитә акылың.
Тирән ихтирамга чынлап лаек,
Йөзек кашы туган халкыңның.

Тырышлык та сокланырлык синдә,
Тирән фикер, әдип асылы.
Уйларыңны төгәл җиткерәсең
Тапкыр, нәфис сүзләр аркылы.

Милләтемнең киләчәге өчен
Җиң сызганып күптән эшлисең.
Халкым язмышларын кайгыртуда
Тавышлы син, дәртле, көчле син.

Тавышыңны бер дә туктатмале,
Ишетсеннәр башка халыклар:
Шушы җирдә яшәр хакыбыз бар,
Җирдә татар дигән халык бар!

Мин дә татарым дип тавышланам,
Синең тавыш саллы, көчлерәк.
Минем тавыш, белмим, кирәк микән,
Синең тавыш, әлбәт, бик кирәк.

Татар уллары да кайгыртмаса,
Кем кайгыртсын татар язмышын?
Барлык балалары йөзен борса,
Исән  калыр милләт бармы  соң?

Үз хәстәрен үзе күрмәдисә,
Кемгә кирәк, дисең, татарың?
Азмыни ул җирдә югалганнар,
Юкка чыккан, беткән милләт азмы,
Булмый инде кире кайтарып.

Ана теле, халкым даны өчен
Без бурычлы газиз татарга.
Татар җыры, татар үҗәтлеге
Куәт бирә безнең чаптарга.

Халкым алдындагы бурычларны
Ихлас хезмәт белән түләек,
Җанны аямыйча түләек.
Бердәм булсын татар, бергә булсын,
Бер алманы бишкә бүләек!

## Җебегәнме татар ?

*...татарлар*
*Җебегән бит, җебегән.*
*Г. Тукай*

Җебегәнме ?
Җебегәндер,
Кай дәүләтен саклаган ?
Бөек Булгар юкка чыккан,
Үз җире дә аз калган.

Шанлы Казан каласын да
Явыз дошман җимергән.
Кол хәлендә калып, татар
Күпме газап кичергән.

Яртылаш югалткан телен,
Изге динен, җырларын.
Татар җебек, дияр өчен
Ниләр кирәк соң тагын ?

Тик шулай да, уйлап баксаң,
Җебегән түгел сыман.
Илен яклаганда татар
Җанын аямый торган.

Аның Олуг Мөхәммәт хан,
Кол Галиләре дә бар,
Сәхип Гәрәй, Сөембикә,
Кол Шәрифләре дә бар.
Мәрҗәние, Тукайлары,
Максуди, Акчуралар,
Җәлил, Сәйдәш, Саралары,
Такташ, Туфаннар да бар.

Бар Фәхретдин, Хәмидиләр,
Илһамнар, Минтимерләр.
Санап китсәң, бик күп әле
Мактанырлык исемнәр.

Җебек халык тудыралмас
Мондый кызлар һәм уллар.
Язмыш бураннарын жиңеп,
Үтәлмәс авыр юллар.

Җебек халык әллә кайчан
Эреп тә бетәр иде;
Исемен дә калдырмыйча,
Хәтердән китәр иде.

Ә татар бит яши әле,
Телен, динен сатмаган.
Нинди изүләр булса да,
Хет яртылай саклаган.

Җебек түгел татар халкы.
Тукай язган ачынып,
Йокламасын, яшәсен, дип,
Татар алга ашкынып.

Килер көндә татарымның
Бәхетләре бар аның.
Насыйп булыр әле күрү
Киләчәкнең ал таңын.

## Сөембикә манарасы

Казанның нәкъ уртасында
Җиде катлы таш манара.
Күпме гасыр картаймый ул,
Гел яшь үзе, гел яңара.

Алтын  ярым-ай очында
Нурлар сибеп тора һаман.
Туп-туры юл күрсәтәдер
Изге кыйбла тарафына.

Догаларын укый монда
Яше- карты, үткән-барган.
Бөтен  җиргә күренә ул
Якыннан да, ераклардан.

Күптән үткән буыннарың
Безгә калган ул мирасы.
Башы күккә  тиеп тора
Сөембикә манарасы.

**Картәткәемә хат**

*Игенчеләр безнең ыруда.*
*Разил Вәлиев*

Авылыма кайттым.
Шаулы басу,
Гөрләп иген үсә, хуш исле.
Башакларын барлыйм сокланып мин,
Кызу кояш яна баш өсте.

Ничә гасыр шушы басуларда
Бабаларым тирен түккәндер.
Исе китеп иген диңгезенә
Исергәндер асыл хистән бер.

Газиз картәткәем Хәйрулла да
Шул басуны сөргән һәр язда.
Тук атларын җигеп сабаннарга,
Менә шунда салган буразна.

Карап туялмаслык иген кыры.
Туктатам да хыял атымны,
Үзем бер күрмәгән картәткәмә
Язам әле шушы хатымны.

«Картәткәем, и сөекле бабам,
Синсез үткән гасыр аша мин
(Оныкларыңның да иң кечесе),
Башым иеп, бүген дәшәмен.

Син рәнҗемә инде, картәткәем,
Таралышып киттек еракка.
Синдәй җилдермибез җил уйнатып
Авыл буйлап ярсу паратта.

Туган авылым да төштә генә,
Игенче дә түгел һөнәрем.
Балаларым, оныкларымның да
Бүтән эштә үтә көннәре.

Башка яктан алар булдыклы да,
Ләкин иген эшен белмиләр;
Ата-бабам иген иккән, диеп,
Тик мактанып кына сөйлиләр.

Дөнья үзгәрдеме, язмыш микән,
Беребез дә иген икмибез.
Кара тирләреңне түккән җирдән
Аерылдык бугай инде без.

Әйе, игенчеләр түгелбез дә,
Ә барыбер басу чакыра.
Шул басуда эшем калган сыман,
Онытылсам әгәр чак кына.

Синнән киләдер ул шундый хисләр-
Шундый сөю иген кырларын.
Җир дә сөрмим, ләкин һич онытмыйм
Картәткәем сөргән җир барын.

Синең исем- безгә фамилия.
Нәсел булгач якты дөньяда,
Син дә һаман исән-имин сыман.
Тагын нәрсә кирәк бәндәгә?

Чынлап масаябыз:
Хәйрулланың-
Игенченең дип, без нәселе;
Авылдагы иң саф намуслы җан
Булган, дибез, аның кәсебе.

Һич борчылма, кыек-мыек юлга
Борылмады синең нәселең:
Эштән тайпылмады,
Кирәк чакта
Яклады үз җирен, үз илен.

Бөтен нәселең дә синең кебек
Үз көчләре белән мал таба...
Хатым барып җитмәс.
Бәлки сиңа
Хәбәр җиткерер кем булса да».

Җан тартмаса, кан  тартадыр инде,
Кайткан саен барам басуга.
Әйтерсең лә,
Межа буйлап, эре-эре атлап,
Картәткәем  килә каршыма,
Нидер әйтергәме ашыга.

## Дога

Хак Тәгаләм, тик бер синә
Менә шул кылган догам.
Синә генә инанам мин,
Синә ялварам, Ходам.

Гөнаһларым бардыр инде,
Аны үзең беләсең.
Ярлыкагыл, дип үтенәм,
Син генә кичерәсең.

Саваплар да байтак кына
Булырга тиеш иде.
Түкми-чәчми исәбеңә
Кертергә тырыш инде.

Яшьлегемне кайтар, диеп,
Сорамыйм синнән, Ходай.
Булыр-булмас теләкләрне
Кабул итмисең бугай.

Даһилык сорамыйм синнән,
Биргән акылың җиткән.
Даһилыкны дәгъва итеп
Йөрер вакыт та үткән.

Җитәкче булыйм, дип әйтмим,
Зур байлыклар бир, димим.
Нәфес чиксез бит бәндәңдә,
Биргәнең калсын, димен.

Корычтай сау-сәламәтлек
Бирә алмассың инде.
Хет бүгенге саулыгымны
Миңа сакласаң иде.

Адәм балалары белән
Минем мөнәсәбәтем
Дустанә һәм ачык булды,
Калсын шушы гадәтем.

Ихтирам иттем кешене,
Үзем дә күрдем хөрмәт.
Юл беткәнче, шулай булса,
Бусы да ярый, димәк.

Мине, Аллам, якыннардан,
Дусларымнан аерма.
Аларсыз мин кемгә кирәк,
Ялгызлыкка боерма.

Эшләремне тартып алып,
Буш калдырма кулымны.
Эшлим эле, көч җиткәнчә,
Эшем бизи юлымны.

Бәла-казалардан сакла,
Бирмә ут-су афәтен.
Андый кайгылар китермә,
Тойыйм дөнья рәхәтен.

Бала кайгылары авыр,
Миңа язмасын инде.
Балаларым, оныкларым
Гөрләп яшәсен иде.

Миңа бирмәгән бәхетне
Бирче балаларыма.
Кыен итмә баруларын
Бу дөнья базарына.

Гомер озынлыгын алсак,
Кирәк шул кадәр еллар,
Үзем теләп, шатлык белән
Үтәрлек булсын юллар.

Юл азагын уйлар булсак,
Бир, Ходай, тыныч үлем.
Башкаларны җәфаламый,
Тиз генә алсын гүрем.

Илләремә имин еллар,
Тынычлык бирсәң иде.
Көләч йөзле, тук балалар
Йөгереп йөрсен иде.

Газиз туган халкым күпме
Рәнҗешкә калган иде,
Халкыма киң рәхмәтеңне
Тутырып салсаң иде.

Килмешәк түгел ләбаса
Шушы халык бу җиргә.
Башкалардай үз балаң бит,
Кыерсытма гомергә.

Саный торгач, байтак булды,
Кичер мине, Ходаем.
Шул кадәр үтенеч миннән
Килми бит ул көн саен.

Мине тиргәр урын юктыр,
Сирәк сорыйм,валлаһи!
Шундый итеп мине үзең
Яраткансың, Аллаһым.

## Мулла бабай

Зинһар кичер инде, мулла бабай,
Бик атеист булып үстек шул.
Мулла дигән җиргә төкердек без,
Динебездән дә ваз кичтек шул.

Бер мин генә түгел, Тукайлар да,
Такташлар да шуны җырлады,
Мулла бит ул бер соры корт, диде,
Надан, дип тиргәде мулланы.

Муллаларга каршы чыккан чакта
(Әллә белеп, әллә аңламый)
Кушылганнар безнең әтиләр дә,
Абыйлар да көчен аямый.

Дәүләте дә гел мулланы кырды,
Ерак сөргеннәргә озатты,
Китапларыбызны утка якты,
Изге динебезне югалтты.

Муллаларны юкка чыгардык та,
Мәчет нигезләрен җимердек,
Абыстайлар өстеннән дә көлдек,
Мәдрәсәләрне дә бетердек.

Менә хәзер без - бер динсез инде,
Юкка чыгар сыман телебез.
Милли рухыбыз да көч-куәтсез.
Милләт шулай бетә,
Белегез!

Ничә дистә еллар үткәч кенә
Инде хаталарны аңлыйбыз.
Милләт яшәсен дип җанын биргән
Муллаларның эшен барлыйбыз.

Динебезне саклап калыр өчен
Мәктәп ачкан мулла, мәдрәсә.
Татар теле югалмасын  диеп,
Җир йөзендә  татар булсын  диеп,
Мулла баш күтәргән ләбаса!

Нинди афәтләрдән исән калган
Татар халкы  күпме гасырлар.
Динем өчен, туган телем  өчен
Мин  җанымны фида кылдым  диеп,
Шул мулланың әйтер хакы бар.

Һәйкәл куяр идем муллаларга,
Белдереп мин татар рәхмәтен.
Җиргә сеңдерсен иде шул һәйкәл
Дошманнарның явыз зәхмәтен.

Мәңге киткәннәргә җиңел туфрак,
Җаны булсын җәннәт - оҗмахта.
Тәңрем белсен:
Инде изге Коръән
Рәнҗеп ятмас янар учакта!

Кичер инде мине, мулла бабай,
Ышанмадым  элек  вәгазьгә.
Хәзер  генә аңлый  башладык бит,
Бүген генә  яза башладык бит
Изге исемнәрне кәгазьгә.

## Мөселман фарызы

Кирәк булса белем табар өчен,
Кытайларга тиклем барырсың,
Гамәлгә тик шулай ашырырсың
Мөэмин-мөселманның фарызын.

Изге пәйгамбәр дә кушкан:
«Бул,-дип, -
Йә галим, йә белем алучы,
Йә илтифат белән галимнәрнең
Сүзләренә колак салучы;

Шундыйларны ихтирам ит,-дигән,-
Бул аларны ихлас сөюче».
....
Мондый тирән уйлы асыл дингә
Булырсың да чын баш июче!

## *ГАЗИЗ ХАЛКЫМ- ТАТАРЫМ*

### Милләтемә сүзем бар

Әйтер сүзләрем бар, милләтем,
Җир йөзендә байтак яшәдем.
Болгавыр ла шушы дәверләр
Белән туры килде гомерләр.
Уйлап торсаң татар язмышын,
Тыялмассың кайнар яшьләрең.

Әллә кирәгендә тумаганмын,
Әллә инде соңлап туганмын.
Минсез үткән күпме гасырлар,
Мин югында торган батырлар.
Ә мин булдым мескен энесе
Көч-гайрәтле өлкән туганның.

Аның теле миңа беренче,
Анам теле - ике, өченче.
Бөек аның гына тарихы,
Ул яктырткан җирдә барысын.
Кушса, китәм яуга, тау кисәм,
Рөхсәт итсә генә -игенче.

Минме үз өемнең матчасы,
Чит түгелме илем патшасы?
Туган җиргә хуҗа булалмыйм,
Үзем теләгәнне кылалмыйм,
Иркен, тигез юллар юк миңа,
Сикәлтәле юллар барчасы.

Сокланалмыйм галәм яменә-
Йөрәк әрни татар хәленә.
Аллам!
Ник тиң түгел халыклар-
Ачык телләр дә бар, ябыклар?...
Киләчәктә татар калыр дип
Өметләнә халкым әле дә.

Өметләр бар, тик чык юлыңа,
Язмыш, татар, үзең кулыңда.
Бүгенгенең шушы мәхшәрен
Исән үтүнең күр хәстәрен.
Син үзеңә генә кирәксең,
Үзең хуҗа бул үз йортыңда.

**Татарның милли хисе**

*Кто не любит своего народа и кому*
*не мил конкретный образ его,тому не мил*
*и конкретный образ человечества.*
*Н.А.Бердяев*

Бармы татар дигән милләт,
Яшәвендә нинди хикмәт?
Тарихтагы шул татармы,
Җирдә яшәр хакы бармы?

Күпме гасыр югалмаган,
Эремәгән, таралмаган.
Һаман тере, һаман исән,
Горур микән, татар дисәң?
Йә китәрме башын иеп,
Мин бичара татар, диеп?

Яратылган төрле милләт,
Тәңре шулай кушкан димәк.
Һәр милләтнең үз төре бар,
Үз урыны, үз җире бар.

Һәрбер милләт тулы хаклы,
Үзен-үзе саклый, яклый.
Якламаса, ул югала,
Тарихта эз генә кала.

Милләтнең үз гомере бар,
Вакытында гөрләр, шаулар.
Милләт-милләт тату яши,
Милләт гомерен кисә вәхши.

Бирешмәскә вәхши көчкә,
Гайрәтле бул милли хистә.
Милләтеңне үзең сакла,
Милли рухың торсын сакта.

Намуслы бул син үзең дә,
Урын җитәр җир йөзендә.
Читләр хакы кирәк түгел,
Үз хакыңа сак бул бүген.
Гәрчә уртак зәңгәр бер күк,
Милли хисне сакла берүк!

### Дуслыкны ныгыту чарасы

*По Закону ГД РФ национально-региональный компонент исключен из стандартов образования.*

Депутатлар закон чыгаралар
Мәскәү дигән бөек калада.
Мәҗбүри ул закон һәр кешегә-
Өлкәнгә дә, кече балага.

Һәр депутат күптән тикшерелгән,
Һәр депутат монда сайланган.
Гел Мәскәүдән генә түгел алар,
Төрле җирдән, әллә кайлардан.
Алар арасында татарлар да,
Башкорт, чувашлар да бар, имеш,
Башкалар да.
Бөтен законнарны
Хуплый ничек язган, шул килеш.

Һәр депутат акыл ияседер,
Аны монда халык сайлаган.
Думада ул унбиш- егерме ел
Тел шомарткан, телен кайраган.

Тик бер кара акыл белән генә
Бу законның тирән мәгънәсен
Аңлап булмас.
Менә белсәң иде
Депутатлар нәрсә әйтәсен.

Аңламагач, нишләргә соң ?
Булмас
Гади акыл белән баш ватып.
Тыңлыйк әле
Закон зарурлыгын
Депутатлар ничек аңлатыр.

«Бүген кабул иткән законыбыз
Бик кирәкле, бигрәк вакытлы.
Бөтен дөнья безгә дошман чакта
Төрле-төрле булыр вакытмы?

Хәтәр бит ул, әгәр һәрбер халык
Туган ана телен өйрәнсә,
Җырларның да уртакларын түгел,
Һаман шул үз көен көйләсә;
Әллә нинди милли кием кисә,
Безнең кушканнарны кимәсә;
Безнең динебезгә инанмаса,
Әгәр үз Тәңренә инанса;
Башларында үз уйлары булса,
Бүтән фикерләрне сыйдырса;
Чик куярга кирәк барысына,
Безнең ил таркалыр югыйсә.

Шушы закон бөтен илебезгә
Алып килер байлык, муллыкны.
Һичбер шиксез чынлап ныгытыр ул
Илдә халыкара дуслыкны».

Әлбәт, депутатлар бик акыллы,
Илгә ни кирәген беләдер.
Тик мин белмим, ничек шушы закон
Дуслык арканнарын үрәлер?

Ата-бабаң рухы тапталганда
Нинди  дуслык хисе табылган?...
Акыл иялəре законына
Кимсетүле билге тагылган.

Да умна ты Дума, Дума, Дума,
Неужели горе  от  ума?

## Урыс татары

*Великая миссия русских... скреплять русских армян,*
*русских азербайджанцев, русских немцев,*
*русских татар... Скреплять в такой тип*
*государства-цивилизации, где нет «нацменов».*
*В.В.Путин*

Исемең дә калмады бит синең,
Татар түгел,
Урыс татары.
Телең хәзер ярты-йорты татар,
Алырлык ни -нәрсәң бар тагы?

Татар дигән горур исем белән
Туган халкым  җирдә танылган.
Шул исемне бүген яшерен генә
Тартып алмакчылар  җанымнан.

Татармын дип, минем бабаларым
Иген иккән, гомер сөргәннәр.
Шушы исем белән халкы өчен,
Иле өчен утка кергәннәр.

Кешелекне сөймәс бәндәләргә
Җирдә яшәр урын тар микән?
Урыс татарлары булган кебек,
Татар урыслары, чукча урыслары,
Нанай урыслары, немец урыслары,
Төрки урыслар да бар микән?

«Нацмен» булмый инде киләчәктә,
Кайда калсын, бар да бер эздә.
Мәдәният, рухи байлык уртак,
Урысныкы, әлбәт, нигездә.

«Безнеке-чит» -булыр аермачык,
Кирәк түгел монда тәһарәт.
Мәдәният урысныкы-яхшы,
Туры килми икән-хәшәрәт.

Оешкан бер милләт бөтенесе-
Нацменнар да, олы агай да.
Тик бер иске гадәт калыр-
Сылтау
Бар чатакны мәрхүм Мамайга.

Исемеңне, төптә җисемеңне
Якларлык көч бармы, татарым?
Якламасаң, бик тиз онытырлар
Борын заман татар торганын.

## Татар тарихы

*Знание истории является главным отличием цивилизованного человека от дикаря. Народ, лишенный истории, превращается в стадо.*

Яхшы закон чыкты татар өчен,
Яшәү күңеллерәк, җиңелрәк:
Татар тарихының, теленең дә
Хәҗәт-фәләне юк, ник кирәк!

Юктыр татар мәдәнияте дә,
Тарихы да чүпкә күмелгән.
Башка халыкныкын өйрән, татар,
Сиңа шушы хокук бирелгән.

Ата-бабаң юньле булганмыни,
Кыргый, ерткыч кына булганнар.
Ярый әле, изге күршеләрең
Дөрес юл күрсәтеп торганнар.

Шуның белән генә син, татарин,
Кешелеккә кабул ителгән.
Күрше генә сиңа акыл биргән,
Ахмак татар җирдә ни күргән?

Синең бар тарихың күршеңнеке,
Үзеңдә юк һичбер мактаныч.
Бөек халык кул астында гына
Син тәүге кат аяк баскан ич.

Гомер бакый шуңа рәхмәтле бул,
Гомер бакый шуңа хезмәт ит.
Җирдә синең башка вазифаң юк,
Аңламасаң, башка җиргә кит!

Туган халкым!
Менә шул тарихны
Балаң өчен куйган әзерләп.
Ата-бабаң рухы нәрсә дияр,
Тарихыңны сатсаң хәзер дә?

Бөек булган синең ата-бабаң,
Шаны бөтен Җирдә танылган.
Әй, бүгенге татар!
Зиһенеңә
Әллә кара япма ябылган?

Күрмисеңме, әллә сизмисеңме,
Тарихыңны мыскыл итәләр.
Үзең өчен үзең тырышмасаң,
Кемгә кирәгең бар, әйт әле!

Мәдәниятеңнең кирәге юк,
Кирәге юк синең тарихың.
Тагын ничә гасыр өйрәнәсең
Башка бер халыкның тарихын?

Милләт,
Әгәр милләт булыйм дисә,
Өләм итә халкы тарихын.
Көч җитәрме, татар,
Туктатырга
Кыргыйлыкка төшеп барышың?

**Һәйкәлләр**

*В Казани собираются поставить*
*памятник Екатерине Второй.*

Әби патша!
Татарларны
Яраткансың, монысы хак.
Безгә кылган «изгелегең»
Мөмкин түгел онытмак.

Ничә еллар тырыштың бит
Урыслашсын болар дип,
Чабаталы (һәм читексез! ),
Тәре таксын татар дип.

Татар үзе гаепле шул:
Көчләп чукындырсаң да,
Ислам динен ташламады
Ач көнгә калдырсаң да.

Мәҗбүр булдың, рөхсәт иттең
Аз-маз мәчет салырга,
Тәре таккан татар белән
Мөселман да калырга.

Әби патша явыз диеп,
Күтәрелгән Пугачев.
Ә син һич икеләнмәдең-
Боердың син:
Ут ачып
Кырып салырга халыкны,
Картын- яшен карамый,
Татарын да, башкортын да,
Чирмешен дә аямый.

Бөек Суворов үзе бит
Монда командир булган,
Ач-ялангач татарларны
Пушкалардан аттырган.

Синең һәйкәлең булгачтын,
Суворовка да булсын;
Ул да татарны кырган бит,
Бик зур һәйкәл куелсын!

Нигә Иван Дүртенчегә
Һәйкәлләр куелмаган?
Аннан да бер бөртек татар
Калган бит суелмаган.

Күбесен үтергәннәр дип,
Кем кайгырсын, ди, бүген?
Бүгенге кешеләр бүтән,
Элекке татар түгел.

Иван солдатларына да
Монумент булсын иде,
Менә шунда укучылар
Караул торсын иде...

Юк Казанда Петрга да
Һәйкәл берәр урамда.
Ул бит куган татарларны
Лашман итеп урманга
(Исән калганнары беткән
Петербурны корганда).

Барысына һәйкәл булсын-
Николайга, Иванга,
Башкаларга.
Бар көч белән
Татарны корытканга.

Шунда гына милләтара
Дуслык ныгая,  имеш...
Тарихың, телеңне, татар,
Югалту- синең өлеш!

Урыс патшалары монда
Һәйкәл булып бассалар,
Берәр татар уйлар микән:
Кайда татар патшалар?

Ничек куясың Казанда
Һәйкәл  татар ханына,
Хезмәте Мәскәүгә түгел,
Булгач үз татарына! ...

Һәйкәлләр күп башкалада,
Юк Казан ханнарына -
Олуг Мөхәммәт, Мәхмүт  хан,
Сафагәрәй, Сөембикә,
Тагын  башкаларына.

Татар  эзле зур тарихта,
Горурланыр хакы бар.
Аның бөек шәхесләре
Һәйкәлләргә  хаклылар.

Дус  бул  күршеләрең  белән,
Тик үзеңне кимсетмә.
Милләтеңне  түбәнсетсәң,
Башкадан дуслык көтмә,
Ихтирам  өмет итмә!

## Татар мәктәбе

*Во всякой татарской деревушке имеется ...*
*школа… в казанских слободах и в больших*
*деревнях  есть подобные сим девичьи школы.*
*Г.И.Георги, 1777 год*

Бар иде, бар шундый чаклар-
Һәр авыл саен  мәктәп.
Татар балалары укый
Ана телендә рәтләп.

Укытучы абыйлар да,
Апалар да үз иде.
Шуклык өчен орышса да,
Тик ягымлы сүз иде.

Шаккатмалы шул мәктәпләр
Милли хисләр ныгытты.
Адашабыз, дигәндә дә
Алга барыр юл  чыкты.

Нәкъ шул авыл мәктәпләре
Бирде кирәкле  белем.
Әллә ничек «сихерләде»,
Китапка ягып җилем-
Башла гына, ычкынмассың,
Бөтен дөньяң шул,  илең.
Мәктәп бирде кулга китап-
Сердәш бәхетем минем.

Мәктәп китаплары белән
Гиздем туган телемдә.
Алар якты кояш булды
Бар караңгы төнемдә.

И мәктәбем! Мин бүген дә
Укыйм сиңа рәхмәтем.
Сине читләп үтсен иде
Бүгенге көн зәхмәте.

Авыл мәктәпләре кирәк
Татар балаларына.
Туган телне алып килер
Соңрак калаларыңа.

Шул мәктәптә татар рухы,
Шунда татарның җаны.
Сакла авылның мәктәбен,
Булса аз-маз вөжданың.

## Атам-анам теле

*Язык народа... не только выражает собою*
*жизненность народа, но есть именно самая*
*эта жизнь. Когда исчезает народный язык,*
*- народа нет более.*
*К.Д.Ушинский*

Кем укымый, дисең, мәдхиясен
Ата-ана теле хакына.
Мин дә укыйм күз яшьләрем аша,
Туган телем өчен ачынам.

Күп чыдады тышау, йөгәннәргә,
Иза чикте телем камчыдан.
Үз ирегеп җуйган, җигелүле,
Авызлыклы телем, ачынам.

Утлы куз салгандай яна, көя,
Көрмәкләнә телем ачудан.
Саф татарча сөйләү оятмыни?
Нәфис телем өчен ачынам.

Ике сүзнең берсе урысныкы,
Кырлы-мырлы сүзләр,  ачыган.
Хәтта Тукай җыры ярты-йорты
Булыр инде, диеп ачынам:
«Точно Заказаньеда бар
Кирлаево селосы.
Мотив өчен надо булса,
Курицалар  җырласы».

Шул әхвәлгә калып бара бүген
Анам теле- татлы бал гынам.
Кайда  синең моңлы үз сүзләрең?
Гүзәл телем өчен ачынам.

Фәкыйрь, мескен, кыйшык-мыйшык бер тел
Булмас борын әйтим, ашыгам.
Үз теленә  татар үзе дошман,
Газиз телем өчен ачынам.

Туган телем саклыйм, дигән уйлар
Килмимени, татар, башыңа,
Синнән башка аны кем сакласын?
Ана  телем өчен ачынам.
Үлем түшәгендә  яткан хәлгә
Килгән телем өчен ачынам.

Бөек идең бит син, горур идең,
Күп халыкка серең ачылган.
Бүген  калдың инде мескен булып,
Изге телем өчен ачынам.

Татар  теле  ерак нәселемә
Барып  җитсен, диеп, борчылам.
Мөкатдәс шул телем яшәсен, дип,
Тезләнепләр кылам баш догам.
Анам телен сакла, и Ходам!
Туган телем өчен ачынам.

**Татар теле кирәкме?**

*Запрещена сдача единого государственного экзамена на языках нерусских народов. Татарам запрещен также переход на латиницу.*

Татар теле бар микән ул,
Әллә инде юк микән?
Аңа хәтта имтиханда
Һич ышаныч юк икән.

Институт ишеге ябык,
Укыйм, дисәң, татарча.
Урыс, инглиз телләрендә
Укып йөри һәр барча.

Тик татарча укымасын,
Бу тел монда хокуксыз.
Аның киләчәге дә юк,
Көче беткән, тотрыксыз.

Урыс теле җитмимени,
Бу дөньяда торырга,
Татар теленә юл биреп
Илнеме таркатырга?

Үзенчәләп язмасын да,
Безнең букварь укылсын.
Диннәрен дә кыскан яхшы,
Нәкъ безнеңчә чукынсын.

Тизрәк бетсә, юкка чыкса,
Шушы халыкның теле,
Бердәмлек тә, дуслык белән
Гөлләнер урыс иле.

И Ходаем, тагын нинди
Сынау яздың телемә?
Болай да бит җитә сыман
Телем соңгы көненә.

Бирче акыл татарыңа,
Ул да синең колың бит.
Күрсәт аңа туп-туры юл,
Менә синең юлың, дип.

Шул юл белән киләчәккә
Армый-талмый атласын.
Тәңре биргән изге телен
Гомер бакый сакласын.

И татарым!
Шушы гүзәл
Ата-бабаңның телен
Бер югалтсаң, каргар сине
Килер буын нәселең.

### Коллык галәмәте

*Я шаху не раб и рабом не стану!*
*Лишь только пред Всевышним рабом я предстану.*
*Кол Гали. «Кыссаи Йусуф»*

Кол булырга күнеккәнсең бугай,
Хатирәләр әле исәнме-
Үзең тотып бирдең дошманыңа
Ханбикәңне Сөембикәңне.

Бәлки аның ачы күз яшьләре
Сиңа каргыш булып төшкәндер.
Бәлки, шуңа купкан зилзиләләр,
Усал җилләр каршы искәндер.

Тирә-юнең дөм караңгы чакта,
Юлсыз калганда да аптырап,
Барма  хыянәткә –гүр газабы,
Гүрдә булмас җирдән яктырак.

Шундый караңгы чор килгәндә дә,
Барлык өмет  беткән әхвәлдә:
Коллар буласым юк, диеп кеше,
Яшәү юлын таба һәрхәлдә.

Давыл чыкса, җилне  җил куар,
Коллардан бит тагын кол туар.

Коллык гадәтеңне җиңәрсеңме,
Үз-үзеңне саклап каламсың?
Синдә, татар, акыл җитәрлек бит-
Татар булсын  татар баласы.

И милләтем, мин бит синең балаң.
Бөтен кимчелегең миндә   бар.
Килер буыннарым азат булсын,
Горурлансын иде: «Мин –татар!»

Әгәр шул  өмет тә булмый икән,
Яшәү, гомернең юк кирәге.
Татар булып тудым, үстем, яшим,
Татарлыгым- яшәү терәге.

И татарым, и син газиз халкым,
Киләчәгең бармы бу  җирдә?
Сакларсыңмы гүзәл татар телен
Һәм үзеңне гомер-гомергә?

## Татарлык хасияте

*Когда нацисты пришли за коммунистами,*
*я молчал...Потом они пришли за социалистами,*
*я молчал...Когда они пришли за мной, больше*
*не было никого, кто бы мог протестовать.*
*Мартин Нимёллер*

И миллəтем,
Җан əрнүле сүзлəр
Үпкəлəми генə кабул ит.
Үз татарың ачы хакыйкатьне
Ачмаса соң, читлəр ачмый бит.

Ваз кичəсең сыман үз телеңнəн,
Мəдəният ярым читнеке.
Богау салып, ябып куяр өчен
Үзең əзерлисең читлекне.

Үз-үзеңне аклар өчен генə
«Дуслык» дисең, авыз тутырып.
Дуслык – ике яклы ихтирам бит,
Эчү түгел, бергə утырып.

Синең телең, рухи байлыгыңны
Танымаса, дуслыкмыни ул?
Телең, тарихыңны мыскыл итсə,
Дустанə бер тиңлекмени ул?

Син барсына риза, «Дуслык,- дисең,-
Без бит, - дисең,- бергə тоташкан».
Шул тоташкан дустың үзлегеңне
Ничə гасыр җуя тоташтан?!

Рəхəтлəнеп үзең кушыласың
Миллəтеңне җую эшенə.
Гадəтең шул:
Татар читне мактар,
Һич юл бирмəс үзе ишегə.

Дустым канәгать булсын,  диеп син
Үз халкыңнан үзең көләсең.
Шул каһкаһә белән көлүеңә
Ялган  дус  кушыла, беләмсең?

Борынгылар инде күптән әйткән:
«Татар,- диеп,- ашар татарны».
Хәтта җанварларда мондый хәл юк,
Бүре үз бүресен ашармы?

Гүзәл туган телдән, тарихыңнан,
Үзлегеңнән һәрчак ваз кичсәң,
Вакыт  җиткәч, кемгә таянырсың,
«Татар булып калыйм мин», -дисәң?!

Әгәр милләтемне саклыйм, дисәң,
Татарлыкны яклау кирәктер.
Башка халыклар бит аңлый шуны!
Безнең кебек гамьсез сирәктер.

Бала сөя татар, бала бага,
Ләкин татар түгел баласы.
Бүтән халыкларга кан яңарта
Татар атасы һәм анасы.

Үз милләтен якын итми торган,
Ятны гына читкә какмаган
Халык
Берчак  япа-ялгыз калыр.
Табылмас бер аны яклаган.

Тирә-ягы коры буш чүл кебек,
Ни якыны булмас, ни терәк.
Тере  түгел, ул  үле дә түгел,
Андый бәндә кемгә, ник кирәк?

## **Идел-Урал йорт**

*Здравствуй, Идель, Отчизна-Дом!*
*Мир да будет в Доме родном!...*
*О мой Дом, желанный мой Дом*
*Между Иделем и Яиком!*
*Народный эпос «Идегей»*

И туган йорт, Идел-Урал йорт,
Иркен дала, куе урман йорт.
Кыя таулар, җитез дәрьялар,
Гомер бакый татар торган йорт.
Шушы җирне сөйгән татарлар,
Ераклардан сагынып кайталар.

И туган йорт, изге туган йорт,
Ата-бабам иген иккән йорт.
Тәкъдир язган гомер беткәндә
Бабам мәңгелеккә киткән йорт.
Миннән алдагы бар өммәтем
Кабул иткән бу җир һәммәсен.

И туган йорт, хуш ис тулган йорт,
Әткәм-әнкәм гомер сөргән йорт.
Нәселемнең бәхет оясы,
Шашып гөлчәчәкләр үргән йорт.
Шунда калды тәпи эзләрем,
Чыккан тәүге татар сүзләрем.

И туган йорт, туган-үскән йорт,
Татар диеп үзем тойган йорт.
Халкым җыры белән сихерләп,
Җанда тирән эзләр уйган йорт.
Татар телен шунда иңдерде,
Туган телем яшәр көч бирде.

И туган йорт, гүзәл туган йорт,
Яшел хәтфә назлы юрган йорт.
Чит яуларга башын имичә,
Татар үз дәүләтен корган йорт.
Гүзәллегең күреп туймадым,
Чит җирдә дә сине уйладым.

И бердәнбер газиз туган йорт,
Татарына Ходай биргән йорт.
Ачы кайгысын да, хәсрәтен,
Шатлыгын да халкым күргән йорт.
Сакла, татар, илне гомергә,
Башка туган илең юк Җирдә.

И туган йорт, Идел-Урал йорт,
Сайрар кошлар килеп кунар йорт.
Үзең якла, сакла барысын,
Туган җирнең һәрбер карышын.
Илеңнән дә мәхрүм итсәләр,
Газиз халкым, кая барырсың?

## ТУГАН- ҮСКӘН ЯКЛАРЫМ

### Шул якларга сәлам

Шул якларның урман, болыннарын,
Басуларын беләм электән.
Кар-буранлы кырыс юлларын да
Үткән идем үзем яшьлектә.

Җырлап йөргән идем кырларында,
Байтак эчтем татлы суларын.
Монда юк шул алар.
Барысы да
Тик хәтердә генә нибары.

Шул якларга барып кайтам хәзер
Тик бер төштә генә күргәндә.
Шул якларга сагыш, сәламемне
Җиткерегез җае килгәндә.

## Кайтыр юллар

Юлларның иң күңеллесе-
Өйгә кайта торганы.
Тизрәк кайтыйк, тизрәк җитик,
Әйдә, чаптыр юрганы.

Ат тоягы кышын карны,
Җәен тузан туздырыр.
Җил җилләтеп, очар гына,
Ул да өйгә ашкыныр.

Тау башына килеп җиткәч,
Авылым да күренер.
Назлы иркә җилләр иссә,
Ул авылым җиледер.

Сулда чыршы урманнары,
Юл буенда каеннар.
Тау арасы җиләк-җимеш
Тулы,
Адым саеннар.

Ерак түгел Агыйделем
Дулкыннарын уйната;
Кышын булса, боз астында
Җәйләрне көтеп ята.

Башка яктан кайтыр булсаң,
Урман, болын аша юл.
Зиреклектән чыгу белән
Ялтырап тора авыл.

Кайсы юл да җанга якын,
Өйгә кайта торганы.
Күңелгә хуш кышкы кар да,
Җәйдә тузган тузаны.

Сагындырды болыннарым,
Урманнарым, кырларым.
Бик сагындым
Өйгә мине
Алып кайтыр юлларым.

## Идел-Урал яклары

Кай яклардан син?-
Дип сорасагыз,
Мин Иделләр, Урал ягыннан.
Күкләренең балкыр зәңгәрлеге
Минем күзләремә ягылган.

Онытырлык түгел һичбер вакыт,
Күз алдымда бала чагымнан:
Гүзәллеге белән туган ягым
Аермасыз гөлләр багыннан.

Исләремдә язгы хистән ярсып
Сабан тургаеның сайравы;
Җиткән иген исен аңкытып
Җил
Алтын башакларны барлавы.

Монда якын итеп кенә шаулый,
Шомлы тоелса да карурман.
Өс-баш талап,
Өзгәләми монда,
Мәрхәмәтле хәтта чытырман.

Яшел түбәтәен кигән таулар
Башын югарыга күтәргән.
Бөркетләре канатларын кага
Биеклеккә очып китәргә.

Колачларын җәйгән Иделләрем,
Җем-җем итә көмеш сулары.
Дулкыннары белән
Уйный-уйный
Көн уздыра кояш нурлары.

Кышын ап-ак карлар ябына җир,
Боз астында сулар басынкы.
Йокымсырап  кына көч туплыйлар
Гөрләшергә,
Җиткәч вакыты...

Кай яклардан син?-
Дип сорасагыз,
Мин  Иделләр, Урал ягыннан.
Кайда йөрсәм, кайда яшәсәм дә,
Гүзәл туган якны сагынам.

## Зимагур

*Авылыма*
*Зимагурлары да үз аның.*
*Роберт Миңнуллин*

Ниһаять, мин туган авылымда.
Байтак еллар кайткан булмагач,
Читсенгәндәй бераз шаулап куйды
Ботакларын җәйгән алмагач.

Балачакта уйнап үскән урам
Киң дә, иркен иде шул вакыт.
Хәзер никтер тап-тар.
Китеп барам
Комлы сукмак буйлап, шаккатып.

Ихаталар элеккечә түгел,
Таныш түгел өйләр урамда.
Аптырыйлар бугай, ят кеше дип,
Кызыксынып карап торганга.

Менә туган өем.
Ул да башка.
Карашында аның үпкәлек.
Мөлдерәмә яшьле тәрәзләре
Моңсуланып карый текәлеп.

Мин дә карыйм, сөйлим хәлләремне,
Бакча коймасына сөялеп.
Койма боек,
Кузгаласы түгел
Китәремдә миңа ияреп.

Син рәнҗемә инде, туган өем,
Ел да кайтып булмый, бер киткәч.
Менә кайттым бик сагынып сине,
Авылымны,
Ямьле җәй җиткәч.

Ышанырдай, ышанмастай өй дә,
Тып-тын урам мине тыңлыйлар.
Капка гына бер шыгырдап куйды,
Ишетелде тирән моңлы зар.

Кинәт кояш чыкты күктә көлеп,
Нурларыннан өйләр балкыды.
Җаннарыма шифа
Елмаешкан
Тәрәзләрнең ачык ялкыны.

Назлап карый миңа туган өем,
Үз иткәндәй туган авыл да.
Тылсымлы наз барда
Зимагурны
Ега алмас усал давыл да.

Миндә зимагурның язмышлары,
Чит илләрдә йөргән юлларым.
Кайда булсам да бит,
Оныталмыйм
Туган җирдә йөрер юл барын.

## Тауларым

Таулар моңсу карап тора сыман,
Никтер тынып калган тауларым.
Әллә инде алар хәтерлиме
Моннан үткән дошман яуларын.

Таулар, ахры, искә төшерәдер
Туган якның батыр улларын.
Миңа җирдә ирек булсын өчен
Алар түккән монда каннарын,
Монда биргән газиз җаннарын.

Таулар миңа пышылдыйлар кебек,
Онытма, дип, атаң-бабаңны,
Авырлыкка бирешмәгән алар,
Саклап калган халкын- татарны.

Мәңгелек бер мәһабәт көч белән
Басып тора гүзәл тауларым.
Әллә нинди таулар бирсәләр дә,
Урал булыр минем сайларым.

## Кайтам әле авылыма

Туган- үскән авылыма,
Кайтсам, танылыр микән?
Кендек каным тамган урын
Хәзер табылыр микән?

Ялан тәпи тәүге баскан
Җир һаман йомшак микән?
Гөрләп үскән үләне дә
Гүяки түшәк микән?

Бергә уйнап үскән дуслар
Кайда  икән, кем икән?
Минсез урам, аз булса да,
Китек микән, ким микән?

Рәхәтләнеп без чокынган
Комнар әле дә бар микән?
Элек бик киң иде  урам,
Хәзер киңме, тар микән?

Челтерәвек көмеш сулар
Бүген дә татлы микән?
Урманнары элеккечә
Чыршы, наратлы микән?

Без үрмәләгән агачлар
Берәрсе  калды микән?
Җәйләр һаман чиксез гүзәл,
Кышлары карлы микән?

Язда кошлар сайрый-сайрый
Канат кагына микән?
Читкә киткәннәр авылын
Миндәй сагына микән?

Бабаларымның  нигезе
Әле дә исән микән?
Ихатада  хуш ис үлән
Әле дә үсә микән?

Үзгәрде микән авылым?
Күпме еллар үтте бит.
Еллар түгел, бөтен гомер
Җилдәй үтте-китте бит.

Барыбер кайтырмын сиңа,
Туган-үскән авылым.
Кайтмый ничек түзмәк кирәк,
Кайтам.
Бигрәк сагындым.

**Туган ягым**

Туган ягым- иркә бишек,
Күземне ачкан түрем.
Озын юллар үтәр өчен
Тәү тәпи баскан җирем.

Туган ягым күге биек,
Канатлар каккан илем.
Әгәр аннан көч алмасам,
Мин ничек очар идем?

Туган ягым моң чишмәсе,
Тәүге җырым шыткан кыр.
Туфрак шифалы булганга
Җырлар үсеп чыккандыр.

Туган ягым -
Ата-бабам
Түккән тир, аккан каны.
Саклый мине догалары,
Иманлы изге җаны.

Туган ягым гүзәл төбәк,
Күреп туймас тансыгым.
Онытмам беткәнче бушап
Тәкъдиремнең янчыгы.

## Сагыну

*Казаклар авылы карты сагышы*

Күзләр камашырлык чәчкә шавы,
Йөрсәм иде искә исереп.
Әрәмәне бер аралар идем,
Яшьлегемне искә төшереп.

Гүзәл Имән- Җилән  болынында
Алсам иде кулга чалгымны,
Йөрәк җилкендереп печән чабу
Таратыр иде бар кайгымны.

Гармунымны тартып урам буйлап
Үтәр идем шунда кайтканда.
Җырларымны тыңласыннар иде
Япь-яшь  кызлар
Йокы качканда.

Тик бер генә мәлгә кайтсам иде,
Әллә кайчан үткән көннәргә,
Туган  авылыма, яшьлегемә
Төштә генә түгел, өннәрдә.

## Көянтә

Авылыннан таңда чыккан егет,
Карамаган салкын, карына.
Бер көянтә алыйм бүләккә, дип,
Килен булып төшәр ярына.

Көянтәнең иң матурын эзләп,
Базар айкап, озак сайлаган.
Кәләшемә бик хуш килер, диеп,
Алып кайткан берсен каладан.

Күзең камашырлык бизәкләре,
Үзе җиңел, иплe икән бу.
Чишмәләргә суга барыр өчен
Ашкындырып тора икән бу.

Гүзәл килен суга киткән чакта
Көянтәләп яңа чиләкләр,
Яше-карты догаларын укып,
Теләп калган изге теләкләр.

Тау астында салкын чишмә ага,
Татлы суы таныш авылга.
Мөлдерәмә чиләк,
Тамчысын да
Түкми генә алып кайтырга.

Шатлык белән барган сылу килен
Җырлый-җырлый чишмә суына.
Күпме еллар шул көянтә белән
Баскан икән чишмә юлына...

Келәттәге чөйдә шул көянтә-
Әнкәм истәлеге, яшь чагы.
Хәзерге яшь килен иңнәренә
Асмас инде аны бер тагын.

Никтер сулар тамган көянтәгә,
Әйтерсең лә, яше коела.
Үткәннәрне сагынып елагандай,
Ямансулый кебек тоела.

## Ата-бабам нигезе

Кайтып җиттем ата-бабам нигезенә,
Булмады юл якын, туры, тигез генә.
Ата-бабам шул нигездә гомер сөргән,
Шатлыгын да, кайгысын да шунда күргән.

Шул нигездән чыгып киткән киң юлларга
Балалары,
Бәхет эстәп еракларга.
Шул нигездә үтте минем балачагым,
Кайту бәхетләре тиде менә тагын.

Саумы, туган өем, диеп, бакчаларым,
Берәм-берәм кочар идем агачларын.
Әйтерсең лә, алда әткәм басып тора,
Озак йөрдең, дигән сыман тамак кыра.

Җил капкадан әнкәм чыгар күк тоелды,
Богазыма бер чеметем ком тыгылды.
Апаларым килер кебек йөгерешеп,
Көлә-көлә узышкандай берсен-берсе.

Абзыем да карап тора түгелме соң?
Күзләремә тагын кемнәр күренмәсен...
Юк шул берәве дә, калды истә генә,
Миңа каршы чыгалар шул төштә генә.

Хуҗалары булмагачтын күптән өйдә,
Нигез ничек төзек торсын, ыспай көйгә?
Тәрәзәләр кыек, күпме хәсрәт күргән,
Ихатада чүп-чар, койма җимерелгән.

Чүп үләннәр баскан бакча ятим сыман,
Алмагачлар күптән инде корган, сынган.
Ачы кайнар яшьләр тулды күзләремә,
Ничек табыйм көч шул хәлгә түзәремә?

Еларсың да, тыялмастан үз-үзеңне,
Әгәр күрсәң ташландык үз нигезеңне.
Рәнҗеп ятма, изге нигез, язмыш шулай
Еракларда гомер буе йөртә бугай...

Башкаларга миһербанлы булсын тәкъдир,
Хак Тәгалә балаларга итсен тәэсир.
Атаң нигезендә яшәү бәхетләрен
Бирсен Ходай.
Шулдыр сезгә теләкләрем.

## Кайту белән китү

Кайтып барам әле туган якка,
Вагоннар да  гүя шатлыклы.
Так-так итеп чаба, йөгерәләр,
Сизә бугай минем шатлыкны.
Тәгәрмәчләр дә бит ашкындылар,
Кайтам - кайтам,
Диеп ашыкты.

Ерак юлны якын итеп кайтам,
Туган илем, шундый сагындым!
Йөрәгем дә ярсып-ярсып тибә
Сиңа якынлашкан чагымда.
Күзләремне алмый карыйм һаман
Текәлепләр тагын-тагын да.

Каршы  ала мине урманнарым,
Ялтыравык сулы Иделем,
Көләч йөзле газиз милләттәшләр
Аңлый минем чит зат түгелем.
Кайда барсам, шунда колач җәеп
Күрсәтәләр керсез күңелен.

Ишетелә атам-анам теле,
Татар җыры, милли көйләрем.
Тәрәзәләр көлеп, балкып тора,
И кунакчыл инде өйләре.
Хуш исләрне  генә алып килә
Туган якның  иркә җилләре.

Китәр вакыт бик тиз килеп җитте.
Әйбер-мазар әзер, җыелган.
Күңел боек, кәеф төшенкедер,
Аерылулар бигрәк кыен ла.
Туган җирдә үткән һәрбер мизгел
Мәңге калыр минем уемда.

Моңсуланып кына озаттылар
Тәрәзәләр-тоның күзләре,
Түбәсеннән аксыл-зәңгәр яулык
Болгый-болгый калды өйләре.
Яфраклары шаулы алмагачлар
Тагын кайтуымны теләде.

**Яңгыр**

Күкнең йөзе сөремләнгән бүген,
Кара таңнан ага яшьләре.
Ишетелеп кала күк күкрәве,
Тик күренми яшен яшьнәве.

Җирдән күккә кадәр су коймасы,
Тоташ койма, юк бер капкасы.
Бу яңгырны туктатыр көч юктыр,
Бозылгандыр күкнең капкачы.

Яңгыр ява, котырынып ява,
Бер еллыгын коя, күрәсең.
Чыгам дисәң, тышка чыгалмассың,
Диңгез иткән өйнең тирәсен.

Бетмәс-төкәнмәслек микән сулар,
Әллә каян күккә җыелган.
Бу кадәрен җир дә сыйдыралмый,
Көннәр буе күктән коелган.

Коя яңгыр, әле һаман коя,
Сулар ага урам шаулатып...
Гомер буе шулай яумас әле,
Туктар әле яңгыр бервакыт.

## Күк арбасы

Дөбер-дөбер китте күктә арба,
Әллә чокыр-чакыр юллары;
Әллә арбасы  да ватык-потык,
Тәгәрмәчнең сынган сыңары.

Әллә  инде  күкнең арбасына
Иске тимер-томыр төялгән.
Йә арбакеш такыр юлны ташлап,
Күзе төшкән якка юнәлгән.

Чакма таштай чаткы ялтырый да,
Күк арбасы тагын дөберди.
Әрдәнәләре дә  аркылыга
Кыйшык түшәлгән бер күпердәй.

Соңрак арба тынды, күк ачылды,
Яңгыр  бүген   никтер яумады.
Әй яумаса, яумас ,
Җитәрлек бит
Кичә  генә коеп яуганы.

## Урман аланы

Урман уртасында алан,
Чыклары да кипмәгән.
Кояш әле биек түгел
Күтәрелгән иртәдән.

Яңа ачыла башлаган
Гүзәл чәчәк таҗлары.
Ялтыр -йолтыр карый күзгә
Шуннан су тамчылары.

Бер чәчәктән бер чәчәккә
Күбәләкләр уйныйлар.
Күңелле бит очулары,
Туктап кунып тормыйлар.

Чәчәкләрдә чык кибүен
Көтә алар, мөгаен.
Якты көнгә, гүзәллеккә
Куана, тапкач җаен.

Агач яфраклары белән
Кояш нуры уйнаклый.
Җилләп китә йомшак кына,
Йоклар булсаң, уятмый.

Чәчәкләрнең хуш исенә
Тәмам исердем бугай.
Шушы кадәр гүзәллекне
Ничек яраттың, Ходай!

## Сукмаклар

Беленердәй-беленмәстәй генә
Эзләр белән сукмак башлана.
Туры гына бармый, әле уңга,
Әле сулга табан ташлана.

Боргаланып-сыргаланып кына
Урман, кырлар барлый бу сукмак.
Армый-талмый һаман йөгерә ул,
Бераз ял да итми бер туктап.

Эзли-эзли баргач, табыла да
Үзе кебек ялгыз сукмагы,
Шатланыша ике сәяхәтче,
Бәхет тулы туган туфрагы.

Сукмакларны сукмак олыгайта,
Куәтләнеп болар аннары
Бергә-бергә китә,
Еракларга
Алып бара салган юллары.

Кайбер сукмак үзе ялкау була,
Эзләми дә кырда тиңдәшен.
Олы юлга тизрәк сыена ул,
Таба белми юлдаш, иптәшен.

Бик бәхетсез сукмак ялгыз кала,
Бара-бара, мескен, югала.

## Көзге яфраклар

Агачларга ялкын капканмыни,
Җем-җем итә кояш нурында
Көзге яфрак,
Нәни бала кебек,
Селкенмичә булмый торырга.

Җилләр иссә, очкын-очкын булып,
Төрле яфрак уйный, шаяра.
Әле генә кызыл яфрак иде,
Яшкелтемен тапкан кай ара?

Салют биреп, күккә омтылалар
Аксыл-сары, көрән- кызгылты,
Аксулары, коңгырт, чуарлары,
Шәмәхәсе белән соргылты.

Җиргә төшәргә бик ашыкмыйлар,
Очып йөри күктә кайгысыз.
Иркәләнә, бөтерелеп бии
Җилләр кочагында ваемсыз.

Сокланырлык яфрак уеннары,
Искитәрлек төстә барысы.
...
Башкаема ап-ак карлар яуган,
Минем кышым җитте, ахрысы.

## Карлар ява

Тирә-ягым өнсез калган,
Җил дә юк, тыныч һава.
Болыт арты болыт ага,
Яфрак-яфрак кар ява.

Бәйләгән ак яулык каен,
 Япь-яшь килен диярсең.
Күпләп карлар яусын әле,
Аппак бүрек киярсең.

## Ай уйный

Күктәге ай минем белән
Качыш уйный үзенчә:
Бер югала, бер күренә,
Шаяра  шул көенчә.

Йөгереп  кереп кача да
Бер болытның артына,
Күренмичә генә тора
Күп тә түгел, аз гына.

Шук малайдай качып тора
Түземлеге  җиткәнче,
Алдындагы шул болыты
Үтеп кенә киткәнче.

Ялт итеп ул килеп чыга,
Көлеп минем каршыма.
Аннан кабат яшеренә
Кара болыт артына.

Дөм караңгы булып кала,
Бернәрсә дә күренми.
Айның кайда икәнлеге
Бөтенләй дә беленми.

Бик көттереп ул, ниһаять,
Күренә авыз ерып.
Саранланмый  чәчә җиргә
Мул итеп көмеш нурын.

Бөтен дөнья сихри нурга,
Яктылыкка күмелә.
Шул чагында бу төне дә
Ачык көндәй күренә.
Ә ай тагын качыш уйнап
Болытларга үрелә.

## Ак каен

Ак каеннар зифа буена
Озын күлмәк кигән аппак, саф.
Никтер ак күлмәкләр өстенә
Төшкән икән кара вак-вак  тап.

Ак  каенга барып сорадым,
Нигә таплы, дип ак күлмәгең,
Кер күтәрми бит ул ак кием,
Әллә инде шуны белмәдең?

Белсәм дә мин, үзем сайладым
Күлмәгемне,- диде бу каен,-
Шундый ук ак, саф-пакь бәхетне
Бирсен өчен миңа Ходаем.
Бәхет кенә түгел дөньяда,
Кайгы- хәсрәте дә бар аның;
Күлмәгемдә һәр тап- бер кайгы,
Бер хәсрәте шушы дөньяның.

## Ак болыт

Җил улатып усал давыл килә,
Офыкларны кара каплаган.
Тоташ яулар булып өерелә,
Күктә бер ачык  җир калмаган.

Табигать тә куркып китте бугай,
Тыз-быз оча кошлар борчылып.
Ә бу якта һич ваемсыз йөзә
Бер кечкенә генә ак болыт.

Әллә өметләнә микән үзе
Давыл читләп үтеп китәр дип,
Әллә уйламастан  әтәчләнә,
Давылларга көчем җитәр дип.

Әй ак болыт, бераз читкә тайпыл,
Давыл йотар сине жәлләми.
Шул давылга каршы көрәшерлек
Әле көчең дә юк әллә ни...

Кара  давыл белән бил алышкан
Батырлыкны мактау гадәттә.
Тик гел куркакмыни чигенүче?
Төпле акылның бер күрсәткече-
Чигенә белү кирәк сәгатьтә.

## Яз җитте

Яз җитте, күк зәңгәр,
Якты кояш нуры
Иркәләп кул суза
Югарыдан туры.

Карлар, бозлар эри,
Тамчылары тама.
Берсен-берсе куып,
Гөрләвекләр ага.

Кошлар очып кайтты
Ерак-ерак җирдән.
Табигатькә  көләч
Бәйрәм төсе кергән.

## Гүзәл яз

Киткән кошлар кайта, язлар җиткәч,
Гөрләвекләр белән бергә.
Якты кояш йөзә зәңгәр күктә,
Назлап нурын сибә җиргә.

Шытып чыга, калка умырзая,
Тиздән карлар эреп бетә.
Күзләр камашырлык  яшел хәтфә
Келәм
Җирне каплап китә.

Сирень, алма, чия чәчкәләре
Зәңгәр, көрән, алсу төсле.
Тирә- юньгә тулган, аңкып торган
Һич туймаслык чын хуш исле.

Бар дөньяны уятам дип, язлар
Күк күкрәтә яшен белән;
Ашыктырып җанлы- җансызын да,
Картларын да, яше белән.

Яңа тормыш башларга да әзер
Бар табигать күзен ача.
Ашыга ул елдам эш башларга,
Кышкы йокылары  кача.

Язлар белән килә зур өметләр,
Шифалыдыр язгы җил дә
Һәр яз гүзәл.
Ләкин язларның да
Иң гүзәле туган җирдә.

## Яз көннәре

Кышкы салкын киткән,
Кояш көлә күктән.
Нурга чумган дөнья,
Яз көннәре җиткән.

Кошлар оя ясый,
Чыбык-чабык ташый.
Кояш белән яңгыр
Соңгы карны ашый.

Гөрләвекләр ага,
Биек зәңгәр һава.
Көннәр борды йөзен
Эссе җәйгә таба.

## Колын

Ямь-яшел үләнле болын,
Уйный шаян бер колын.
Йөгереп -чабып китә ул,
Җилфердәтеп койрыгын.

Күктә кояш, җирдә чирәм,
Яшәү рәхәт, болын киң.
Сикереп тә ала колын,
Кешнәп куя:
«Менә мин!»

## Күбәләк

Җирдә бер көн генә яши торган
Күбәләккә карыйм кызыгып.
Шундый бик аз гына яшәүнең дә
Таба берә бит ул кызыгын.

Очып килеп куна бер чәчкәгә,
Анысыннан күчә башкага.
Күбәләк бер көндә бу җирдәге
Язган бөтен эшен башкара.

Гомер буе эше белән мәшгуль,
Үз күңелен үзе хуш кылып.
Бүген кәеф начар, эшем бармый,
Дип утырмый, кулын кушырып.

Гомерләрем кыска дип уфтанмый,
Өлгерәлмим дип тә зарланмый.
Кояшлы көн булса бик канәгать,
Яңгырларны гына яманлый.

Күбәләккә баксаң, безнең гомер
Ничә мең мәртәбә күбрәктер.
Шуны юкка-барга таратмыйча,
Шатланышып яшәү кирәктер.

Бер уйласам, гомер байтак икән,
Тик белмибез, ахры, кадерен...
Юкка гына сарыф итәбез бит
Күпме күбәләкнең гомерен.

## Урман юлында

Пөхтә, зифа ак каеннар
Тезелгән юл буена.
Авылымда җыелгандай
Кызлар кичке уенга.

Ыспай кием өс - башында,
Кояш нуры чагыла.
Җем - җем итә бизәкләре
Җилләр искән чагында.

Ачык - яшел күлмәкләре
Ялтыр - йолтыр төймәле.
Аякларда  ап - ак читек,
Кызгылт - сары чикмәле.

Якут  ташлар, энҗе - мәрҗән
Боларның калфагында.
Тыйнак кына көлешәләр
Шул кызлар кайчагында.

Каршы якта яшь наратлар-
Бөдрә чәчле егетләр.
Менә - менә тыпырдатып
Биеп китәр кебекләр.

Күн итекләр аякларда,
Төп - төз таза гәүдәләр.
Сизелеп тора
Гайрәтле,
Кыю егетләр мәгәр.

Кызлар түгел, егетләр бит,
Көлешәләр шаулашып.
Шаярышып, бер - берсенә
Сугып куя шап та шап.

Тик бер нарат шаян түгел,
Чыжлап кына җилләрдә
Курай булып яңгырата
Моңлы  җыр күңелләрдә.

Моңланып, бер мизгел кызлар,
Егетләр дә тын кала.
Яшьлек бит ул !
Тиз арада
Яшьлегенә кайталар.

Яшел ефәк шәлләренә
Кызлар йөзен яшерә.
Ә үзләре сиздермичә,
Егеткә күз төшерә.

Егетләр турыдын - туры
Яшь кызларга карыйлар.
Карашларда йөрәк сере,
Назлы сөю - бары бар.

Эх, арада юл булмаса,
Чыгар иде биергә
Егетләр дә,  кызлары да,
Йә парлашып, йә бергә.

Булмый гына,
Урман юлы
Арада бер киртә шул...
Кавыштыра, аера да
Юллар.
Язмыш йөртә шул.

## Алтын туй чәчәге

Су буенда алтын-сары хәтфә палас,
Күзләр камашырлык  энҗе-мәрҗән, алмаз.
Йомшак  җилләр гөлнең башын иеп китә,
Чәчкәләре  елмаешып җем-җем итә.

Сары чәчәк үсмәгән,  ди, элек монда.
Яшәгән, ди, яшь балыкчы су буенда.
Аның сөйгән яры булган, ди, бай кызы,
Кавышуга һич форсат юк, байдан узып.

Ярлы балыкчыны бу бай тиң күрмәгән,
Кызына ул башка  бер туй әзерләгән.
Ләкин  егет һәм кыз вәгъдә бирешкәннәр,
Аерылудан үлем артык, диешкәннәр.

Су буена килгән алар икәү бергә,
Алтын-мәрҗәннәрен  яшь кыз сипкән җиргә.
Бер-берсенә әйткән болар серен-уен,
Синең белән булыр диеп, алтын туем.

Кул тотышып кереп киткән  су эченә,
Биек дулкын- уртак чатыр икесенә.
Бераздан соң сулар тынган, дулкын сүнгән,
Егет һәм кыз җирдә бүтән күренмәгән.

Алтын чәчкән җирдә  гөлләр үсеп чыккан,
Алтын- ачык сары  гүзәл чәчкә аткан.
Саф мәхәббәт  эзе булып калган алар,
Алтын туй чәчәге диеп аталганнар.

## Туган якның инеше

Челтер-челтер бер кечкенә инеш
Үлән арасыннан үрмәли.
Бер югалып кала, тагын чыга
Юллар сала күрер-күрмәле.

Кайбер киртәләрне ерып уза,
Әйләнеп тә уза кайберсен.
Армый-талмый алга омтыла ул,
Нигә ашыгадыр, кем белсен.

Бара-бара бүтән инеш очрый,
Кушыла да икәү,
Аннары
Кулга кул бирешеп ары китә,
Зуррак инде салган юллары.

Башка инешләр дә очрап тора,
Бер елгачык инде бу хәзер.
Күмәк чөкердәшү күңелле бит,
Киртә ерулар да бергәдер.

Елгаларга көчен куша елга,
Дулкыннарын куа бу дәрья;
Ургылыплар ага, ашкынадыр
Диңгезенә барып җитәргә.

Яр комына чыгара шул диңгез
Суларының тозлы, ачысын.
Шушы суда тоям чишмә тәмен,
Ерактагы инеш тамчысын.

Җәйрәп яткан диңгез назлый мине,
Тибрәтә дә сөеп, иркәләп.
Туган якның инеш, елгалары
Сәлам бирә миңа иртәләп.

## ХӘТЕР ЯНЧЫГЫН АКТАРГАНДА

### Нигә?

Нигә килдем икән шушы җиргә,
Ник туганмын якты дөньяга?
Нигә биргән миңа шундый йөрәк,
Туктаусыз көн яна, төн яна?

Нинди өмет баглап, атам-анам
Тагын бер балага җан биргән?
Егылырда ничек табылган соң
Ныклы терәк миңа һәр җирдән?

Нигә насыйп булды озын гомер,
Аклы һәм каралы бер язмыш?
Ник сынады икән җәлләмичә
Мине газиз бердәнбер тормыш?

Бирде Аллам чиксез шатлыклар да,
Ачы кайгы, югалтуларын.
Күрсәткәндер, тагын баш күтәреп,
Атлап, басып китәр юл барын.

Югарыдан күзәтәләр сыман
Егыла-тора дөнья куганым.
Никтер мин дә кирәк булдым, ахры,
Никтер бит бу җиргә туганмын.

Бакый дөнья һаман алмый әле,
Бәлки бардыр тагын кирәгем.
Башкаларга файда китерергә
Җитәр микән хәзер егәрем?

## Ай-һай дөнья

Ай-һай дөнья, күрсәттең син
Ачысын да, төчесен,
Сөюләрнең иң татлысын,
Хисләрнең иң көчлесен.
Зәңгәр күккә очырдың да,
Җиргә бәреп төшердең.
Ач- ялангач калдырдың да,
Затлы шәраб эчердең.

Ай-һай дөнья, минем дә бит
Үз хыялым бар иде-
Тик бер генә була торган,
Үземә тиң яр иде.
Алдың сөйгән ярымны син,
Калдырдың  ялгызымны.
Сүндердең  күктәге минем
Бердәнбер  йолдызымны.

Ай-һай дөнья, киртә куйдың
Алларыма китереп,
Талар өчен этләреңне
Җибәрәсең  өстереп.
Бер юктан да улатасың
Усал өермә буран,
Таудай көртләр өеп юлга-
Мин алга бара торган.

Ай-һай дөнья, бөктең, сыктың,
Тик барыбер юк үпкәм.
Бар кайгысы, бар шатлыгы
Гомердә булган, үткән.
Китәр вакыт җиткәч, тагын
Ай-һай дөнья,  диярмен,-
Күп күрсәттең, шуңа рәхмәт,
Дип башымны иярмен.

## Гөнаһлы бәндә

*Адәм булып туган өчен генә*
*Мин гөнаһлы икән Җирдә нигә?*
*Ә.Синугыл-Куганаклы*

Җан иясен Җиргә китерәләр
Кылмасын, дип, һичбер гөнаһны.
Ләкин никтер гел гаепле кеше,
Тумышыннан башлап гөнаһлы.

И Ходаем, үзең яраткансың
Миндәй бер бичара бәндәңне.
Тумыштан ук ул гөнаһлы булгач,
Күрәмени Җирдә бар ямьне?

Гөнаһлы дип алдан бәялисең
Аның кылыр эшен барысын.
Тумыштан  ук ул гөнаһлы булгач,
Мәхәббәтне ничек танысын?

Шул бөек хис тәмен татырга да
Кирәктер бит Җиргә килүләр.
Тумыштан ук ул гөнаһлы булгач,
Язык аңа бала сөюләр.

Гөнаһлы дип әйттең туганнарын,
Ата-анасын да, әшнәсен.
Тумыштан ук ул гөнаһлы  булгач,
Җир йөзендә ничек яшәсен?

Бәндәләрең гүя җыйгансың син
Гөнаһ тулган уртак арбага...
Тумыштан ук гөнаһлы син, дисәң,
Килмәс идем мин бу дөньяга.

## Үтте гомер

Үтте дә китте гомерләр,
Тик бер генә көн сыман.
Артта калды якты юллар,
Алдымда зәңгәр томан.

Ерак калды,  кайтмас инде
Йөрәк янган яшьлегем,
Дөнья көтә башлаган чор-
Яшь кияү дә яшь килен.

Олы юлның бормасында
Югалды таныш-белеш.
Дуслардан  аерды юллар
Дуслыклар исән килеш.

Барыр юлның азагы да
Хәзер күренә инде.
Кешегә бер мизгел генә
Яшәүне бирә инде.

Бәлки шуңа кадерледер
Шушы җирдә яшәвең,
Кояш кебек нур сибүең,
Яшен кебек яшьнәвең.

Күкне болыт басканда да
Гомерең   бик кадерле.
Дулап-давыллап китсә дә,
Үз итмисең каберне.

Үтте дә китте гомерләр,
Үткәнен дә сизмәдем,
Күз ачып йомганчы гына
Үтәрләрен белмәдем.

## Яшәү җырым

Туктатып та, бүлгәләп тә булмый,
Уза гомер, уза бөтенчә.
Яшәү-  кабатланмас бер җыр үзе,
Һәркем җырлый аны үзенчә.

Ярсып-ярсып  мин дә көйләр суздым,
Еллар ашыктырдым, ашкынып.
Җырның һәр бөртеген, һәр мизгелен
Хәзер искә алам сагынып.

Хыял дөньясына чумам кайчак,
Кайбер җырым телә бәгырьне...
Нинди булсын, бар да үземнеке,
Бар да үземә бик кадерле.

## Ялгыз әнкәем

*Ана күңеле балада,*
*Бала күңеле далада.*

Өйдә калган ялгыз әнкәем.
Урамнардан үтсә машина,
Барлык эшен ташлап, тиз генә
Тәрәзәгә табан ашыга.

Тәрәзәгә карый тилмереп,
Күренмәсме күзем карасы?
Айлар, еллар буе көтте бит,
Кайтып җитәр газиз баласы.

Чыга да ул капка төбенә,
Барлый һәрбер үткән-барганны.
Өмет баглап карый текәлеп:
Әллә инде минем баламмы?

Изге догаң белән, әнкәем,
Язмыш юлын үттем байтагын.
Көткәнсеңдер мине зарыгып,
Кайталмадым,
Кичер, кайтмадым.

## Яшел читек

Яшел читек хыял булып калды,
Киялмәдем яшел читекне.
Җае килгән чакта киеп йөрдем
Бик куанып,
Кирза итекне.

Бабаларым, ахры, минем кебек
Булмагандыр.
Алар электән
Яшел читек киеп кенә барган
Намаз укыр өчен мәчеткә.

Авыл ялкауы бер әйткән имеш:
«Йөрер идем, - диеп, - намазга,
Хәйрулланыкыдай яшел читек
Бирсә Ходай миңа беразга».

Ялкаумынмы, әллә башка сәбәп,
Киялмәдем яшел читекләр.
Кулдан килгән чакта алып кидем,
Көязләнеп,
Кирза итекләр.

## Гомер йомгакларын сүткәндә

Гомер йомгакларын сүткән чакта
Ниләр калган, дисәм, хәтердә,
Әткәм- әнкәм назын җаным белән,
Тәнем белән тоям хәзер дә.

Картнәем дә менә күз алдымда,
Йомшак кулы сыйпый башымнан.
Япь- яшь абзыем да, апаларым
Тора кебек минем каршымда.

Менә бүтән якын туганнарым,
Әби- бабай, абый- апалар,
Чын күңелдән мине яратканга
Иркәләп киң колач ачалар.

Ярсып сөю ташкыннары истә,
Аерылышулар, кавышу,
Мәхәббәтнең утларында яну,
Шулай сарыларга сабышу.

Күптән түгел сыман дуслар белән
Бергә җырлап -биеп йөрүләр,
Мәңге бергә булыр төсле дуслар,
Ашкынулы гомер сөрүләр.

Миңа кирәгендә ярдәм кулын
Сузган икән күпме кешеләр!
Барысы да истә.
Зинһар өчен,
Рәхмәтемне кабул итсеннәр.

Нинди күркәм  кешеләре белән
Очраштырган икән Ходаем.
Шундый терәкләрем аркасында
Адәм булганмындыр, мөгаен.

Үткән елларымны бик сагынып,
Гомер йомгакларын сүткәндә
Кемнәр генә искә төшми  икән,
Нинди хәлләр, баштан үткәннәр...

## **Булдым да булалмадым**

*Мин Тукай була алмадым,*
*Такташ та булалмадым...*
*Роберт Миңнуллин*

Тукай була алмадым мин,
Такташ та булалмадым.
Тимер Заһит-
Шигърияттә
Минем бар булалганым.

Җәлил, Кәрим, Туфан түгел,
Роберт Миңнуллин түгел.
Йолдызлардай балкып тормыйм
Шигъри дөньяда бүген;
Канат җәеп иңли алмыйм
Милли шигърият күген.

Ә шулай да туганмын бит,
Булгандыр бер кирәгем.
Юкка гына типмәгәндер
Күпме еллар йөрәгем.

Булдым иң кадерле угыл,
Онык, энекәш, абый.
Җаннан якын дус та булдым,
Болары да бит ярый.

Сөйгәнемә сөекле яр,
Ата балаларыма,
Оныкларыма картәтәй,
Кирәк булдым барына.

Шәкертләрем өчен остаз,
Ышанычлы юлдаш мин.
Ялган сүзгә җенем килә,
Изге эштә кулдашмын.

Шатланыр яклар бар ласа,
Байтак бит булалганым...
Тик халкыма Тукай да мин,
Такташ та булалмадым.

## Юллар, еллар

Йөргән юллар, үткән еллар
Һич онытмалы түгел.
Гомерләрнең агышы дип
Кадерләп саклый күңел.

Йөргән юллар, үткән еллар-
Гомеремнең байлыгы.
Авыр юллары да булды,
Еллары да кайгылы.

Йөргән юллар, үткән еллар-
Артта калган гомерем.
Алда язмыш нинди икән,
Ни бар икән күререм?

Йөргән юллар, үткән еллар-
Нәкъ үземә язганы.
Нинди булса, шундый булсын,
Кыскармасын калганы!

## Әйрән тәме

Хәзер минераль су гына
Булса да өйрәнгәнем,
Телем белән тоям сыман
Салкынча әйрән тәмен.

Өйдә утырып эчсәм дә,
Урманда, чирәмдәме,
Бик яратып эчсәм, сизәм
Салкынча әйрән тәмен.

Туганякларда булыйммы,
Читләрдә йөргәндәме,
Сусап эчкән судан килә
Салкынча әйрән тәме.

Күпме булса, шунча булыр
Җир  шары әйләнгәне.
Тик барыбер онытылмас
Салкынча әйрән тәме.

## Яшь гомер

Яшь гомерләр үтә диләр,
Үткәнен күрсәң иде,
Үтеп барган яшь гомерне
Туктата белсәң иде.

Туктап калып булса икән
Гомерләрнең язына,
Яңадан бер яшәр идем
Япь-яшь булып аз гына.

Үткәндәге хаталарны
Бер дә ясамас идем.
Туры юлдан гына йөреп,
Кыек атламас идем.

Язмыш чатларын алдан ук
Мин белеп торыр идем,
Шуңа карап бик бәхетле
Бер гомер корыр идем.

Кайгы- хәсрәтне үземә
Якын китермәс идем,
Авырлык, кыенлыкларны
Бөтенләй белмәс идем.

Тик шулай хыялланганда
Бер уй тырный күңелне:
Андый гомер сөргән бәндә
Башка берәү түгелме?

Менә бу хаталы кеше
Нәкъ үзем бит, мин үзем!
Ялгышлары да минеке,
Сүзләре минем сүзем.

Күңелдәге хатирәләр
Минем өчен истәлек.
Теге  хатасыз кеше ул
Бөтенләй бер чит кебек.

Яхшымы, яманмы инде,
Бу гомер- минем гомер.
Хәтердә шул янсынмыни,
Калдырып кара күмер?

Юк, мин моңа риза түгел,
Булсын минем үземә
Кадерле гүзәл яшьлегем,
Үтсә дә бик тиз генә.

Ә шулай да...
Яшьлегеңнең
Үткәнен күрсәң иде,
Шуны беразга булса да
Туктата белсәң иде.

## И тәкъдирем

И тәкъдирем- узмышы юк язмыш,
Рәхмәт, аз булмады биргәнең.
Соравын да бик күп сорадың шул,
Еш-еш ордың-суктың, тиргәдең.

Синең усал давылларың дулап,
Башларыма яуды ташларың.
Сирәк-мирәк кызгандың да бугай-
Шатлыкларга күмеп ташладың.

И тәкъдирем, туган җирдә түгел,
Чит илләрдә үтте гомерем.
Маңгаема язып куйгансыңдыр
Еракларда гомер сөререм.

Күрсәттең син миңа бу дөньяның
Яхшы-яман төрле кырларын.
Ярый әле, шуңа чыдасын дип,
Бирдең миңа моңлы җырларың.

И тәкъдирем минем, и тәкъдирем,
Рәнҗемәс тә идем һичкайчан,
Иң бәхетле чакларымны минем
Бер мизгелгә генә кайтарсаң.

**Әллә кердең микән төшемә**

*Гомерем! Тик төшкә кердеңме?*

*С.Есенин*

Ничек болай бик тиз үтте-китте,
Ышанмыйм мин үзем яшемә.
И гомерем!
Тик бер мизгел генә,
Әллә кердең микән төшемә?

Әнкәенең җылы кочагыннан
Назлырак ни бар соң кешегә?
Шул наз бүген хәтер түрләрендә,
Гомерем кергән кебек төшемә.

Әткәм җилкәсендә утырганым,
Бала чагым төшә исемә.
Шунда куанганым  тик күңелдә,
Кердемәллә гомер төшемә?

Дөрләп янган яшьлек мәхәббәтем,
Ничек сыйган хисләр эчемә?
Шул утлар да сүнде.
Гүзәл гомер
Кергән кебек тик бер төшемә.

Карап торам сыман туганнарга,
Якыннарга, бар дус-ишемә.
Җаным кебек якын иде,
Юклар...
Гомер кердемәллә төшемә?

Менә дөнья куып эшләп йөрү,
Җиң сызганып, бөтен көчемә.
Хәзер дөнья  куа мине.
Әллә
Керде шул чаклар тик төшемә.

Үткән гомер кире кайтмаслыгын
Бара-бара һәркем төшенә.
И гомерем!
Бигрәк кыска булдың.
Кергән кебек кенә төшемә.

**Әткәем**

Яшькә синнән олырakмын хәзер,
Ләкин синең   алда кечкенә.
Әткәм моңа ничек карар,  димен,
Алда торган кылыр эшемә.

Нинди юллар сайлап китәремне
Әткәемнән сорыйм һәрвакыт.
Киртәләрне үтәм  бугай, әткәй,
Синдәй атлап, сиңа охшатып.

Синең сүзләреңә таянам гел,
Шуннан һичбер мин ваз кичмәдем.
Үземне дә, йөргән юлымны да
Синең бизмән белән үлчәдем.

Зур бәхетләр, шатлык-куанычлар
Эчкә сыймый торган чагында
Сине искә алам мин, әткәем,
Киңәш сорыйм синнән тагын да.

Башкаема кайгы-хәсрәт төшсә,
Син, әткәем, иң зур терәгем.
Эчтән генә синнән ярдәм сорыйм,
Өйрәтәсең ниләр кирәген.

Күптән юк син фани дөньяларда,
Күңелем синең белән сөйләшә.
Син назлыйсың кебек,
Йомшак җилләр
Туган якның көен көйләсә.

Шул көч бирә миңа,
Каршы торам
Килгән авырлыкның барына.
Әткәм минем белән, дип курыкмый
Керәм дөнья чытырманына.

Яшем синнән олы хәзер,
Ләкин
Керешергә торсам бер эшкә,
Мин барыбер кеп-кечкенә малай,
Тагын киләм сиңа киңәшкә.
Ярдәм сорап киләм киңәшкә,
Берәр яңа эшкә керешсәм.

## Исеңдәме, әнкәй?

Таныш урман юлын икәү бергә
Үтеп барган чакта, әнкәем,
Исеңдәме?
Җырла әле, улым,
Мин дә ишетим, дип әйткәнең.

Син җырлыйсың икән моңнар белән,
Шулай диләр, - булды сүзләрең.
Бер дә көтелмәгән шул сүзләрдән
Син күрендең миңа үзгәреп.

Кыенсынып бардым бераз вакыт,
Җырчы түгел лә мин, әнкәем!
Теләгеңне җиргә ташлый алмыйм,
Оялсам да җырлыйм, нишләем.

Яңгыратып урман араларын
Багышладым сиңа җырымны.
Нарат җырга кушылгандай булды,
Чыршы гүя безгә борылды.

Ак каеннар һәм мәһабәт имән
Җырны тыңлый кебек күренә.
Ә әнкәем башын түбән игән,
Кайнар яшьләр тулган күзенә.

Татлы балачагын сагындымы,
Хәтерләпме гүзәл яшьлеген,
Үткән гомерләрен кызганыпмы,
Атлый барды әнкәм яшь түгеп.

Нинди хатирәләр төште икән
Синең исләреңә, газизем?
Мин белмәдем.
Аны син, әнкәем,
Белгәнсеңдер бары  тик үзең...

Күңелем түрендә шушы урман,
Аның борылмалы юллары,
Әнкәемнең изге күз яшьләре,
Моң-сагышлы татар җырлары.

## Кайталмадым

Быел  тагын кайталмадым, әнкәй,
Зар булсам да синең карашка.
Изге теләкләрем барып җитсен
Бер улыңнан синең тарафка.

Исән генә яшим әле, әнкәй,
Юк, ахрысы, артык үзгәреш.
Балалар да үсте, оныклар бар,
Үз көннәрен күрә үзләре.

Эшләп йөрим һаман элеккечә
Эшлисе эш әле бетмәгән.
Дөнья бит ул, туктарга юл бирми,
Гел сикертә төрле киртәдән.

Җаның борчылмасын минем өчен,
Килмәгәнгә  синең кабергә.
Кайтсам, барыр идем
Синең
Соңгы урыныңны кадерләп.

Сурәтеңә карап сөйләр идем
Моң-зарымны, дөнья хәлләрен,
Башка балаларың  исәнлеген,
Барлык оныкларың хәбәрен.

Сурәтеңнән син елмаеп кына
Карап торыр идең күземә.
Күңелләрем тынычланыр иде,
Яшәү көче табып үземә.

Булмады шул, кайталмадым, әнкәй,
Кайтып-йөреп булмый һәрдаим.
Син рәнҗемә инде миңа, яме?
Җәннәт сөенечен насыйп итсен
Синдәй изге җанга Ходаем.

## Яшьлек кыска гомерле

Зәңгәр күктә кояшыма
Яшьлегемне тиңләдем.
Назлы кояш нурыннан да,
Яшьлектән дә бизмәдем.
Кояш кебек мәңге-мәңге
Балкып торсын, дигәнем.
Кояш балкый, тик яшьлегем
Үткәннәрен сизмәдем.

Ярсып  аккан ташкыннарга
Яшьлегемне тиңләдем.
Язгы судай шаулап акты,
Тиз китәрен белмәдем.
Дулкыннарның арасында
Яшьлегемне эзләдем.
Киткән яшьлек кире кайтмас,
Мин бит шуны белмәдем.

Бакчадагы исле гөлгә
Яшьлегемне тиңләдем.
Гомер буе гүзәл чәчәк
Атуларын теләдем.
Көн дә чыгып сулар сиптем,
Гөлләремне өзмәдем.
Ләкин алар сулды, шиңде,
Үтәлмәде теләгем.

Дөрләп янган кызу утка
Яшьлегемне тиңләдем.
Яндырмасын яшьлекне, дип,
Аңа якын килмәдем.
Янган утлар берчак сүнәр,
Күмерләнер димәдем.
Күрми калдым яшьлегемнең
Шул чаклары килгәнен.

Яшьлегемнең ал чәчәген
Саклап тоттым, өзмәдем.
Нурларының назын тойдым,
Утларын сүндермәдем.
Ашык-пошык үтеп киттем
Яшьлегемнең үрләрен.
Яшьлек кыска гомерле шул,
Кадерләрен белмәдем.

## Күңел яшь минем

Яшьлек чагың үткән, диләр,
Үтмәгән күк яшьлегем.
Артта күпме еллар калсын,
Күңел һаман яшь минем.

Яшьләр узса җырлый-җырлый,
Кушылып җырлыйсым килә.
Шулар белән бергә мин дә
Уйныйм күк көлә-көлә.

Тыпырдатып биесәләр,
Чымырдый аякларым.
Мин дә төшеп биер идем,
Кулымда таякларым.

Яшьләрнең саф сөюенә
Минем йөрәк талпына.
Әллә кая китәр иде,
Көче җитми чак кына.

Яшьлегемне оныталмыйм,
Әле күңел яшь минем.
Яшең олы, дип әйтсәләр,
Юк, мин әле яшь, димен.

Картаюны сизми икән,
Белми икән бу күңел.
Җирдә күпме яшәсәм дә,
Үзем белән яшьлегем.

## Картнәемә

Дәшмәдем мин сиңа Дәү әни дип,
Әби дигән сүз дә якмады.
Картәнкәем, Картнәй дигәннән дә
Татлырак бер исем тапмадым.

Иң сөекле оныклардан булдым
Картнәемә бала чагымда.
Аның яннарына кайтып киләм
Хыялымда тагын, тагын да.

Рәхмәт укый- укый искә алам.
Ачып куйсам хәтер дәфтәрен,
Мин ишетәм иркә сүзләреңне,
Күрәм көмеш ап-ак чәчләрең.

Күз алдымда тирән җыерчыклар,
Ак яулыгың, йөзең нурлары.
Тоям кебек мине сыйпый-сыйпый
Назлаганын йомшак кулларың.

Менә кесәңнән бер тәм-том чыга,
Аны минем учка саласың,
Искиткеч бер иркә назлар белән
Бөтенләйгә чорнап аласың.

Шул чактагы тойгы, хисләремне
Нинди сүзләр белән язасы?!
Җитми сүзем, ничек аңлатырга
Хисләрнең иң саф, иң тазасын.

Картнәмнең дә изге догалары
Булды миңа яшәү терәге...
Оҗмахларда урын алсын җаның,
Картнәмә шул соңгы теләгем.

## Сагыш сүзе

*Бертуган абзыем Әхмәтшәриф истәлегенә*

Бик шәфкатьсез булды сиңа
Алдан язган тәкъдир дигәне.
Дөньяның бар ачылары
Сиңа килә торды нигәдер.

Ачлыгы да, кытлыгы да,
Имгәклек тә төште җилкәңә.
Җилләре  дә  каршы өрде,
Көч бирмәде синең җилкәнгә.

Сугышларда  үз каныңны
Коюны да бирде Ходаем.
Син күрмәгән бер авырлык
Калмагандыр җирдә мөгаен.

Син ничектер ялгыз сыман,
Әйләнәңдә кеше булса да.
Берәүгә дә сиздермәдең,
Эчләреңә утлар тулса да.

Сагышлы моң, җырлар белән
Күңелеңне үзең юаттың.
Иртә киттең мәңгелеккә,
Хәзер инде сине югалттым.

Гомер бер гүзәл җыр кебек,
Аны син үзеңчә җырладың.
Үлмәс җаның бәлки сизәр
Сагышлардан йөрәк сызлавын.

## Апаларым

*Мөгаллимә, Әлфия, Лия апаларыма*

Ата-анам назлап сөюләрен
Чагыштырыр нәрсә табылмас.
Абзыемның, апаларымның да
Иркәләве мәңге онытылмас.

Өч апам бар минем, өчәү генә,
Өчесе дә миңа кадерле.
Җаннарым  җәл түгел алар өчен,
Җаным  бирергә  дә  әзермен.

Бу дөньяның ачы-төчесен дә,
Авыр юлларын да үттеләр,
Бирешмәде минем апаларым,
Эшчән,  тырыш булып үстеләр.

Бәләкәй чана да тартты алар,
Биштәрен дә иңгә астылар.
Җаннарына бозлар тулганда да
Минем өчен җылы таптылар.

Иң өлкәне сабыр, чыдам булып,
Түземлекләр юлын күрсәтте,
Кечеләре хәсрәт-сагышларны
Җырлап таратырга өйрәтте.

Апаларыма гел бурычлы мин,
Хәзер булмас инде  кайтарып.
Игелекләр үзләренә кайтсын,
Дип Ходайдан сорыйм ялварып.
Апаларым минем, апаларым...

## Юллар чакыра мине

Офыклардан ары киткән
Ерак юллар чакыра.
Кая алып бармакчыдыр,
Ниләр бардыр ахырда.

Нинди җирләр күрсәтмәкче,
Очратмакчы кем белән;
Күпләр сәфәр кылыр микән,
Ялгызмы бер мин генә?

Юк җавабы,
Ләкин юллар
Тартып тора үзенә.
Җилләр генә пыш-пыш итә:
«Әйдә киттек тиз генә».

Карап торам ерак юлга,
Белмим ник чакырганын:
Күңел үргә омтыламы,
Моңаямы зар җаным.

**Җаның рәнҗемәсен**

*Берлин янындагы сугышларда*
*һәлак булган ике туган абыем*
*Хәмәтнур Гәрдәнов истәлегенә*

Исеңдәме, сине Армиядән
Кайткан дигән сүзне ишетеп,
Йөгереп тә килдем мин, бәләкәч,
Үз-үземне
Күкнең иң күгендә хис итеп.

Ә син өйнең агач болдырында
Чалкан ятып гармун уйныйсың.
«Килдеңмени, энем?», дип сөйдең дә,
Күкрәгеңә
Мине атландырып куйдың син.

Масаюым эчкә сыяр түгел,
Ә син һаман гармун уйныйсың.
Елмаеп бер миңа карыйсың да,
Сагыш белән
Уйнап, акрын гына җырлыйсың.

Әллә җаның сизде шул мизгелдә
Күрәлмәм, дип моның үскәнен.
Кем белә соң?
Син сугышка киттең. Шуннан килде
Хәбәрнең иң үзәк өзгәне.

Ел артыннан еллар үтә торды,
Тик мин һаман бара алмадым
Кабереңә.
Дога укып, шунда баш имәдем,
Чәчәкләр дә илтеп салмадым.

Биш дәүләтнең чиген үтәргә бит
Барыр өчен синең янына.
Ни эшлим соң?
Барып булмады  шул бер ничек тә,
Әллә шуңа сине сагынам.

Менә хәзер яшьне чагыштырсак,
Мин хәтсезгә синнән олырак.
Рәнҗи күрмә.
Миннән бәхил бул син.
Кабереңдә
Җиңел булсын авыр туфрак.

## Иске зират

Иске зират.
Кабер ташлары да
Җиргә сеңгән, язу җуелган.
Белеп булмый, кем күмелгән монда,
Кемгә атап ташлар куелган.

Күпләр хәзер эзсез юкка чыккан,
Куйган ташлары да калмаган.
Әйтерсең лә, ул җан яшәмәгән,
Андый кеше җирдә булмаган.

Куе урман үскән тирә-якка,
Аяк асты-хәтфә тукыма.
Бабам каберен  мин тапмак булам,
Дога кылмак булам рухына.

Эзлим-эзлим, һаман таба алмыйм
Минем өчен изге урынны.
Игелексез  онык булдым, ахры,
Ничек тиргәсәң дә, урынлы.

Әткәем бит бер күрсәткән иде
Шул бабамның кабер агачын.
Бабам җаны мине көткәндер бит -
Газиз баласының баласын.

Ә мин һаман монда киләлмәдем,
Әткәм үзе исән чагында.
Менә хәзер эзлим,
Таба алмыйм,
Әйләнәм мин тагын, тагын да.

Ахырында туктап, утырдым да,
Башларымны борып кыйблага.
Дога кылдым монда ятканнарга,
Кемнәр мохтаҗ булса догага.

Багышладым барлык әрвахларга.
Мондый догалар да кирәкле.
...
Картәткәм каберен табалмадым,
Шул уй уктай чәнчи йөрәкне.

## Әткәем карамасы

Кечкенәдән  минем күз алдымда
Биек бер карама агачы.
Бакча почмагында  ялгыз гына
Тора  иде  җәеп колачын.

Шул агачны әткәм утырткан да,
Сулар сибеп үзе үстергән.
Елдан-елга күккә күтәрелгән
Бу карама бөтен тирә-юньгә
Искиткеч бер гүзәл ямь биргән.

Шуның тирәсендә уйнап үстек,
Куыш кордык  агач астына.
Ботакларын иеп көч сынадык,
Үрмәләдек аның башына.

Ә карама миһербанлык белән
Безнең шуклыкларны кичерде.
Ботаклары сынса, рәнҗемәде,
Тагын яңаларын үстерде.

Мин авылдан киткән чакта агач
Гүя сузды ботак-кулларын.
Изге теләкләрен теләгәндәй,
Җиңел булсын диеп, юлларың.

Язмыш безне төрле  якка чәчте,
Ә карама калды өй саклап.
Бер кайтырлар  әле,  диде бугай,
Хуҗаларым  өйгә паратлап.

Әткәем дә бу дөньядан китте,
Шул кайгыдан агач сыгылгвн.
Яшәү көче беткән караманың,
Хәлсезләнеп җиргә егылган.

Инде күптән юк ул карамабыз,
Тик саклана минем хәтердә.
Аның назлы яшел яфраклары
Күңелемдә шаулый хәзер дә.

## Күктән йолдыз атылганда

Күктән йолдыз атылганда
Нинди теләк теләдең,
Өметләнеп,
Кабул булыр
Минем дә, дип, теләгем?

Бу дөньядан  киткәннәрне
Тагын күрим диденме,
Җирдә  кабат яшәсеннәр,
Дип сораган идеңме?

Теләдеңме
Яшьлек чагым
Яңадан бер кайтса, дип,
Тәүге мәхәббәт гөлләре
Гөрләп чәчсәк атса, дип?

Элек йөргән юлларыңны
Бәлки, үтәсең килгән,
Ышыклап сөйгән ярыңны
Давылдан, ачы җилдән.

Яшәр идем яңадан, дип,
Булдымы бер хыялың;
Әллә  бусын әйтмәдеңме,
Күп сорарга оялып?

Белмим ниләр теләгәнең,
Нәрсәләр сораганың;
Ләкин беләм, бар  теләк тә
Үтәлеп тормаганын.

Белеп теләсәң, ул теләк,
Тели белмәсәң, имгәк.
Мәңге булмасны теләүнең
Хәҗәте дә юк, димәк.

Тик белеп теләгән теләк
Гамәлгә аша, диләр.
Хак  Тәгалә күк капусын
Кайчакта ача, диләр.

## Ярый әле, туганмын

*Тууым дөрес булган.*
*Марсель Галиев*

Килгәнмен бу дөньяларга
Көннәр ачык торганда.
Бик куанган якыннарым
Нәкъ бу малай туганга.
Аз булса да үзгәргәндер
Дөнья,
Мин дә булганга.

Мин булмасам, гүзәл ярым
Сөюне белмәс иде.
Балаларым, сөендереп,
Дөньяга килмәс иде.
Нәселемнең киләчәген-
Оныклар күрмәс идем.

Күпме агач утыртылмас,
Үсмичә калыр иде.
Гөлчәчәкләр суга сусап
Шиңәр дә, сулыр иде.
Табигатьнең гүзәллеге
Тоныграк булыр иде.

Йөргән сукмак, юлларымны
Үтмәс иде беркем дә.
Хисләрем тоелмас иде
Беркемгә дә, бер көн дә.
Эшләнмичә калыр иде
Бар эшләрем бүген дә.

Кирәк булгандыр ул
Җирдә
Менә минем тууым;
Шул вакытта, шул урында
Яшәр оя коруым;
Таянычка мохтаҗларга
Ышанычлы булуым.

Ярый әле, мин туганмын
Якты дөнья йөзендә.
Яшәдем бит җәен, кышын,
Язларын да, көзен дә.
Яшәешнең ләззәт, тәмен
Татып калдым үзем дә.
Ярый әле, туганмын !

## Кычкырмале, кәккүк

Кычкырмале, кәккүк, кычкырмале,
Бигрәк еш кычкырдың бу айда.
Әйтмәсәң дә,
Гомер аз калганын
Үзем белеп торам болай да.

Китәргә дә вакыт җиткәндер ул,
Җир йөзендә байтак яшәлгән.
Ашыктырма, яме?
Эш беткесез,
Әле туймадым да яшәүдән.

Ә син һаман очып киләсең дә
Мин бакчага чыккан чагымда,
Үзең ятлап алган ап-аз санны
Кабатлыйсың тагын, тагын да.

Шунда мин утырткан, мин үстергән
Шомырт, алмагачлар рәнҗиләр.
Юкка гына шушы саран кошка
Биргән икәнбез гел җим, диләр.

Син рәнҗетмә әле агачларны,
Әгәр китсәм, алар корырлар.
Кунып сайрар агачың да корыса,
Сиңа дөньяның ни нуры бар?

Ярый, бүген килмәдең син, кәккүк,
Хет бер көнне синсез үткәрдем.
Башка хәтерләтмә.
Чакырсалар,
Кичекмичә шундук китәрмен.

## Үткән яшьлек

Үтте яшьлек, дип көрсенмә,
Үкенмик үткәненә.
Без яшәгән яшьлек бит ул,
Түгел тик үткән генә.

Гөрләп үткән яшьлек бит ул,
Шунда бәхет, шатлыклар.
Шунда безнең уен-көлке,
Шаянлык та, мутлык бар;
Бөтен галәм сыяр уйлар,
Дөрләп янган йөрәкләр,
Ашкынулы пакь күңелләр,
Шунда изге  теләкләр.

Шунда беренче мәхәббәт,
Сөюнең иң татлысы,
Иреннәрнең иң баллысы,
Күз яшенең ачысы.

Анда сөю җырларлык та,
Анда сөю еларлык.
Сөю түгел, язгы ташкын,
Аягыңнан егарлык.

Яшьлегемдә калды минем
Җандай якын дусларым.
Беркайчан да онытalмам
Җирдә шундый дус барын.

Дуслар терәк, баскан җирең
Кинәт тетрәп китсә дә,
Авыр хәлдә башкаеңа
Кайгы-хәсрәт төшсә дә.

Якын дуслар, иң саф хисләр
Гомер буе хәтердә.
Исләремнән бер дә чыкмый,
Күңелләрдә гел бергә.

Күңел бит ул һәрчак бик яшь,
Әйтерсең лә, яшь көнем.
Күңелемнең түрләрендә
Үткән гүзәл яшьлегем.

Тик бер мизгел булды яшьлек,
Яшьнәгән бер яшен тик…
Үкенмик лә, үтте, диеп,
Без яшәгән яшьлек бит !

## Нихәтле бар сулар агасы

Уйланасың да син, уфтанасың,
Дәртсез хәзер диеп, гомерләр.
Уфтанмале, кышлар мәңге түгел,
Матур язлар  тагын килерләр.
Өйнең кыегыннан шап-шап итеп
Тамчылар да тиз-тиз тамарлар,
Кар сулары гөрләвекләр булып,
Берсен-берсе куып агарлар.

Нихәтле бар сулар агасы,
Нихәтле бар уйлар уйласы.

Якты кояш  оя корыр күктә,
Назлы нурын сузып җирләргә,
Дәртләр  өстәп егет-җилкенчәккә,
Мыеклары бәсле ирләргә.
Кыз-кыркыны җырлар  яңгыратыр,
Биеп кенә торыр хатыннар,
Әби-бабайлар да  күңелләрдә
Яшьлек елларына кайтырлар.

Нихәтле бар сулар агасы,
Нихәтле бар җырлар җырласы.

Гөрләп торыр  гүзәл тормыш җәйдә,
Барлык  җан иясе яшәүдә.
Ни эшләсәң, шул уңышлы була,
Ниләр җитә шулай яшәүгә?
Өстәлләргә муллык  алып килә
Көзләр - хезмәтеңнең йомгагы.
Бөтен дөньяң түп-түгәрәк булса,
Бәндәләргә кирәк ни тагы?

Нихәтле бар сулар агасы,
Нихәтле бар эшләп каласы.

Көз  җитте дип, эшләр туктап тормас,
Юллар китәр юлга ялганып.
Юлларыңны үзең йөргән яхшы,
Карлар күмә  аның калганын.
Салкын кышлар килгәч, ямансулап,
Уфтанырсың инде тагын да,
Дәртсез үтә хәзер гомер диеп,
Буран уйнап торган чагында.

Нихәтле бар сулар агасы,
Нихәтле бар юллар барасы.

Бозылмасын әле кәефләрең,
Язгы матур көннәр килерләр.
Әллә кая, диңгез аръягына
Ашкынырлар тагын күңелләр.
Агым суның гайрәт-куәтенә
Сокланырсың,  күреп агышын.
Язгы ташкын үзе белән бергә
Алып китәр йөрәк сагышын.

Нихәтле бар сулар агасы,
Нихәтле бар уйлар уйласы.

## Күрше карчык

Кырыс, кытлык еллар иде,
Сугышта әтиләре,
Ачтан шешенгән гаилә-
Зурлары, нәниләре.

Күптән төтен күренми дип,
Килеп кергән җан күрше,
Күрше хакы- Алла хакы,
Дип аңлый торган кеше.

Кеп-кечкенә, үтә ябык,
Җаны кайда яшидер.
Шул карчыкның теле татлы,
Гадәттә бик төчедер.

Ә бүген ул, күреп калгач
Хәлнең ничек икәнен,
Теле белән кырып сала,
Тетә хуҗабикәне.

«Син, -ди, -нәрсә, шешендек, дип,
Өеңдә тик ятасың?
Үлән чыккан болында, бар,
Җый кузгалак, юасын.

Бер кашык он кушып пешер
Җыйган яшь кузгалагың,
Ак күмәчтән тәмле була,
Җибәр мичеңне ягып».

Йөгереп алып та керә
Үләннәрнең барлыгын.
Кушып бирә бер кашыктай
Кадерле арыш онын.

Нинди  авыр хәлләр булсын,
Кытлык еллар, ачлыклар,
Безнең  авылда бар иде
Шундый  изге карчыклар.

Шул  карчыкны  күмәч белән
Өлгермәдем сыйларга.
Дөньяда юк  иде инде,
Үз көчем белән  ак күмәч
Эшләп табар елларда.

## Биш кашык он

Биш кашык он дисәң, аның бүген
Бәясе, күп булса, бер сумдыр.
Шушы арыш онын искә алу
Кирәксездер, бәлки, бик соңдыр.

Соң булса да, шуны искә алам,
Биш кашык он миңа бик кыйммәт.
Дөньяда иң тәмле тәгамнәрдән
Кадерлерәк миңа шул нигъмәт.

Авыр еллар килгәч бөтен илгә,
Саклап калды ачлык үлемнән
Әнкәемнең, корсак алдар өчен,
Дип пешергән ашы үләннән.

Туган якның кузгалакларын да,
Балтырганнарын да, юасын,
Ат кузгалагын да ашадык без,
Кичерткәнен, алабутасын.

Черек бәрәңгедән пешерелгән
Кәлҗемәне сорап ашыйсың.
Ләкин язгы ачлык килгән чакта
Шул кәлҗемәне дә тапмыйсың.

Шундый чакта яткан нәни малай
Торалмастан, яшәр хәл беткәч;
Газраил да якынлашкан инде,
Алып китәргә дип, төн җиткәч.

Ана кеше газиз баласының
Шул хәленә ничек чыдасын?
Йөгергән ул колхоз рәисенә,
Белми ничек ярдәм сорасын.

Ялварган ул: «Зинһар, юл табыгыз
Шул баланың  җанын сакларга;
Кырда үлән  үскәч, бәлки яшәр,
Бәлки аягына басар да.
Аның әтисе дә, абыйсы да
Кайтса сугыштан,  ни әйтерсең?
Аз булса да, яшәсен иде бит,
Бәлки күрер иде әтисен».

Рәхмәт, рәис!
Әнкәм алып кайткан
Бер биш кашык арыш онынннан.
Шуның белән пешерелгән умач
Газраилны куган  янымнан.

Әйе, мин шул малай.
Әнкәемнең
Җиңел булсын авыр туфрагы.
Биш кашык он белән баласына
Яңа гомер биргән ул тагын...

Хәзер дә мин төшләремдә күрәм,
Хәтерлим дә ачлык елларын,
Кыйммәтледән дә иң кыйммәтлесе,
Кашык белән генә үлчи торган
Җан саклаган арыш оннарын.

## Ир егет

*Кайларда гына йөрми, ниләр күрми*
*Ир егеткәй белән ат башы.*
*Халык җыры*

Кая гына бармый, ниләр күрми,
Кайда гына йөрми ир егет.
Диңгез, дәрья, биек таулар кичә,
Күрсәтәм, дип, җирдә ирлеген.

Күпләр чыгып китә еракларга
Чарасыздан, качып нужадан.
Читтә эшләрмен дә җиң сызганып,
Кайтырмын, дип, илгә бер заман.

Олы юлда яңа дуслар таба,
Якын дуслар - яме дөньяның.
Бергә ерып чыккан авырлык та
Арттыра бит якты көн санын.

Еракларда килә саф мәхәббәт,
Чит җирләрдә кора оясын.
Гөрләп яши сыман.
Ләкин менә
Сагышыңны кая куясың?

Шау-гөр килеп бәйрәм иткәндә дә,
Күтәренке кәеф, көр чагың,
Келт итә дә, кинәт искә төшә
Туган яклар, изге туфрагың;
Әткәеңнең җылы күз карашы,
Әнкәеңнең иркә назлары,
Туган якның кырыс табигате,
Ләкин гүзәл җәйләр, язлары.

Моңлы сагыш белән менә шулай
Үтә айлар, үтә елларың.
Тик барыбер булыр кебек әле
Узган елларыңа юл ярып.

Туган илкәемә кайтып китәм,
Дия - дия җитә картлыгы.
Тормыш түп - түгәрәк, мул булса да,
Сагынудан китек шатлыгы.

Һәр ел саен ераклаша бара
Туган җир дә, калган туганнар.
Йөрәк әрнүенә дучар була
Читтә яшәп дөнья куганнар.

Туган ягыннан да аерылган,
Яшәгән җир никтер чит инде.
Ана теле монда ишетелми,
Ул үзе дә монда чит илле.

Гомеренә йомгак ясаганда
Күз яшьләре - гүя пәрдәләр.
....
Туган - үскән илдә гомер сөрә
Ходай бәхет биргән бәндәләр.

## Кораб

Җир читендә иксез-чиксез диңгез,
Торам әле карап.
Тик нигәдер һич күренми әле
Мин утырыр кораб.

Кайчак туа күңелләрдә шөбһә,
Ачык бөтен тараф,
Әллә читләп үтте микән мине
Алып китәр кораб.

Күзләрем дә тоныкланды инде,
Әллә даим карап.
Ә мин һаман көтәм.
Бәлки, килер
Мин утырыр кораб.

## Кышкы урманда

*Карурманга кергән чакта*
*Атым китте юл буйлап...*

Карурманга кереп киттем,
Атым бара урман юлыннан.
Атлый бирсен ашыкмыйча,
Дилбегәне куям кулымнан.

Кышкы урман юлы тап-тар,
Биек-биек көртләр өелгән.
Агачлар да карга баткан,
Авыр йөктән аска иелгән.

Урман тып-тын, бер тавыш юк,
Кошлар киткән әллә каядыр.
Һич күренми җанвар-мазар,
Берәр җирдә посып ятадыр.

Бөтен урманда юк сыман
Бездән башка бер җан иясе.
Җаным-тәнем бушап калды,
Бушагандай укның җәясе.

Акрын гына атлый атым,
Үз уйларын уйлый , ахрысы.
Мин дә уйлар диңгезендә,
Исләремә төшә барысы.

Менә алтын бала чагым,
Бер сагындым яшьлек елларын.
Истә шатлык, кайгысы да,
Җырлап үткән тормыш юлларым.

Гомер юлы төрле икән,
Әле китә атың чаптырып,
Әле атлый чак-чак кына,
Әле туктап кала, аптырап...

Уйларымны бүлде атым,
Чыккан икән урман юлыннан.
Чапты авылыма карап
Ап-ак карлы кышкы болыннан.

## Поездда

Чаптыр-чаптыр, дип такылдый
Вагон тәгәрмәчләре.
Бик ашыгып киткәнгәме,
Очкыннары чәчрәде.

Кабаланып чаба  поезд,
Канатлы бер аттай ул.
Алдагы юл кимеп- кими,
Озыная артта юл.

Поезд белән барган чакта
Үтеп  авыл, каласын,
Ятсаң, торсаң, утырсаң да,
Алга гына барасың.

Монда күпме очрашулар,
Танышу да, сөйләшү,
Кайчагында уртак юлда
Үзара  ияләшү.

Берәү керә, берәү чыга,
Алмашына кешеләр.
Әле бусы, әле бүтән
Була сиңа күршеләр.

Киткән китә бөтенләйгә,
Кире кайтып әйләнмәс.
Күңелләрне кушкан җепләр
Бер өзелсә, бәйләнмәс.

Артта калган үткән гомер
Поездда бару сыман.
Җилкетә дә, селкетә дә,
Алларында юл һаман.

Гомерләр дә шулай үтә,
Азмы анда очрашу,
Танышулар, табышулар,
Кем беләндер дуслашу.

Анда да бар аерылышу,
Мәңгелеккә  китүләр,
Юлны бергә йөргән дә бар,
Ялгыз да бар үтүләр.

Дөньясы да тар вагондай,
Монда да бар кысалар.
Күктә иркен очалмыйсың,
Кошлар гына очалар.

Дөнья үзе ашыктыра,
Чаптыр-чаптыр дип тора.
Туктарга һич ирек бирми,
Куа-куа чакыра.

Поездда бер ятып торсаң,
Байтак юлың үтелгән.
Гомер дә шул:
“Ә” дигәнче
Моннан китәр көн килгән.

Чакрымнарны йота поезд,
Эчә юллар хәмерен...
Бер юл хәтле кыска гына
Биргән бәндә гомерен.

## Алмагачым

Алмагачым, саумы!
Байтак еллар
Үтте минем моннан киткәнгә.
Бик сагынып тагын кайттым менә
Җәй азагы, көзләр җиткәндә.

Кайчандыр бит сине бу бакчага
Мин утырткан идем иркәләп.
Кичләрен дә сиңа сулар сиптем,
Сулар сибә идем иртәләп.

Ә син күпләп -күпләп алма бирдең
Бер төс кенә түгел, биш төсле;
Татлыдан да татлы, ис китәрлек,
Исертерлек аңкыр хуш исле.

Хәтеремдә, күз алдымда сыман
Күккә куллар сузган чорларың;
Җилфердәтеп ялтыр яфракларың,
Сандугачка кушылып җырлавың.

Бүген син бик боек.
Назлавыма
Әллә зар булдыңмы бакчада?
Әллә сине беркем якламады,
Бозлар явып, давыл какса да?

Яннарыңда мин булмагач, бәлки
Җитмәгәндер кояш яктысы.
Үзе юкның күзе дә юк, диләр,
Чит иткәннәр сине, ахрысы.

Эчтән генә әрнеп елагандай,
Әлсерәгән юлчы кебексең.
Өметләрең җуеп киләчәктән,
Гүя  ярты-йорты терексең.

Кулларың да асылынып төшкән,
Кубык киемнәрең сәләмә.
Кәкре -бөкре  куллар-ботакларың
Шыгырдашып  нидер сөйләнә.

Әллә картлык хисе бастымы соң?
Ялгыз картлык авыр һәркемгә.
Тышта гына түгел, эчләреңдә
Карлы яңгыр ява һәр көндә.

Картлыктан бер дәва юк шул җирдә,
Һич яшәреп булмый яңадан.
Кешеләр дә  дөньяга  бер килә,
Бер мәртәбә туа анадан.

Туктале син.
Яшьлек  кайтмаса да,
Сарыф итмәдең бит тикмәгә
Гомереңне.
Артта калган еллар
Бер дә юкка, бикәр үтмәгән.

Алмаларың синең  күпме еллар
Кешеләргә  шатлык китерде.
Үз янында назлап әллә ничә
Сылу үсентеләр үстердең.

Синең гомер шулай шаулап үтте,
Зарланырлык түгел язмышка.
Башларыңны күтәр, елмай әле,
Үз-үзеңне салма сагышка.

## Соңладым шул

Бүләк итеп гөлләр алып килдем,
Кичер мине, бигрәк соңладым.
Алла биргән гомер бардыр алда,
Өлгерермен диеп уйладым.

Өлгермәдем.
Хәзер гөлләремне
Кабер өсләренә таратам.
Чәчкәләрнең иң хуш ислеләрен,
Төсләре дә нәкъ син яраткан.

Тик син дәшмисең шул, сурәтеңнән
Елмайгандай карап торасың.
Әллә беләсеңме язмышымны,
Тормышымда  ниләр буласын?

Минем дә бит бик беләсем килә-
Бар микән соң теге дөньясы?
Безгә очрашулар насыйп микән,
Төзәлерме йөрәк ярасы?

Дәшмисең шул, елмаясың гына,
Әллә миңа күңелең үпкәле...
Кичер инде мине, бик соңладым,
Сизми калдым гомер үткәнен.

## Ышанам

Аклы- кара була, диләр, гомер,
Каралары күпкә охшаган.
Гел кап-кара булмас әле,
Берчак
Килер аклары, дип ышанам.

Күңел бик төшенке чаклар була,
Кәеф начар,  һаман пошаман.
Шул чакта да:
Әле күтәрелер
Кәеф, димен,
Шуңа ышанам.

Авыр кайгы төшә башкаема,
Шатлык букчалары буш заман.
Тик шунда да:
Бу кайгы да бетәр,
Алда шатлык бар,  дип ышанам.

Хәлем бетеп, егылыплар калам,
Атлап чыгалмастай бусагам.
Ә шунда да
Торам барыбер мин,
Атлап китәремә ышанам.

Яшәр көннәр алда беткән сыман,
Гүя  җирдә минем эш тәмам.
Ә мин һаман
Өмет өзмим әле,
Алда гомер бар,  дип ышанам.

## Үткәннәрне сагынам

Кем моңая уйлап яшьлекләрен,
Кем сагына әрем исләрен.
Мин сагынам үткән гомеремнең
Һәр минутын, һаман истәген.
Айлар, көннәрен дә бик сагынам,
Кышларын да, якты язларын,
Яңа гына чыккан яшь үләнен,
Кире кайткан киек казларын.

Сагындыра туган-үскән яклар,
Ялан тәпи баскан туфрагым.
Туган туфрак сыман сагынырлык
Йомшак, иркә кайда бар тагын?
Сагындыра карлы бураннары,
Коеп-коеп яуган яңгырлар.
Сагындыра бөтен табигате-
Җан ияләре дә, җансызлар.

Сагынам мин язгы су ташуын,
Эреп бетә барган карларны.
Бик сагынам барлык дусларымны,
Ярсып сөя белгән ярларны.
Газиз әткәм-әнкәм күз алдымда,
Онытмаслык якын туганнар,
Җил-давылдан мине ышыклаучы-
Терәк булып иңнәр куйганнар.

Үткәннәрнең һәрбер мәле кыйммәт,
Сагындыра хәтта томаннар,
Урап алып сине төрле яктан
Бар дөньяны каплый торганнар.
Яхшысы да, яманы да кыйммәт,
Барысы да минем гомерем.
Шул булгандыр минем язмышларым,
Шулай булган минем күререм.

Барысы да тик хәтердә генә,
Кайтарыплар булмый, бер үткәч.
Сагыш дулкыннары басып ала,
Гомер йомгакларын бер сүткәч.
Үткәннәрне шулай сагыну бар,
Ничек кенә алар бетәдер...
Сагынулар бу дөньяда бәлки
Яшәү көчен бүләк итәдер?

**Урманда**

Урманнарда йөрим җырлый-җырлый,
Яңгыратып чыршы, наратын.
Әле уңга, әле сулга атлыйм,
Үзем белмим кая барасын.

Урман кошчыклары минем янда
Сайрый башлый бергә ашыгып.
Урман җырын суза ак каен да,
Наратлар да миңа кушылып.

Туктасам да, алар туктамыйлар,
Моңга моңнар кушып шаулыйлар.
Үзәкләргә үтеп керә торган
Кара урман җырын җырлыйлар.

Күреп туймас урман гүзәллеге,
Башын күккә чөйгән наратлар.
Аландагы имән ашкынадыр,
Юл чыгарга җиккән параттай.

Мин сокланып йөрим табигатькә,
Җырлап кара урман турында.
Шулай үтте инде гомерем дә,
Әйтерсең лә, урман юлында.

Җырларыма дуслар кушылдылар,
Күкрәк киереп гомер юлында.
Хәзер җырлар бетте,
Тик кайтаваз
Карурманның моңлы шавында.

## Яшьлегемдә калдың

*Лифә Насртдиновага*

Еракларда калдың, яшьлегемдә,
Үзәк өзгеч моңлы җыр сыман.
Кызлар үстерден син бүтән иргә,
Ник көтмәдең мине, җан гынам?

Юк, юк, кыз балаңа бер сүзем юк,
Гөлчәчәкләр үссен юлына.
Ләкин вәгъдәң бар иде бит миңа,
Ана булырмын, дип, улыңа.

Үкенечкә генә сөйгәнмен шул,
Тоз сибелгән минем җәрәхәт.
Яшьли сөйгән ярың ятка китсә,
Дөньяларда кала ни рәхәт?

Юл чатыннан ике якка киттек,
Сәбәпләрен эзләү файдасыз...
Сөю башкаларны кавыштырсын,
Йөрәкләре булыр ярасыз.

## Дәрья

Аккан дәрьяга карыйм мин,
Куәтенә сокланам.
Таулар ерып, ташлар ярып
Акканына таң калам.
Ярсып яр кимерә дулкын,
Агып китә ашыгып,
Ни очраса, барысын да
Үзе белән агызып.

Ашкына дәрья, ургыла,
Аямыйча бар көчен,
Киртәләр  җимереп, тизрәк
Диңгезгә  җитәр өчен.
Уйламый да, туктамый да,
Ашкынуы -ашкыну.
Ару да юк, талу да юк,
Өзлексез су ташкыны.

Әйтерсең, тик бер көн генә,
Бүген - яшәр вакыты.
Гүя шунда сыяр кебек
Яманы да, яхшысы.
Минем дә шул дәрья сыман
Ярсып яшисем килә.
Һәрбер көнем соңгы көндәй
Шаулап гөрлисем килә.

### Шигырь

*Бәхетлеләр шигырь язмый.*
*Шәмсия Җиһангирова*

Ни дип кулга каләм ала кеше,
Мондый шөгыль ансат түгел лә;
Әллә шулай бераз бушанамы
Күңелдәге авыр йөгеннән?

Моңлы көйгә салып,
Ник шигырьне
Яза икән адәм баласы;
Көрчегенә җиткәч, шигъри юллар
Тезә микән әллә чарасыз?

Шигырь диңгезенә чумган чакта
Онытамы хәсрәт- сагышын;
Әллә шул мохиттә эзли микән
Югалтулар түгел, табышын?

Йөрәккәе дөрләп янганда да,
Бәгырьләре бозга катса да,
Каләм ала микән кулга кеше
Кайгы упкынына батса да?

Бәндә нигә шигырь яза?- дисәң,
Җиңел генә сыман соравы.
Аптырарсың җавап табалмыйча,
Сорау гади тик бер каравы.

## **Җырлап китәсем килә**

*Җырлап үләрмен мин үлгәндә дә...*
*Габдулла Тукай*

Елап килгәнмендер бу дөньяга,
Җырлап китәсем килә.
Мәңгелеккә җырлый-җырлый китү
Үзе бер бәхет диләр.

Җырлап яшәдем бит җирдә,
Җырлар
Никтер мине ошатты.
Биек күккә чөйде башларымны,
Җигеп куйды паратны.

Күпме генә еллар үтсә, үтсен,
Җырлар һаман күңелдә.
Гомер буе тугъры җан юлдашым,
Җырлап яшим бүген дә.

Кемнең, кайчан, ничек китәчәген
Ходайдан тыш кем белә?
Гүзәл гомеремә җырлый-җырлый,
Хуш, дип әйтәсем килә.

Тормыш дәрьясында йөзгән чакта
Чоңгыллар күп очрады.
Упкыннарга җырлар төшермәде,
Җаным күккә очмады.

Авыр кайгы төшсә, бер таяныч
Булды миңа җырларым.
Җырда таптым куәт,
Таратырлык
Хәсрәтләр, сагышларым.

Җырлап үтәлдем бит алга килгән
Чокыр-чакыр, киртәсен.
Елап килсәм дә мин бу дөньяга,
Килә җырлап китәсем.

## Фатихалар

Изге теләкләрен тели- тели,
Фатихасын бирде картнәем.
Мине озатканда дога кылды
Ак фатиха белән әнкәем.

Кара төннәремдә фатихалар
Якты нурлар сибеп тордылар.
Бозлы усал яңгыр яуган чакта
Баш өстемә чатыр кордылар.

Кар-буранлы авыр юлларымда
Хәвефләрдән мине саклады
Изге фатихалар.
Алар яклап,
Кара  гайбәт миңа якмады.

Аягымнан егар өчен килсә
Мәкерле җан, бозык канлылар,
Абынсам да,
Юлдан тайпылсам да,
Фатихалар тотып калдылар.

Изге фатихалар көчен тоеп,
Җир йөзендә яшим бүген дә.
Картнәемнең,
Газиз әнкәемнең
Фатихасы күңел түрендә.

## Зәңгәр күгем

Күгем йөзләре бик чытык бүген,
Нурлары да сүнгән, сүрелгән.
Тирән сагыш тулганмыни аңа,
Күкнең сөремнәре сөрелгән.

Кинәт кенә үксеп-үксеп куя,
Тамчы-тамчы авыр яшь түгеп.
Кемгәдер ул рәнҗегән дә сыман,
Әллә бетмәс кайгың бар, күгем?

Күңелләрең тулса, әйдә, ела,
Эчең бушаганчы яшең түк.
Ләкин сагышларга, кайгыларга
Бик бирешмә әле, зәңгәр күк.

Гел генә тик кара йөзле булма,
Мәңге түгел синдә болытлар.
Вакыт җиткәч, таралырлар әле,
Тере җанда сүнмәс өмет бар!

Килер бер көн, көләч кояш чыгар,
Төпсез зәңгәр күзләр карасын:
Җир өстендә шактый озын юллар
Бар бит әле бергә барасы.

Йөрәк җилкендереп, шул юллардан
Дәртле күңел белән атларбыз.
Кара болыт тулган көннәрне без
Онытырбыз, артка ташларбыз.

Һичбер күрелмәгән олы галәм
Безне еракларга чакыра.
Сагышыңны оныт.
Әйдә, киттек.
Алда килер көннәр яктырак.

## Бүтән мин хәзер

Үткән елларыңны эзләмә син,
Үлән баскан аны, ул беткән.
Уфтанма да, юллар югалган дип,
Син дә башка хәзер, мин бүтән.

Ак томаннар арасында калды,
Дәртле, шаулы яшьлек, юк күптән.
Кайда яшьлегем, дип, үрсәләнмә,
Син дә башка хәзер, мин бүтән.

Үткән гомер гүзәл бер мизгелдәй,
Кайтарыплар алу юк икән.
Сагыш калсын үткән гомер белән,
Син дә башка хәзер, мин бүтән.

Борылыплар баксаң, артта күпме
Онытылмас еллар!
Тиз үткән...
Үткәннәргә салават, дип, китик,
Дөнья башка хәзер, без бүтән.

## Юлларда

Юллар тартып тора үзләренә,
Чакрымнарын саный кешеләр.
Һәр юлчының барыр юлы үзгә,
Һәрберсенең йөрер эше бар.

Изге максат, зур өметләр белән
Байтак гомер үтә юлларда.
Яшәвең дә- чынлап яшәү бит ул,
Алларыңда сиңа юл барда.

Бөтен дөньядагы хәл-әхвәлне
Сөйләп бирә юлдаш күршеләр.
Кайда, ни булганын ачып сала,
Бар да юлчы, синең ишеләр.

Ниләр ишетмисең юл йөргәндә,
Ни күрмисең барган җирендә -
Бусагада гына калганда да,
Утырсаң да өйнең түрендә.

Кемнәр генә юлга якын булсын,
Юлчыларга карап калалар.
Никтер, кая йөрәк ашкына, дип,
Юл турында хыялланалар.

Соңрак инде алар юлчы була,
Ә мин торам юллар буенда.
Эх, көнләшәм шул юл йөрүчедән,
Юлга чыгу гына уемда.

Юлчымы син, юкмы,
Тик барыбер
Юлга бәйле һәрчак гомерләр.
Һич бетмәсен иде барыр юллар,
Юллар булса, алда гомер бар.

## Гомер үтә диләр

Гомер диләр, үтә диләр,
Ул ничек үтә икән,
Юлларында тирән эзләр
Калдырып китә микән?
Үтә микән таныш юлдан
Акбүз атка атланып,
Әллә туры кашка җигеп
Үтә яңа юл салып?

Гомер диләр, үтә диләр,
Үтүләре тиз диләр.
Мөгаен, шуңадыр аның
Үткәнен дә сизмиләр.
Үтә микән гомер күктә
Болытлар белән агып,
Әллә  җилләр белән бергә
Үтәме тәрәз кагып?

Гомер диләр, үтә диләр,
Әйләнеп кайтмый кире.
Жәлләмичә ташлап китә
Сөйгәнен, туган җирен.
Әллә гомер китә микән
Сулар ташкыны белән,
Диңгезләргә омтыламы
Яшьлек ашкыну белән?

Гомер диләр, үтә диләр,
Үтәрен кем уйлаган?
Гомер  үтәр юлларына
Ходай киртә куймаган...

## Никтер килми китәсем

*Ник үлемнән куркыйм? Аны бит тик бер генә*
*Күрәм, вакыт үземә җиткәндә генә.*
*О. Хәйям*

Бер куркакка гына килми бит ул,
Җирдә кыюлар да үлемле.
Бу дөньяда кемнәр яшәсә дә,
Вакыт җиткәч, киткән түгелме?

Ул миңа да килер сәгатендә,
Башкаларга килгән шикелле.
Монда калыр яшәгән бар гомер,
Атларым да калыр җигүле.

Теге дөньяларда булмас, диләр,
Омтылышлар, дөрләп янулар,
Үзәкләрне өзгеч сагышлар да,
Күңел тулы хәсрәт-кайгылар.

Анда йөрәк янып сөйгән ярлар,
Атам-анам, туган, дусларым.
Очрашырбыз, анда булмыйдыр да
Җәфалану, авыр юл ярып.

Җиңел булыр анда эшсез-нисез,
Уйламассың гомер үтәсен.
...
Ләкин шушы авыр дөньяны да
Никтер килми ташлап китәсем.

## Әдерәсмән

Әдерәсмән дигән затлы үлән
Озак  эзләп йөрдем далада.
Бик шифалы үлән, диләр  аны,
Алып кайтмакчымын калага.

Җыйнап алсаң,  имеш, шул үләнне,
Өйгә элеп куйсаң көлтәсен,
Бәла-каза, хәсрәт бетә, диләр,
Бәхет-шатлык кына көтәсең.

Ә далада кызу, эссе, җил юк,
Саргаешкан инде үләннәр;
Кайберләре яши сыман әле,
Кайберләре янып үлгәннәр.

Шулар арасында әдерәсмән,
Кечкенә бер яшел куактай.
Тап-тар яфраклары очлы башын
Күккә төбәп тора  кыяктай.

Гади генә, вак-вак кына аның
Аксыл чәчәкләре түбәндә...
Утырдым да  шунда, уйга чумдым,
Карап алдымдагы үләнгә.

Ниләр генә искә төшми икән!
Хәтерләдем үткән юлларым.
Кайгы-хәсрәтләрем, сагышларым,
Шатлык-куанычым,  җырларым,
Очрашулар белән аерылышу,
Миңа иң кадерле кешеләр,
Югалтулар белән табышларым-
Барысы да искә төштеләр.

Үкенерлек чаклар булган икән,
Шуларны мин уйлап, көендем.
Кешеләргә  кылган яхшылыгым
Искә төшкән саен сөендем.

Бераздан соң тынычланып калдым,
Бардыр әле алда елларым.
Тагын күрермен мин даласын да,
Туган якның урман, кырлыарын.

Эшләп бетермәгән эшләремне
Бетерермен,  Алла боерса.
Башкаларга яхшылыклар кылу
Бардыр әле, алда көн булса.

Гомер дәвам итә, баш имимче
Тик бүгенге хәсрәт, сагышка;
Өметләним әле якты көнгә,
Югалтулар түгел, табышка.

Әйдә үссен әле әдерәсмән,
Өзмим әле тик бер үземә.
Минем кебек тагын берәү килер,
Яше тыгылганда күзенә.

Ул да бер уйланып, тынычланыр,
Сагышларын шунда бетерер.
Әдерәсмән исә- изге үлән
Бик күпләргә бәхет китерер.

## Яшисе дә әле, яшисе

Шәрабсыз да әйләндерә башны
Бакча гөлләренең хуш исе.
Ничек ташлап китим шул дөньяны,
Яшисе дә әле, яшисе.

Дуслар белән аралашыр чагым,
Дөрлисе дә әле, гөрлисе.
Ничек аерылыйм мин алардан,
Яшисе дә әле, яшисе.

Үтелмәгән бит нихәтле дәрья,
Диңгезләрне ничек кичмисең?
Менелмәгән биек таулар да бар,
Яшисе дә әле, яшисе.

Баксаң, әнә нихәтле бит әле
Җирдә йөрисе дә, эшлисе.
Ничек барысын да ташлыйсың, ди,
Яшисе дә әле, яшисе.

Яшәргә, дип килдем бу дөньяга,
Мин нәкъ шушы дөнья кешесе.
Күпме вакыт бирсен, барысын алам,
Яшисе дә әле, яшисе!

## ЯШЬЛЕГЕМ КАЙТАВАЗЫ

### Мин һаман гашыйк сиңа

Шөкер итәм йөрәгемдә
Син урын алганыңа.
Бер генә дистә ел түгел,
Мин һаман гашыйк сиңа.

Яшь чакларда булды микән
Йөзеңә сокланмаган?
Хәзер сырлар капласа да,
Мин гашыйк аңа һаман.

Йөрәгемдә ут дөрләтте
Нурлы күзләрең балкып.
Нурлары сүнгәнен күрмим,
Хәзер дә сиңа гашыйк.

Бөдрә чәчләр чем-карасын
Саклыйм күңел түрендә.
Ап-ак хәзер дисәләр дә,
Мин гашыйкмын бүген дә.

Кайнар кызыл иреннәрең
Ялкын иде шул заман.
Сөекле шул иреннәргә
Мин гашыйк,
Гашыйк һаман.

Яшьлек үтте, дип үкенмим,
Үтте еллар сайрашып.
Син бүген дә япь-яшь миңа,
Мин һаман сиңа гашыйк.

Озын гомер юлларында
Гел терәк булдың миңа.
Рәхмәт сиңа, бердәнберем,
Мин һаман гашыйк сиңа.

## **Татар хатынына мәдхия**

*Әминә Сабит кызы истәлегенә*

Кемнәр сиңа китап багышламый,
Кем атамый сиңа җырларын,
Сиңа шигырь язмаган ир бармы?...
Мин дә яздым.
Мин дә җырладым.

Башкалардай мин дә гел сокландым
Зифа буйга, нурлы йөзләргә.
Мәхәббәтең белән чорнап алып,
Син исерттең мине хисләргә.

Мәхәббәтнең иң саф диңгезендә
Икәү бергә йөзгән чакларым
Һичкайчан да онытырлык түгел,
Мәңге күңелемдә сакლармын.

Сөекле яр сөйгән ярың өчен,
Син ана да, татар хатыны.
Җиргә тик бер татар китерсәң дә,
Мактанычы син үз халкыңның.

Аналарга изге хисләр тулы,
Тик әйтер сүз таба алмыйм мин.
Аналыкка лаек бөек сүзләр
Бер телдә дә юктыр,
Аңлыйм мин.

Гаиләнең нигезе дә син бит,
Терәге дә булдың син үзең.
Кыек тәгәрәсә уртак арба,
Аны турылаучы син идең.

Татар хатынының пөхтәлеге
Искитәрлек:
Бар да ялт итә.
Армый-талмый һаман тазалый ул,
Белмим,ул кай вакыт ял итә?

Борын-борыннан ук ашка-суга
Осталыгы белән данлыклы.
Ул саклый да, арттыра да белә
Гаиләдә муллык, байлыкны...

Ә шагыйрьләр хатын-кызны һаман
Гаҗәеп бер гөлгә тиңлиләр,
Сөйгән ярын чагыштырыр өчен
Берәр матур чәчәк эзлиләр.

Дөрестер ул, шулай
Хатыннарны
Гүзәл чәчәкләргә тиңләсәң;
Чәчкә кебек назлап түрдә тотсаң,
Аңа һич җил, яңгыр тимәсә;
Җирдә бар бурычың тик бер булса –
Шушы гүзәллекне сакларга;
Иркә кояш нуры һәрвакытта
Аңа төшсә төрле яклардан.

Хатынымны мин дә чәчкә итеп
Түргә куяр идем өемдә.
Вакытында сулар сибәр идем,
Торсын иде чәчкә көендә.

Дөнья бит ул, дөнья...
Беләм мин дә
Мондый хәлнең мөмкин түгелен...
Татар хатыны да арба тарта
Ире белән бергә җигелеп.

Арба тарту - түрдә  тору түгел,
Чәчкәләр дә тиздән коела.
Ә йөзләрдә  гөлләр назы түгел,
Кайгы-хәсрәт  эзе җыела.
(Ә бераздан үсеп җитә кызы-
Яңа буын  татар хатыны.
Ул да ире белән бергә  тарта
Уртак йөкне, алга ашкынып).

Татар хатынының менә шундый
Сәләтенә башым иям мин.
Чын күңелдән аңа:
Синнән башка
Мин дә юк бу җирдә, диям мин;
Кирәк сиңа китап багышларга,
Исемеңне ташка уярга,
Сиңа атап җырлар чыгарырга,
Сиңа диеп һәйкәл куярга.

Рәхмәтлемен татар хатынына,
Татар хатыны бит анам да,
Балаларым газиз анасы да,
Үсеп  җиткән  кызым-балам да.

Һәйкәл куялмадым сиңа атап,
Шигырь яздым, татар хатыны.
Кара төнне сиңа якты итсен
Ихтирамлы  йөрәк ялкыны.

## Акрын гына кар ява

Сагышларым эчкә сыйдыралмыйм,
Күңелемдә дөрләп ут яна.
Салкын кар да сүндерәлми аны,
Акрын гына җиргә кар ява.

Яраладың ялгыз йөрәгемне,
Тик бирмәдең миңа бер дәва.
Җәрәхәтле йөрәк көн-төн әрни,
Ә кар ява һаман, кар ява.

Нигә бергә киттең,
Булалмагач
Минем өчен сулар саф һава?
Уртак сукмак кар астында калган,
Өсләренә тагын кар ява.

Югалттым шул сине, табалмам да,
Йөрәккәем хәзер кан сава.
Кайнар каным җиргә тамган сыман,
Акрын гына һаман кар ява.

## Синең кулларың

Кая карыйм, шунда күренә
Онытылмас нәфис кулларың.
Синең җылы куллар эретә
Күңелемнең туңган бозларын.

Балкып чыга кояш офыктан,
Миңа табан суза нурларын.
Йомшак кына сыйпый битемнән-
Бу бит синең назлы кулларың.

Тик бер миңа нидер пышылдап
Акрын гына җилләр исәләр;
Чәчләремне җыя, тарата,
Синең куллар кебек иркәләп.

Тирә-якка хуш ис аңкыткан
Бакчадагы гөлләр сөйкемле.
Чәчәкләре миңа сузыла,
Гүя синең куллар шикелле.

Кыяр-кыймас яңгыр тамчысы
Иренемә тиде яшерен.
Бераз төшми торды, оялчын,
Уйлагандыр нидер әйтерен.
Тамчы түгелдер ул, иренгә
Тиде бугай синең кулларың.
Тамчы-тамчы яңгыр аралап,
Куллар ача барыр юлларым.

Кая карасам да, шунда мин
Күрәм синең нәфис кулларың.
Ярый әле, шулар эретә
Йөрәгемнең каткан бозларын.

## Йөрәктәге кояш яктысы

*Йөрәктәге кояш яктырак.*
*Роберт Миңнуллин*

Иркә карашыңа мин интизар,
Сине бер күрергә ымсынып,
Барыр юлларыңа кара төндә
Чыгып басар идем шәм булып.
Мин шуңа да риза,
Яннарыңда
Бер яктырткыч булыйм, ичмаса.
Юлларыңа нурлар сибеп торыйм,
Каршыларда киртә очраса.

Теләдем мин йөрер юлларыңа
Кояш нуры булып төшәргә.
Ләкин кояш күктә көндез генә.
Кара төннәр җиткәч, нишләргә?
Барыр юлларыңа юнәлтимме
Күктә ялгыз айның яктысын?
Ай яктысы җиңеп чыгалмас шул
Синең нурлы йөзең балкышын.

Йолдыз нурын синең юлларыңа
Борып куяр идем, бик ерак.
Чагыштырмыйм,
Ләкин күз карашың
Йолдыздан да ачык, яктырак.
Ай-кояш та, йолдыз гел яктыртмас,
Син борчылма,
Тормам аптырап.
Ал син минем кайнар йөрәгемне,
Йөрәк януларым яктырак.
Йөрәгемдә кояш яктырак.

## Адашмам бураннарда

Китмә әле, китмә, җаным,
Югалма томаннарда.
Берьялгызым юл табалмам,
Адашып бураннарда.

Көнләшепләр карап торам
Чөкердәшкән парларга.
Алар бер-берсенә терәк,
Адашмас бураннарда.

Бергә булу зур бәхет тә,
Шатлык җыры таңнарда.
Шул җыр безне адаштырмас
Күз ачмас бураннарда.

Сиңа гына таянам мин,
Мин тере тик син барда.
Һәрчак яннарымда булсаң,
Адашмам бураннарда.

## Очрашулар

Тик очраклы гына булган иде
Синең белән тәүге очрашу.
Тарттыниләрдер бер- беребезгә,
Никтер кирәк булды аңлашу.

Белмим, ничек шундый хисләр туды,
Йөрәгемдә җәйдең тамырлар.
Бергә корган бәхет дөньялары
Күңелемдә мәңге калырлар.

Язмыш безгә кырын карады шул,
Көтмәгәндә генә аерды;
Чиксез зәңгәр күктә очарлыктай
Көчле канатымны каерды.

Байтак еллар үтте, күрешмәдек,
Икебез дә ике якларда.
Кинәт бер очраштык, гүя кайттык
Бергә үткән гүзәл чакларга.

Тик бер төштәй булды бу очрашу,
Тик бер мизгел- бергә булулар.
Кинәт кенә хисләр яңаруы,
Дөрләп кабат йөрәк янулар.

Бик тиз җитте аерылыр көннәр,
Синең күзләр моңсу, сагышчан...
Китәм мин калдырып җырларымны,
Бер тыңларсың, бәгърем,
Сагынсаң.

## Ялгыз калмассың

Китәсең бит, кире кайтмассың, дип,
Күз яшеңне түкмә, матурым.
Мин барыбер бөтенләйгә  китмәм,
Җырым белән кире кайтырмын.

Китәсең дә,
Ялгыз итәсең шул,
Калдырасың, димә, ятларга.
Ялгыз түгел, исемем бит кала,
Мәхәббәтем - сине якларга.

Мин киткәчтен һич тә моңсуланма,
Хәсрәт диңгезенә чумма син.
Искә төшер,
Безгә күпме бәхет
Алып килде фани дөньясы!

Мин киткәч тә  өең якты булсын,
Утың сүндермә син кичләрен.
Алар маяк булыр.
Синең янга
Очып кайтыр кайнар хисләрем.

Һич калмассың ялгыз.
Синең белән
Гомер буе  бергә калалар
Мәхәббәтем, якты хатирәләр,
Җырларым да, теләк-догалар...

## Яшьли сөйгән ярыма хат

Уртак тормыш насыйп булмады шул,
Язмыш каршы чыкты, ахрысы.
Ә бит синдә генә иде миңа
Бу дөньяның кояш яктысы.

Азга гына диеп саубуллаштык,
Кавышырга вәгъдә бирештек.
Аерылгач, һәрбер көнен санап,
Хатлар аша хәлләр белештек.

Кайнар сөю хисе тулы хатлар
Дәва булды янган йөрәккә.
Хатлар куәт бирде
Йөрәгемнең
Ярсуларын басу кирәктә.

Нидер булды безгә, кинәт кенә
Көтмәгәндә юллар бүленде.
Ләкин миңа шушы бүленү дә
Вакытлыча булып күренде.

Тора-бара ераклашты ара,
Гаепледер моңа икебез.
Аерылган юллар кушылмады,
Икәү ике якка киттек без.

Юксынуым чиксез,
Күңел
Ашкындырды синең яныңа.
Очлы энә булып кадалдың син
Йөрәгемә, моңсу җаныма.

Айлар буе  истән чыкмадың син,
Еллар буе  оныта алмадым.
Кавышырбыз әле дигән өмет
Сүнде инде хәзер, калмады.

Тәкъдир микән, чит бер тәэсир микән,
Сәбәпләре калды билгесез...
Тик нигәдер искә төшкән саен
Өзелеп  йөрәк  әрни ирексез.

## **Җаныма юк урын**

*Җаныма да урын табалмыйм.*
*Марат Кәбиров*

Юк җаныма урын бүген,
Кая гына куйыйм башымны?
Синсез нишлим,
Серләремне
Урманнарга, кырга ачыйммы?

Һавадагы кошлар белән
Серләшимме әллә ялгызым,
Әллә сердәш итим микән
Үз иркендә очкан кыр казын?

Искән җилләр, аккан сулар
Булыр микән миңа сердәшем?
Килерсеңме яныма син,
Җылы сүзләр белән эндәшеп?

Бар дөньяда берьялгызым,
Сагышларга батам һаман мин.
Ялгыз башым нихәл итим,
Җаныма да урын табалмыйм.

## Язмышым син

*Кайгыммы син, бәхетемме?*
*Бәлки хатам, ялгышым?*
*Роберт Миңнуллин*

Ялгышыммы, әллә язмышыммы
Юлларымда сине очрату,
Тәкъдир дәфтәренә язылганмы
Сине сөю, сине ярату?

Белмим, нидер ике җан иясен
Бер-беренә тартып китерде;
Йөрәкләргә утлар кабындырып,
Нинди көчләр аны үстерде.

Бәхетен дә алып килде безгә,
Кайгысын да сөю ялкыны.
Кара корым тулы көннәр булды,
Елларның да булды алтыны.

Хаталанган чаклар байтак бугай,
Аңлашмаган чаклар күпме ул!
Кырын караш белән үткән бер көн
Чиксез авыр еллар төсле ул.

Агын, карасын да уйлаганда
Нинди бәя биреп, нишләргә?
Монда исәп-хисап ярамый шул,
Бизмән белән булмый үлчәргә.

Белмим һаман сиңа ни дияргә:
Бәхетемме, әллә ялгышым.
Хата булды микән, түгел микән,
Ләкин сиңа бәйле язмышым.

## Хатлар

Хатларыңны көттем зарыгып,
Зар-интизар булып түземсез.
Үзем беләм, килмәс хатларың,
Синнән хатлар көтү өметсез.

Хатларың да юк, син үзең дә,
Хатирәләр генә күңелдә.
Бергә үткән һәрбер мизгел дә
Мәңге-мәңге йөрәк түрендә.

Истәлекләр гүя хат миңа,
Кат-кат күз алдыма китерәм.
Ялкынлана хисләр яңадан,
Хисләремнән кабат исерәм.

Шул ялкыннар дөрли, җылыта,
Зәһәр котып җиле иссә дә.
Үткән гомер кайткан шикелле,
Ел артыннан еллар үтсә дә.
Кышын, язын, җәен, көзен дә
Һаман бергә кебек үзең дә.

## Бакчада

Күпме айлар үтеп китсә дә,
Синсез күпме таңнар атса да,
Карточкаңда  һаман япь -яшь син,
Елмаясың язгы бакчада.

Кем турында иде хыялың,
Ниләр уйладың син елмаеп?
Соклandырды микән алмагач,
Ап -ак чәчәк аткан ел саен.

Табигатьнең гүзәл мизгеле,
Хуш исләре бакча гөленең
Калдырдымы өнсез, тавышсыз,
Моңландымы бераз күңелең?

Син китсәң дә,
Шушы бакчада
Гөлләр тагын үсеп чыгалар.
Тирә -юньгә хуш ис аңкытып,
Гүя сине көтеп торалар.

Алмагач та һаман бакчада,
Чәчәк ата һәрчак яз килгәч.
Шушы чәчәкләрне иркәлим
Синең төсең итеп, син сөйгәч.

Фотокарточкаңа карыйм да,
Үткән гомер килә уема.
Бакчаларга чыксам,
Елмаеп
Син торасың кебек  тоела.

## Искән җилләр

Җилләр исә, искән җилләр
Туктамас, исәр әле.
Бергә булган һәрбер минут
Исеңә төшәр әле.

Таң җилләре искән чакта
Күңелеңдә яз булыр.
Саф мәхәббәт тулган йөрәк
Әллә кая ашкыныр.

Йомшак искән язгы җилләр
Сөю булып яңгырар.
Җилләрнең дә йөрәкләргә
Үтеп керер моңы бар.

Көзге җилнең исүләре
Үз моңына күмелгән.
Көзге моңнар сагышларны
Кузгатадыр күңелдә.

Гомер җиле ахыргача
Җыр булып исәр әле.
Шул җырларның бөтен моңы
Исеңә төшәр әле.

## Гүзәл

Төсле, җиңел күлмәк кигәнсең дә,
Су буенда басып торасың.
Итәкләреӊ белән җил шаяра,
Аргы якта синең карашың.

Син  дә  мине бәлки күрәсеңдер,
Сизгер  җандыр синдә, ышанам.
Синең кебек гүзәл юктыр  җирдә,
Булмас  җирдә сиңа охшаган.

Чәчләреӊ чем- кара ике толым,
Билеңнән  дә  түбән төшәләр.
Ялгыз каен зифа, ә шулай да
Син зифарак, миңа  дисәләр.

Йөрәгемә утлар кабыздың бит,
Тик бер генә миңа карачы!
Янган йөрәгемне сүндерергә
Күрсәт миңа берәр чарасын...

Менә тагын килдем су буена,
Төзәлмәсме йөрәк ярасы.
Нәкъ шул җирдә басып торган идең,
Хәзер сине кайдан табасы!?

**Китәм еракларга**

*Сәфәр китәм еракларга*

*Ркаил Зәйдулла*

Китәр вакытларым килеп җитте,
Атлар ихатада, җигүле.
Алда, белмим, нәрсә көтәр мине,
Артта гөлләр шавы, гөл иле.

Кочагымда йөгем берәү генә,
Алып китә алам сәфәргә
Кайнар мәхәббәтем.
Шул көч бирер
Киртәләрне ерып үтәргә.

Синең хакта якты хатирәләр
Таң йолдызы булыр күгемдә.
Җанга үз җылысын өстәп торыр
Хәтер учаклары күңелдә.

Бәлки берчак искә төшерерсең
Син дә мине бераз моңаеп.
Ләкин үткән көннәр кабатланмас,
Киткәннәргә кайтыр юл да юк.

Әгәр берәр дәва кирәк булса
Басар өчен йөрәк ярасын,
Бар син, бар син минем эзләремнән,
Адым саен моңнар табарсың.

## Соң инде

Күзләремә туры карадың син,
Карашыңда сагыш, моң иде.
Юату да, назлау көткәнсеңдер,
Юаталмам сине, соң инде.

Йөрәкләрне җилкендереп янган
Хисләр хәзер салкын, туң инде.
Сүнгән утлар кабат дөрләп китмәс,
Учак бозлап каткан, соң инде.

Безне бәйләп торган якты хисләр
Өзелмәстәй иде, нык иде.
Өзелгән шул.
Ничек бәйләсәң дә,
Ул төенле була, соң инде.

Алдыбызда якты кояш түгел,
Көннәр үткән, кара төн инде.
Нурлар сипкән сөю юкка чыккан,
Ул яңармас инде, соң инде.

Кулларыма кулың биргән чакта
Гомеремдә алсу таң иде.
Гомеремнең киче җитте хәзер,
Уртак таңнар атмас, соң инде.

**Гөлләр**

Синең өчен гөлләр утырттым,
Син аларны, зинһар, шиңдермә.
Суларын сип назлап, иркәләп,
Кояш янгынында көйдермә.

Үссен гөлләр, чәчкә атсыннар
Алсу, кызыл, зәңгәр, күк төсле.
Шул гөлләргә  бар да сокланыр,
Үтә-барган кеше юл өсте.

Үзеңә дә булыр юаныч
Чәчкәләрнең гөрләп үсүе.
Җиңеләер сиңа көтү дә,
Сизелмәс тә вакыт үтүе.

Чәчкәләрнең шавы күңелдә
Сөю хисе булып яңгырар.
Юксынулы төннәр кыскарыр,
Һәр төннең дә якты көне бар.

Сине һәм гөлләрем сагынып
Мин кайтырмын синең яныңа.
Мәхәббәтең- гөлләр чәчәге
Шифа булыр талган җаныма.

## Озатып калдың

Син озатып калдың мине,
Ә мин киттем ерак-еракка.
Тиз күрешеп булмас, ахры,
Аерылдык бугай озакка.

Синең йөзең бигрәк моңсу,
Күзләрең дә җиргә текәлгән.
Үзәкләрең өзеләдер,
Сагышларга сагыш өстәлгән.

Мин дә башым күтәрәлмим,
Аерылышу бик авыр бит.
Сыкрамачы, йөрәккәем,
Сыкрамачы, бераз сабыр ит.

Үтәр әле бу көннәр дә,
Очрашырбыз, бәлки, тагын тиз.
Кыш булмаса, язы җитәр,
Җәй булмаса, килер тагын көз.

Өметеңне бер дә өзмә,
Күрешербез, Алла боерса.
Тагын бергә серләшербез,
Куанышып гөрләшербез,
Син көт инде, яме?
Чыда инде, озак тоелса.

## Югалттым

Озын юллар үттем, сулар кичтем,
Көмеш табалмадым, юк алтын.
Алтын-көмешсез дә яшәр идем,
Ләкин сөеклемне югалттым.

Карлы биек таулар алда торса,
Киртә булса тирән дәрьялар,
Артка чигенмәдем.
Барыр көчне
Биреп торды газиз сөйгән яр.

Авыр чакта ышанычым, терәк,
Аралады хәсрәт-кайгымнан.
Аның җан җылысы, тән җылысы
Ышыклады ачы салкыннан.

Язмыш кисте безнең уртак юлны,
Икәү ике якта мәңгегә.
Калмады бу җирдә гүзәллек тә,
Күрмим мин бернинди ямьне дә.

Хәзер котыра җил, тынгы бирми,
Гүя миндә генә бар үче.
Өзгәләп тә, кырып ташлар иде,
Аямастан,
Җигеп бар көчен.

Кояш нурлары да төшми миңа,
Каерылды очар канатым.
Канатсыз да, бәлки, яшәр идем,
Бердәнберемне мин югалттым.

## Хатлар көттем

Синең  бер сүзеңә интизар,
Өзелеп хатлар көттем, сагынып.
Сагышларым ташып чыга бит,
Бу дөньяда яшим тарсынып.

Җәйге  гөлләр исе исерткеч,
Авыз  ера кояш шатланып.
Минем генә күңел төшенке,
Йөрим хатлар юкка зарланып.

Яңгырлы көз килә, ямансу,
Җәй белән җир гүя хушлаша.
Сагышланмас идем шул кадәр,
Хәлләреңне белсәм хат аша.

Кышын хөкем сөрә салкыннар,
Урап-урап ява карлары.
Эрер иде йөрәк бозлары,
Әгәр килсә җылы хатларың.

Очар кошлар кайта еракта н,
Язгы җилләр йөрәк җилкетә.
Басылыр да иде җилкенү,
Сагынып озак көткән хат килсә.

Өметләнеп көттем хатыңны,
Кош теледәй генә булса да.
Ләкин килмәде шул,
Килмәде,
Айлар арты айлар узса да.

Һәр көн саен синең хатларың
Менә-менә килер кебекләр.
Язмыйсың шул,
Килми хатларың.
Сүнде инде, сүнде өметләр.

## Була икән, диләр

*Фелизага*

Була икән, диләр,
Шытып чыга
Картлыкта да яшьлек тойгысы;
Йөрәкләрнең дөрләп януы да,
Мәхәббәтнең сагыш, кайгысы.

Еллар йөген атып бәргәнмени,
Йөрәк үрле-кырлы сикерә.
Ә күңелләр картны яшьлегенә
Алып бара сыман өстерәп.

Кемдер шул тойгыны бүгенгәчә
Саклап алып килгән яшьлектән.
Кайберәүләр юлда югалткандыр,
Табалмыйча күпме яшь түккән.

Кайбер бәхетсезе гомер буе
Бик эзләп тә таба алмаган.
Булмый андый нәрсә җирдә, диеп,
Мескен үзен-үзе алдаган.

Ходай бәндәсе бит барысы да,
Сөю килгән менә картайгач...
Җимешләре дә юк,
Тик барыбер
Ел да яшелләнә карт агач.

## Төшер исеңә

*Төшер мине исеңә.*
*Макагали Макатаев*

Берчак әгәр йөрәк серләреңне
Ачар булсаң башка кешегә,
Каршы булмам.
Тик ашыкма,
Төшер әле мине исеңә.
Мин килермен шундук күз адыңа,
Көтәм диеп, эчтән чакыр гына.
Саф хисләрем терәк булыр сиңа,
Җиткәнче үз юлың ахырына.

Дөнья бит ул, авыр чагы булыр,
Таян ышанычлы ишеңә.
Таянырлык ишең табылмаса,
Шулчак мине төшер исеңә.
Мин чыгармын барыр юлларыңа,
Мин килермен синең уйларыңа.
Бергә булмасак та, ераклардан
Көч бирермен синең кулларыңа.

Аерылсак та, күңел һаман бергә,
Мин керермен төнге төшеңә.
Өннәремдә бергә булыйк дисәң,
Төшер мине көндез исеңә.
Ачы сагыш басса күңелләрне,
Йөрәк сыкрап торган бер мәлләрне,
Сагынганда искә төшер мине,
Искә төшер татлы мизгелләрне.

## Күңелем сине эзләде

Икәү генә идек бер бүлмәдә,
Тезләремә куйдың башыңны.
Шул мизгелдә ямьле җылы яз дип
Хис иттем мин салкын кышымны.

Тыным кысылганга дәшәлмәдем,
Тик чәчләрең белән уйнадым.
Кара бөдрә калын чәч толымын
Бер үреп, бер сүтеп карадым.

Алсу иреннәрең якын иде,
Суырыплар үптем, туймадым.
Шушы сөю белән икәү бергә
Гомер итәрбез, дип уйладым.

Алла боерса дип әйтмәгәнмен,
Ахры, шуңа юл бер булмады.
...
Күңел һәрчак сине эзләп торды,
Гомерем буе сине уйладым.

## Яшьлегем кайтавазы

Язмыш очраштырды берчак безне,
Онытылып сине тыңладым.
Сокланырлык кайнар хисләреңне
Моңлы көйгә кушып җырладың.
Яшьлегемнең кайтавазы булып
Ишетелә бүген җырларың.

Очраштырган тәкъдир аерды да,
Кавышмаслык итте мәңгегә.
Сүндерде ул бөтен өметне дә,
Бергә без яндырган шәмне дә.
Җаным әрни,  күңелемдә сагыш,
Уйларымда тик бер син генә.

Җырларым да хәзер яңгырамый,
Көйләрем юк инде, сынды саз.
Кайда шатлык, күтәренке күңел,
Минем өчен кайда көн аяз?
Синең җырлар гына йөрәгемдә-
Яшьлегемнән килгән кайтаваз.

Тик бер генә мизгел бирелсә дә
Сине күрер өчен, ичмасам,
Шатлык көне кире кайтыр иде,
Сиңа кушылып бер җырласам.
Каңгырыплар йөрер идеммени,
Җирдә синсез ятим булмасам.

Синсез үтә көннәр, айларым да,
Җәем-көзем, бар кыш, бар язы.
Йөрәк яна, тынгы таба алмыйм,
Гүя парын җуйган  кыр казы.
Колагымда синең моңлы җырлар-
Яшьлегемнең бер кайтавазы.

## КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР

### Чылбыр бoжрасы

Мин чылбырның бер бoжрасы гына,
Ата-бабаларым мирасы.
Миннән алда күпме буын үткән,
Шуңа мин дә җирдә торасы.

Шул буыннар барлык хыялларын,
Өметләрен миңа баглаган.
Тәңремә мең шөкер,
Безнең чылбыр
Өзелмәгән, юкка чыкмаган.

Бабаларым изге хыяллары
Әкияттән күчкән чынлыкка.
Шуның өчен эшли һәрбер буын,
Исем саклап, төшми хурлыкка.

Көннәр, еллар төрле-төрле була,
Күрәсең, бер шундый тәкъдир ул.
Үзеңнән тик яхшы эшләреңне
Кирәк мирас итеп калдыру.

Вакыт җитеп, мәңгелеккә китсәм,
Җирдә яшәр минем балалар.
Ә аларны ялгап оныкларым
Яңа буын булып калалар.

Киләчәктә берәр ерак буын
Искә алыр, бәлки, мине дә,
Ата-бабаларым яшәгән, дип,
Намус белән якты көнендә.

Мин чылбырның бер бoжрасы гына,
Ялгап торам газиз нәселем.
Гасырлардан күчәм гасырларга,
Мәңге аккан кебек Иделем.

## **Ерак буыннарга**

*Киләчәккә хатлар*

*Һади Такташ*

*Сүзләреңне калдыр нәселеңә бүләккә*

*Махтумкули*

Нәселемә калсын мирас булып
Чын күңелдән әйткән сүзләрем.
Ерак буыннарга барып җитсен,
Йөрәкләрдә салсын эзләрен.

Сез тәүгеләр түгел бу дөньяда,
Сезгә кадәр без дә яшәдек.
Утларында дөрләп яндык без дә,
Ничек белсәк, шулай яшьнәдек.

Мәхәббәт тә кайнар, ярсу булды,
Хисләр кочагында оныттылдык.
Тик ятмадык йоклап.
Биеклеккә,
Югарыга һаман омтылдык.

Авырлыктан читкә тайпылмадык,
Киләчәккә баглап өметләр.
Хәзер сезгә ата-баба,
Алар-
Назлап без үстергән егетләр.

Җирдә яшәү- үзе гүзәл бер җыр,
Аны үзебезчә җырладык.
Күңел ачам, дисәң, шаян җыр бар,
Моңлы җаннарга да җыр азык.

Туры килде күпме сугышырга,
Аларны без башламасак та.
Канибызны койдык,
Ләкин данын
Башка халык алды азакта.

Җирдә күпме эшләр кала сезгә,
Без эшләгәне дә байтактыр.
Бөтенесе белән мактаналмыйм,
Хаталар да кылдык кайчаклар.

Уйланабыз, нинди булыр диеп,
Киләчәктә килер буыннар;
Ямьле көе сакланырмы диеп,
Сөеп без яшәгән урыннар.

Әйе, безне борынгылар диеп,
Үзегезчә юллар салырсыз.
Шулай да бер-ике сүз әйтимче,
Бәлки игътибарга алырсыз.

Безгә тигән бу җир сезгә кала,
Кала бөек газиз халкыбыз.
Киләчәктә туган халык өчен
Армый-талмый алга барыгыз.

Артка һич калмагыз,
Юкка чыга
Артта кала торган халыклар.
Горурланып гел әйтерлек булсын:
Җир йөзендә безнең халык бар!

Сездән хөрмәт күрсен татар халкы,
Шунда таныр аны башкалар.
Үзеңә дә ул кадерсез булса,
Ни кирәге бар, ди, башкага?

Безнең язмыш җиңел генә түгел,
Байтак җәбер күрде халкыбыз.
Күпме җирен дошман тартып алды,
Азатлыгыннан да мәхрүм калды,
Азат булырга без хаклыбыз!

Ирек өчен көрәш алда әле,
Булдыклы да, батыр булыгыз.
Бирмәс беркем дә китереп ирек,
Үзең көрәшмәсәң күкрәк киереп,
Изге булсын йөрер юлыгыз.

Татар теле барсын киләчәккә,
Туган телгә уклар атмагыз!
Теле булган халык кына тере,
Гүзәл татар телен саклагыз.

Ана-җирне кадерләгез сөеп,
Монда башкалар да яшәрләр.
Сез дә мәңгелеккә килмәгәнсез,
Сездән соң да килеп китәрләр.

Безнең хаталарны кабатламый,
Газиз милләтне сез саклагыз.
...
Сезгә имин дөнья, бәхет теләп,
Бик еракта калган бабагыз.

## Һәркемнең үз җыры

Яшәү-  бер  җыр һәр җан иясенә,
Яңгыравы  аның төрлечә:
Кемдә ишетелер-ишетелмәс,
Кемдер күк күкрәтә үзенчә.

Кай  җыр - җиргә тамган су тамчысы,
Кайсы- таш актарган Чулманы,
Биюе бар, бәет, такмаклары,
Моң-зар тулы  «Кара урманы».

Кайсы  - качып-посып көн күрүдер,
Кайсы -  йолдызларга омтылу;
Кайсы-  туп-туры юл,
Ә бәгъзесе-
Хәкыйкатьтән читкә тайпылу.

Кайбер  җанның  җыры бөртек кенә,
Кемдә була биек  җыр тавы.
Тик бер генә мизгел бөҗәк җыры,
Күпме еллар бөркет  җырлавы!

Изге ана сөте бар җырларда,
Ата юлы, бала назлары,
Ярсып сөю, гомер язы,  җәе,
Салкын кышы, гүзәл язлары.

Җан ачысы белән һәрбер җырның
Килеп  җитә берчак  азагы...
Үзгә моңлы «Кар-кар» тавышы да,
Булса бәхилләшү авазы.

## Комда калган эзләр

Ком өстендә төрле эзләр калган,
Санап бетергесез, бихисап.
Озын чылбыр булып сузылганнар,
Кайберләре төшкән ике саф.

Кешеләр дә  эзен салган монда,
Әллә нинди кошлар, хайваннар.
Ачык күренерлек эзләр дә бар,
Башка эз астында калган бар.

Ком өстендә эзләр озак тормый,
Тиз югала алар комнарда.
Гүя һичбер вакыт булмаганнар,
Төшмәгәннәр комлы юлларга.

Ярга якын эзне ялап-ялмап
Дулкын белән алып су китә;
Комга вак-төякләр куша да ул,
Шул арада эзне  юк итә.

Тапталып та бетә кайбер эзләр,
Тагын бүтәннәрен салалар.
Элеккеге эзләр  югалалар,
Эз астында юкка чыгалар.

Яңгыр явар булса,  саклап булмый
Ком өстендә калган  эзләрне.
Суын җәлләмичә, коеп, түгеп,
Яңгыр ашап куя шул мәлне.

Җилләргә дә каршы тора алмый
Ком  өстендә калган шул эзләр.
Йә бу яктан, йә тегеннән өреп,
Җил барыбер җирне тигезләр.

Кешеләр дә байтак эз калдыра,
Кайберләре комга салган күк.
Бераздан соң ул эз табылмый да,
Бер мизгеллек кенә булган тик.

Кайбер эзләр ташка уйган кебек,
Менә шулар яши гасырлар.
Гасырларда калып сакланырлык
Эзләр сала җирдә батырлар.

Сугышларда гына түгел бит ул
Батырлыкның бик күп төрләре,
Кан коймаган тыныч кешедән дә
Кала батырга тиң эзләре.

Шул эзләрдә аның хезмәтләре,
Шул эзләрдә кылган эшләре,
Кешеләргә булган ихтирамы,
Изге уйлы иртә-кичләре.

Күпме вакыт эз күренеп торса,
Шушы дәвер кеше исән ул.
...
Мин дә бераз эзләр салган идем,
Комда гына түгел микән ул?

## Диңгез дулкыны

Йөзә-йөзә диңгез өсләрендә,
Дулкыннары белән ярышам.
Дулкын мине үз юлына тарта,
Ә мин аңа һаман карышам.

Дулкын юлы  ул минеке түгел,
Башка тараф минем юнәлеш.
Дулкын орып-сугып кауя,
Ләкин
Үз юлымда булмас үзгәреш.

Ачуланма, дулкын, мин дә беләм,
Синдә чиксез куәт, су көче.
Әмма мин дә бер йомычка түгел,
Адәм баласымын.
Мин кеше!

## Юл чатында

Юл чатында туктап калдым,
Кай тарафка барыйм  икән:
Уң яккамы, сул яккамы,
Йә  туры юл сайлыйм микән?

Һәр тараф та үзгә диләр,
Әгәр китәр булсаң сулга,
Уен-көлке генә сиңа
Туры килер шушы юлда.

Эшләү-мазар юк, ди,  монда,
Яшисең, ди, эшсез килеш;
Бар белгәнең  күңел ачу,
Өзлексез бер бәйрәм, имеш.

Гүр кызлары, яшь егетләр
Урап ала, имеш, сине;
Бер мәҗлестән бер мәҗлескә
Йөртерләр, ди, көне-төне.

Теләгәнчә арак-шәраб,
Теләгән бер җиләк-җимеш.
Кем сайласа шушы юлны,
Аңа рәхәт булыр, имеш...

Әгәр китсәң уң тарфка,
Югарыга менәрсең, ди,
Булсаң да син ялкау гына,
Эшлексез, бер һөнәрсез, ди.

Акылың да кирәк түгел,
Барыбер син хаким, имеш,
Конторы да, зур кабинет-
Барысы да сиңа тиеш.

Синең әйтер сүзләрең дә
Кирәксез, ди, башкаларга.
Син түгел бит, әнә шулар
Ашыга эш башкарырга.

Күзле бүкән булып кына
Кабинетта утырасың.
Әйтерсең лә, син дә шунда
Файдалы эш  башкарасың.

Бармы хаким, юкмы хаким,
Кызык түгел берәүгә дә.
Мондый бәндә яраксыз бит
Бер диварны терәүгә дә.

Еллар үтәр, ә син һаман
Шулай хаким булырсың,  ди;
Кабинетта ялгыз гына
Гомерең уздырырсың, ди...

Әгәр туры китәр булсаң,
Төрле хәлләр очрар, имеш;
Авырлыклар белән сине
Бу юл байтак сынар, имеш.

Белмәссең, ди, алдан үзең
Сине ниләр көтәсен дә,
Фани гомер ничек узып,
Кайчан, кайда бетәсен дә.

Чыдармы бу, юкмы диеп,
Бирер, имеш, сиңа язмыш
Мул кул белән хәсрәтен дә,
Ачы кайгы, тирән сагыш.

Кайгыларга чумган чакта
Җан дусларың булыр терәк,
Хәсрәтеңне бүлешергә
Үзеңә тиң чын дус кирәк.

Күтәренке күңел белән
Йөргән чак та була, имеш.
Кайчагында көнең-төнең
Шатлыкларга тула , имеш.

Шатлыкларың эчкә сыймас,
Бәйрәм булыр бераз вакыт.
Ләкин мөмкин түгел гелән
Ялкаулану,  кырын ятып.

Авыр булса, авыр булыр,
Эшләрсең, ди, тирең түгеп.
Кешеләргә кирәк бит син,
Куанырсың шуны сизеп.

Хәләл хезмәт белән генә
Үз көнеңне күрерсең, ди;
Яшәүнең дә, эшләүнең дә
Кадерләрен белерсең, ди...

Гомеремнең юл чатында
Кай тарафка китим, дисәм,
Уңга, сулга борылыйммы,
Туп-туры юл үтим микән?
...
Юллар кайларга илтәсен
Тик син үзең  хәл итәсең.

## Туктама

Туктап торма аптырап,
Алда дөнья яктырак.
Өмет өзмә бүген дә,
Бу хәл мәңге түгел лә!

Ачып куй җил капкасын,
Чыгып алга атларсың.
Җан биргәнгә  юнь бирә
Үзең йөргәнгә күрә.

Чарла акыл пәкесен,
Йоклап яткан үкенсен.
Ә син әйдә, туктама,
Туктаганнар тукмала.

## Картлык хисабы

Кайчан башлана соң картлык чоры,
Ничә яшьтән китә бу хисап?
Бу сорауга җавап әллә ничә,
Бу турыда фикер бихисап.

Кайберәүләр әйтүенчә, картлык
Кырык-илле яшьтән башлана.
Алтмышны да картлык башы диеп,
Җитмешне дә әйтә башкалар.

Баксаң, барысы да дөрес сыман,
Кайбер кеше картлач кырыкта;
Икенчесе һаман ир уртасы,
Җирдә җитмеш еллап торып та.

Ә бер агай, туксан яшен узгач,
Санаса да үзен карт диеп,
Күренеше яшь-җилкенчәк кебек,
Һаман йөри җырлап һәм биеп.

Азрак эче пошып китә калса,
Әйтеп куя ул чын күңелдән:
«Эх, егетләр, әгәр кайтса тагын
Минем җитмешбиш яшь кенә чагым,
Гөрләр иде дөньям бүгеннән».

Унсигез яшь берәр кайтса диеп,
Күпләр карый яшьлек ягына.
Ә бу агай унсигезен түгел,
Үткән җитмешбишен сагына.

Шул сагынган еллар аның өчен
Көчсез, мескен картлык түгелдер,
Яшьлек елларына тиң булырлык
Шаулап үткәрелгән гомердер.

Белмим, картлык кайчан башланадыр,
Кайда аның тәүге ноктасы.
Һәркем өчен бер үк түгел бит ул
Газиз гомернең дә уртасы.

## Фәрештә

Төшемдә мин бер фәрештә күрдем,
Килгән, имеш, миңа Ходайдан.
Гөнаһларым ярлыкаган икән,
Бик канәгать, имеш, болай да.

Саваплы дип кылган эшләрем дә
Күктә, имеш, төгәл язылган.
Мондыйлары  байтак булган икән,
Үзем онытканнар табылган.

Шуңа күрә  әмер иңгән, имеш,
Җирнең җиденче кат күгеннән,
Миңа күчеп китү рөхсәт икән
Шул сәгатьтә, менә бүгеннән.

Ике йөз  ел  алга күчеп барып,
Мөмкин икән шунда торырга.
Анда миңа һичбер кыенчылык
Булмас, имеш, тормыш корырга.

Анда юк, ди, ачлык, ялангачлык,
Имеш, анда кайгы күрмиләр;
Сугыш дисәң, аның ни икәнен
Андагылар, имеш, белми дә.

Бик куанып моңа риза булдым,
Чиксез дә бит Ходай кодрәте!
Уйлап кына акыл җитәр түгел
Үз колына дигән рәхмәте.

Анда мине тыныч тормыш көтә,
Монда кала хәсрәт, сагышлар.
Анда яшәү гел шатлыклы булыр,
Анда искитәрлек табыш бар.

Анда бардыр ерак нәселләрем,
Рәхәт яшәп, тыныч үләрмен...
Тукта әле, мәйтәм үз-үземә,
Бу турыда кемгә сөйләрмен?

Анда юк бит минем туганнарым,
Юк белүче мине, дусларым;
Җирдән киткән хәтта оныкларым,
Газиз балаларым, улларым.

Кем белән мин күңел күтәрәм, ди,
Кем алдында ачам серемне;
Анда мине тыңлар кеше дә юк,
Япа-ялгыз калам түгелме?

Юктыр анда минем хезмәтләрем,
Юк яратып эшләр эшләрем,
Ни дип тырышырмын соң мин анда,
Чит дөньяда ялгыз нишләрмен?

Эх, мин әйтәм, бигрәк жәл дә инде,
Ләкин күчеп булмас, мөгаен.
Ничек ташлап китим бу дөньяны,
Сагынырмын җирне көн саен.

Ә фәрештә мине ашыктыра,
Мондый форсат ике килмәс, ди;
Тизрәк киттек,
Синең юклыгыңны
Җирдә күпләр хәтта сизмәс, ди.

Шул чагында мин уянып киттем,
Ярый әле, таныш бүлмәдә.
Хәзерге бу минем тормышымны
Фәрештә дә, рәхмәт,бүлмәгән.

Ә шулай да кайчак уйга калам,
Шул фәрештә тагын килсә, дип;
Нинди карар кабул итим икән,
Калыйм микән, әллә китим микән,
Шул форсатны кабат  бирсә, дип.

## Корыган елга

Бик сагынып кына килгән идем,
Корытканнар гүзәл елгамны.
Ышанырлык түгел - су коену,
Балык тоту шунда булганы.

Елгакаем, сиңа нәрсә булды,
Кем вәхшилек кылды шул чаклы?
Бер тамчы да суың калмаган бит,
Төбең генә чуер-күк ташлы.

Ярларың да яп-ялангач шәрә,
Куак түгел, үлән калмаган.
Моны кылган бәндә имансыздыр,
Бер юньсездер, эшкә уңмаган.

Бәлки шатланадыр
Су юк диеп,
Елга төбе хәзер коп-коры,
Кичү дигән нәрсә кирәк түгел,
Кайда барсаң, шунда юл туры.

И адәм зат! Синнән дә шәфкатьсез
Берәр җан иясе бар микән?
Көне-төне җирне бозазың бит,
Иркен дөнья сиңа тар микән?

Урманнарын кырдың агач кисеп,
Чүлгә әйләндерден даласын.
Табигатьне ашап бетерәсең,
Оныкларыңа ни кала соң?

Оныклар  да бу дөньяга килер
Тулы хокук белән яшәргә.
Җирдә  ком бураны уйнап торса,
Оныкларга  җирдә нишләргә?

Очып китсеннәрме  урын эзләп,
Газиз җирне ташлап, калдырып?
Бөтен галәмдә  бер килмешәктәй
Сукбай булсыннармы, каңгырып?

Әллә берсен-берсе  «ашасынмы»,
Каргый- каргый  ата-бабасын?
Шундый хәлне  Җиргә  күрсәтмәсен,
Мондый хәлдән Аллам сакласын!

Нәфис җирне нәфис килеш кенә
Мирас  итик килер буынга.
Аларга да насыйп булсын күрү
Гүзәллекне елга буенда.

Урманы да калсын, даласы да,
Гөрләп агып ятсын елгалар.
Шунда гына ата-бабаларга
Багышланыр  изге догалар.

## Югалтулар

Югалтулар бар дип, хафаланма,
Югалтусыз булмас дөньялар.
Качып китеп тә һич котылмассың,
Кая барсаң, шунда ул да бар.

Нечкә билләр, кара бөдрә чәчләр
Тормыш юлларында  югала.
Кайнап торган хисләр сүлпәнәя,
Ялкын урынына көл кала.

Югалтулар арта бара-бара,
Еллар өстәп тора яңасын.
Чиксез авырлары кайчак бик күп,
Язмыш белми, ахры,  чамасын.

Сөйгән ярлар, дуслар юкка чыга,
Атласаң да тик бер бусага.
Тешләреңне кыс, түз, тик бирешмә,
Югалтулар авыр булса да.

Югалтулар бар, дип хафаланма,
Шулай бара гомер агышы.
Югалтулар белән бергә килә
Бу дөньяда булыр табышың.

## Тәлгәш-тәлгәш карлар

Тәлгәш-тәлгәш карлар тынсыз гына
Төшә,
Бар мохитне агарта.
Ятар өчен йомшак түшәк түши,
Тыныч йоклар ястык кабарта.

Ап-ак җәймә каплый, яшерәдер
Тирә-юньнең кара пычрагын.
Кире кайтарадыр бу галәмгә
Аның тапсыз-нисез, саф чагын.

Бер кечкенә орлык аста калган,
Селкенми дә, язны көтәдер.
Җылы гына килсен, торыр да ул,
Кыяк сузар, башын күтәрер.

Калын кар астында, караңгыда
Өмет саклый килер көннәргә.
Яз барыбер җитәр, кояш чыгар,
Тагын көч табылыр яшәргә.

Якты дөнья көтеп алыр аны,
Йомшак җилләр исәр иркәләп.
Кызу кояш аңа гайрәт бирер,
Алсу таңнар аткач, иртәләп.

Яшәү көчен сакла, ныгыта бел.
Җир йөзендә яшим мин, дисәң,
Биек көрт астында калганда да,
Үз юлыңа тугры бул икән.

Кем, я нәрсә булсын,  адәмме ул,
Үсемлекме, әллә милләтме,
Өмет югалтмыйча көч җыярга,
Көрәшергә, әлбәт, кирәктер.

Тәлгәш-тәлгәш карлар ява һаман
Бар мохитне шундук агарта...
Әллә кайчан сүнгән өмет утын
Җанландырып, учак   яңарта.

## Таулар белән әңгәмә

Горур зәңгәр таулар мине
Үзләренә чакыра.
Әйтерсең лә, барыр ара
Ерак түгел, чак кына.

Ялтыравык тау башлары
Очлы, ап- ак кар гына.
Ашыктыра,
Йөгереп түгел,
Очып- очып бар гына.

Бер елмаеп, бер турсаеп
Карый миңа  тауларым
Хәлләремне аңлагандай,
Белгән сыман уйларым.

Асыл ташлы чапаннарын
Өстенә кигән кебек.
«Без мәңгелек, сез вакытлы
Дөньяда»,- дигән кебек.

«Синең озын гомерең дә
Вакытлы гына, -диләр,-
Тау кечкенә сабый булган
Көн чаклы гына»,-диләр.

«Нигә тиңдәш түгелбез,-дип
Мин таулардан сорадым.-
Ник миңа да бирмиләр соң
Шундый яшәү срогын?»

Биек таулар тирә-юньне
Дер селкетеп көлделәр:
«Меңәр еллык озын гомер
Кирәкмени?»- диделәр.

«Әле шуның кыскасын да
Юньләп яши белмисең.
Кирәгендә туктамыйсың,
Дөрләп янып йөрисең.

Көнчелекнең чиге дә юк,
Ач күзле җан иясе.
Күбрәк ашыйсың да килә,
Затлырак та киясе.

Нәфесеңне тыялмыйсың,
Нәрсә күрсәң, шул кирәк.
Бар байлыкны бер үзеңә
Аласың килә күрәп.

Сугышасың, илләр яулап,
Сиңа тармы җир, кысык?
Яхшы эшкә өлгермисең,
Яшисең ашык-пошык.

Гамьсез сабый кебек боздың,
Ваттың дөньяда барын.
Синдә озын гомер булса,
Шартлатырсың җир шарын».

Шунда таулар тынып калды,
Ни әйтергә белмәдем.
Кеше- җирдә иң бөек җан,
Шул бит минем белгәнем.

Менә сиңа кирәк булса,
Төшемме бу, өнемме,
Таулар кеше күк сөйләшә-
Бу кыямәт көнеме?

Күзем ачсам, кояш балкый,
Хуш ис аңкый һавада.
Еракта мәһабәт таулар,
Челтер-челтер су ага.

Гүзәл табигать назында
Уйга калганмын икән.
Бигрәк татлы йокыларга
Шунда талганмын икән.

## Картлар һәм яшьләр

Уйлап-уйлап торам да мин
Хәзерге бу яшьләрне,
Шөбһә туа:
Алар җирдә
Безнең кебек эшләрме?

Яшь үзләре, тәҗрибә юк,
Күп нәрсәне белмиләр,
Ә шулай да тирә-якны
Үзгәртергә телиләр.

Бусы артка калган имеш,
Тегесе дә ошамый.
Үзләренчә иң алдынгы
Юл табарга чамалый.

Биюләре бию түгел,
Санаусыз, әллә ничә.
Боргаланып-сыргаланып
Сикерәләр төрлечә.

Көйләре дә чит, ят сыман,
Җырлары да бер моңсыз.
Кием-салымнар килешсез,
Әйтерсең, бер имансыз.

Үзем зарланып үземә
Шулай утырган чакта
Бер оныгым килеп керде,
Исәнләште кочаклап.

И мәһабәт егет инде,
Буе биек, киң күкрәк.
Үземнең яшь чагым сыман,
Оныгым тора күкрәп.

Төсе-башы, буе-сыны
Бигрәкләр дә килешле,
Сокланырлык,
Безнең  дәвер
Егетенә тиешле.

Тукта, мәйтәм, үз-үземә,
Яшьләрнең бар төрлесе,
Бездән бик ким дә түгелдер
Егет-кызның  күбесе.

Үзләренчә эшли икән
Теге йә бу нәрсәне,
Бу хәл хәзерге яшьләрне
Тирги торган нәрсәме?

Без дә элек тик гел генә
Әтиләрчә булмадык.
Башка төрле бию таптык,
Үзебезчә җырладык.

Ул гынамы, әтиләр дә
Бездәй яшьлек уздырган,
Яңа тормыш корабыз, дип,
Дөньясын пыр туздырган.

Борын заман әтиләргә
Сүз тидергән бабайлар,
Әллә кемгә охшыйлар, дип,
Безнең үскән малайлар.

Һәр заманның бию-җыры
Үзенә  хас ләбаса.
Бу яшьләр дә бозык түгел,
Ныклап уйлап карасаң.

Һәрбер буын шушы  җирдә
Калдыра үз эзләрен.
Бу яшьләр дә беләдер, дим,
Дөньясында нишләрен.

## **Көзләр килә**

*Рәшит Гатауллинга ияреп*

Көзләр көзгә охшап килми икән,
Берәүләре койган яңгырлы,
Ә башкасы тыныч кояш кына,
Сирәк алып килә яңгырны.

Кайсы көздә амбар тулган, муллык,
Канат үстерерлек куаныч.
Бәгъзе көзләр кытлык белән бергә,
Килер көнгә калмый ышаныч.

Бер көз алып килә очрашулар,
Кавышулар,
Шатлык тутыра;
Аерылышу сагышы кай көздә,
Җанда кара давыл котыра.

Быел әле, шөкер Тәгаләгә,
Каршыладык көзне бергә без.
Ерак булса булыр безнең ара,
Күңелләрдә гелән бергәбез.

Белмим, күпме көзләр бергә үтәр,
Берчак минсез килер көзегез.
Сезгә, бәлки, бераз кыен булыр,
Бераз авыр булыр, түзегез.

Өметем бар- бөтенләйгә китмәм,
Исегездән бик тиз югалмам.
Изге теләкләрем җибәрермен
Сезгә теге бакый дөньядан.

Кылган яхшы эшләр, якыннарым
Җирдә калса, мин дә яшәрмен.
Әйдә килсен инде килер көзләр,
Ходай биргән чаклы яшәдем.

## Көт әле

*И вакыт, көт әле.*
*Ф.Тютчев*

Вакыт чаба паратларда,
Туктап тормый бит әле.
Ялварсаң да, ишетми бит,
Вакыт, бераз көт әле!

Киткән кешенең өч көнлек
Кала, диләр, эшләре.
Бихисап бетмәгән эшләр,
Вакыт, мине көт әле.

Күпләр ярдәм кулын сузды,
Юлым булса киртәле.
Рәхмәт әйтми ничек китим?
Вакыт бераз көт әле.

Аңлашмаган ярлар калды,
Сүзләрем дә бетмәде.
Хисләремне җырым ачар,
Вакыт, азрак көт әле.

Дусларга да кайчагында
Вакытларым җитмәде.
Ашыктырма, бераз торыйк,
Яме, вакыт?
Көт әле.

Мин күрмәгән гүзәл җирләр
Уйласаң, бик күп әле.
Барысын күрәсем килә,
Вакыт, тукта, көт әле.

Яшәүләрдән туймадым шул,
Теге дөнья чит әле.
Яшим әле, эшлим, сөйим,
Вакыт, бераз көт әле!
Аз булса да, көтчәле...

## Елга

Тау башында таш астыннан
Чишмә чыккан, су ага.
Киртәләр күп бичарага,
Бер карасаң, югала.

Таулар, ташлар каршы  аңа.
Тырышып та, тырмашып,
Боргалана, сыргалана,
Үзенә бер юл ачып.

Кая  җитәре билгесез,
Ага- ага, көч  җыя.
Гөрли-гөрли шаулый башлый,
Аны хәзер кем тыя!

Киртәләрне кырып китә,
Зур ташларны актарып,
Чиксез дәртле ташкын була,
Гайрәт белән таш ярып.

Кыяларны кисеп үтә,
Үрдән түбән ташлана.
Кодрәтенә исең китәр,
Дәһшәтле бу шарлама.

Үзәнлеккә барып   җиткәч,
Сүлпәнәйтә агышын.
Кайчак тагын дулап китә,
Сабырлыкка  карышып.

Элеккедәй шаулап-гөрләп
Котырыр хәл юк хәзер.
Талгын елга ял итәргә
Туктар сыман нигәдер.

Берәр күлгә, я диңгезгә
Илтеп куша суларын.
Бормалы юллары гына
Җирдә кала нибары.

Адәм баласы да шулай
Хәлсез килә дөньяга.
Шаулап-гөрләп үтә яшьлек,
Охшап ташкын елгага.

Куәтле бер дәрья кебек
Үтә бара урта яшь.
Талгын гына үтә гомер,
Вакыт  җитеп, картайгач.

Судай ага, үтә гомер,
Үтә еллар үтәре.
Кеше китә, эзе булып
Җирдә кала эшләре.

## Бәхетле бул бүген

*Бәхетле бул син хәзер.*
*О. Хәйям*

Зарланма әле, зарланма,
Ай-һай кыен, дип, тормыш.
Гомер бит ул берәү генә,
Әйдә, бирешмә, тырыш.
Зарланудан  рәтләнми бит
Тормышың, күргән көнең.
Тырышлар кадаклый ташны,
Бәхетле бул син бүген.

Авырган чакларыңда да
Төшмәсен синең күңел.
Төшенке күңелләр белән
Яшәү бик җиңел түгел.
Һәр көнгә шатлана белсәң,
Күтәрелә ул күңел.
Күтәренке күңел белән
Бәхетле бул син бүген.

Кара болыт капласа да
Баш өстендә күкләрне,
Эшең белән якынайт син
Килер якты көннәрне.
Кояшның ал нурларына
Күмелер әле күгең.
Татар булсаң, башың имә,
Бәхетле бул син бүген.

Уфтанма да, алга атла,
Авыр булса да йөгең.
Һәркемнең дә үз йөге бар,
Бәхетле бул син бүген.
Бик кыен булса да сиңа,
Татар бирешмәс, диген.
Шушы көннең кадерен бел,
Бәхетле бул син бүген.

## Балакаем

*Улыма*

Еракларга киттең,
Ә мин
Әйтерсең лә, ялгыз каен.
Кайтмыйсың да, хәбәр дә юк,
Газиз балам, балакаем.

Дөнья мәшәкате сине
Басып киткәндер, мөгаен.
Минем өчен вакыт юктыр,
Газиз балам, балакаем.

Тәрәзәдән күзем алмыйм,
Көтәм сине һәр көн саен.
Бер күрергә зар-интизар,
Газиз балам, балакаем.

Уйларымда гел син генә,
Йөрәк парәм, йөрәк маем.
Өзелә сагынып үзәк,
Газиз балам, балакаем.

Рәхмәтеннән аермасын
Хак Тәгалә, бер Ходаем.
Сиңа шуны теләп калам,
Газиз балам, балакаем.

## Эзләр

Вакыт җиткәч, диләр,
Җирдән китми кемнәр.
Сүнә якты көннәр,
Үтә кара төннәр,
Калса, кала эзләр.

Әнкәм тойган хисләр,
Әткәм әйткән сүзләр,
Өзелеп сөйгән йөзләр,
Балкып торган күзләр-
Йөрәктәге эзләр.

Без сокланган гөлләр,
Аңкыган хуш исләр,
Гизгән күркәм җирләр,
Үрмәләгән үрләр-
Саклар микән эзләр?

Күккә, суга күпләр
Өмет баглый бикәр.
Өзелгәндәй җепләр,
Суда, күктә, диләр,
Калмый икән эзләр.

Үткәч язлар, җәйләр,
Килеп җитәр көзләр.
Улап ачы җилләр,
Тигезләнер эзләр,
Көчсез, ирексезләр.

Табылмаса эзләр,
Килер буын нишләр?
Гүя нәселсезләр,
Кайдан нәселең эзләр,
Югалса бар эзләр?

Калсын иде уйлар
Бездән,
Кызлар, уллар,
Салган  туры юллар,
Бәгъзе изге эшләр,
Ташка баскан сүзләр-
Җуелмаслык эзләр.

## Нилəр булыр мин киткəч

Мин киткəч тə, дəрьяларда ашкынган су
Ургылыр да, гөрли-гөрли  агар микəн;
Диңгезлəр дə гөрселдəгəн ап-ак башлы
Дулкыннарын шашып ярга кагар микəн?

Минем кебек берəр кеше ярга басып,
Суга карап моңланыр да, җырлар микəн;
Тау башында киң дөньяга сокланыр да,
Бетми торган бар уйларын уйлар микəн?

Мин киткəч тə, ялкыннарын яратам, дип,
Тиккə генə берəү  учак ягар микəн;
Дөрли-дөрли уйнар микəн утлы учак,
Очкыннарын күккə чөеп янар микəн?

Учактагы көлдə пешкəн бəрəңгене
Миндəй ләззəт белəн берəү ашар микəн;
Фани дөньяның шул бөтен гүзəллеген,
Бөтен күркен күңелендə саклар микəн?

Сыерчыклы язлар, хуш ис гөлле җəйлəр
Элеккечə вакытында җитəр микəн;
Мул уңышлы көзлəр, чиста карлы кышлар
Бар якларын күрсəтмичə, китəр микəн?

Соңыннан да якты кояш балкыр микəн,
Нурлар сибеп күктə көлеп торыр микəн;
Көндəй булсын караңгы төн, дигəн сыман
Нурлы ай да үз эшендə булыр микəн?

Мин киткəч тə, бөтенесе, əлбəт, булыр,
Кояш һəм ай күктə; язы,  җəе, көзе,
Кыш та килер.
Тик мин генə булмам инде,
Калса, калыр җирдə салган кайбер эзем.

Халкым яшәр, нәселем дә калыр җирдә.
Сүзләремне берсе укыр, белер шунда.
Үз йомгагын сүткән чакта:
Ай-һай гомер, бигрәк кыска,-
Дигән уйга килер ул да.

## Һәйкәл

Мин  үземә һәйкәл куялмадым,
Ахры, куяр юлын тапмадым.
Әлегәчә һаман җыялмадым
Һәйкәл өчен кирәк ташларын.

Үзләренә мәгърур һәйкәл куйган
Тукайлар бар, тагын бүтәннәр.
Бүген җирдә яшәүчеләр дә бар,
Бар күптән үк  моннан киткәннәр.

Һәйкәлләргә лаек эзләр салу
Һәркемгә дә бирелмидер ул.
Зәңгәр күккә, чиксез биеклеккә
Бар кеше дә үрелмидер шул.

Һәйкәлем юк, диеп кайгырмыйм мин
Менә бүген, гомерем көзендә.
Бер Ходайга шөкер, балаларым,
Оныкларым бар җир йөзендә.

Калыр әле китапларым  монда,
Күпме кала кылган эшләрем.
Үзем өчен генә түгел,
Милләт,
Халкым өчен дә бит эшләдем.

Мин үземә һәйкәл куялмадым,
Ә шулай да калыр эзләрем.
Булыр әле искә алучылар
Мине дә һәм язган сүзләрем.

## Аксак чебеш

Тавык чебиләре арасында
Бар иде бер зәгыйфь, аксагы.
Башкалардай йөгерәлми иде,
Артта кала,
Шуңа ач тагы.

Җәберсетә апа-агалары,
Эне-сеңелләре чукыйдыр.
Бу бичара якты көн күрәлми,
Белмим, ничек кенә чыдыйдыр.

Озак яшәмәде мескен чебеш,
Хуҗабика ярдәм кылса да...
Җир йөзендә яшәп буламыни,
Көне - төне чукып торсалар!

Бу дөньяда аксак чебеш булма,
Кешеме син,
Яки милләтме.
Зур кикрикле әтәч булып яшә,
Танысыннар синең кодрәтне.

Юк, юк,
Әтәч булгач, гел масаеп,
Тирә-якка һәрчак лаф орма.
Ләкин синең әтәч икәнлекне,
Сине чукырга юл куймасыңны
Күршеләрең белеп торсыннар.

## Үлән

Таш астыннан  үсеп чыккан үлән.
Әйтерсең лә, аңа хас  ул гелән
Ташны яру тик үз көче белән.
Шул үләндә  яшәү көчен күрәм.

Газиз  оныкларым, балаларым
Белсен кешедә дә зур көч барын.
Кирәк булса, шулай ташны ярып,
Яшәсеннәр һаман  алга барып.

## Килер буыннар

*Безгәчә дә килеп киткәннәр,*
*Бездән соң да килер дәверләр.*
*Х.Туфан*

Бездән алдарак та күпләр килгән,
Бездән соң да күпләр килерләр.
Безгә тоелгандай, аларга да
Кыска сыман булыр гомерләр,
Бер мизгелдәй булыр гомерләр.

Килгән буыннарның гомере дә
Безнекечә булыр, мөгаен.
Бездәй югарыга омтылырлар,
Зур өметләр белән көн саен.

Яшьлекләре яшьнәр аларның да,
Сөю утларында янарлар.
Ике йөрәк берчак  кавышыр да,
Уртак учакка ут  ягарлар.

Җирдә яшәвеннән ләззәт табып,
Җиң сызганып эшләп кинәнер.
Тик эшләре безнекеннән бераз
Җиңел булыр сыман нигәдер.

Безнең кебек бала үстерерләр,
Бала уңышына шатланып.
Оныклары белән масаерлар,
Бик акыллы, диеп, мактанып.

Еллар үткәч, чәчләр ап-ак булыр,
Җыерчыклар басар йөзләрен.
Картаерлар.
Ләкин бездәй саклар
Күңелендә яшьлек хисләрен.

Вакытлары җиткәч, тәңгәлләшер
Яшәү башы белән азагы.
Шул божраны бер әйләнеп чыгу-
Гомер ләззәте дә, газабы.

Башка яңа буын алмаш килер,
Аңа да тик бер юл, билгеле.
Ул да кабат безнең юлны үтәр,
Яшәр, янар безнең шикелле.

Буын арты буын алмашына,
Яңа буын- яңа карашлар.
Үзгәртәбез бар дөньяны,  диеп,
Юлга чыга, җигеп паратлар.

Алга бара, артка чигенәдер,
Уңга китә, сулга сугыла.
Кайчак кырып- җимереп тә үтә,
Һәр буынга  морад табыла.

Үзенчә һәр буын борын чөя,
Менә без, дип, җиһан хуҗасы,
Иң югары форма.
Тик үзгәрми
Шул түгәрәк гомер божрасы.

Баксаң, бу дөньяда элеккечә
Үтә икән һәрчак гомерләр.
Кешегә тик бер күз ачып йому-
Бу дөньяга килеп китүләр.

Безгә кадәр күпме килеп, киткән,
Бездән соң да
Бик күп булыр китү, килүләр.
Тик бәхетле генә булсын иде
Кеше җирдә яшәр мизгелләр.

## Балама нәсыйхәт

Гомереңнең зур юлына чыктың,
Хызыр Ильяс булсын юлдашың.
Тормыш киртәләрен араларга
Үз акылың җитсен, үз башың.

Күзең карасыдай саклап йөре
Намусыңны, керсез атыңны.
Искә ал син изге дога белән
Ата-бабаң, анаң-атаңны.

Синнән иман-кот качмасын бер дә,
Шәфкатьле бул, аның чиге юк.
Башкалардан йөз чөерә күрмә,
Акыл тирән, аның төбе юк.

Син онытма:
Җылы, иркә сүзләр
Каты бәгырьне дә эретә.
Яхшылыкка рәхмәтле бул,
Ходай
Шөкерана сүзен ишетә.

Юк-бар өчен дә син оран салма,
Әрәм-шәрәм итмә елларны
(Елын түгел, үткән бер көнен дә
Кире кайтарырлык юл бармы?).

Син дә бу җиһанда вакытлысың,
Чүп калдырма йөргән юлларда.
Дөньяның бар гүзәллеген калдыр
Килер буын кызлар, улларга.

Җырлап туймас җырдай гомер телим,
Туганнарың сиңа сыенсын.
Хызыр Ильяс изге юлдаш булсын,
Яшәү назы күпкә сузылсын.

## Васыять

*Тимурга, Артурга, Релиягә*

Әткәемнең миңа васыяте:
Намус белән дөнья көтәргә,
Тормыш  юлын үз хезмәтең белән,
Кеше рәнҗетмичә үтәргә;

Көнчеллеккә юл куймаска кирәк,
Кул сузмаска кеше малына.
Әткәемнең шушы васыятен
Мин сеңдердем үзем аңыма.

Еллар үтте, истә юк күп нәрсә,
Кайбер таныш-белеш онытылды.
Ләкин менә шул васыятьне мин
Истән чыгармаска омтылдым.

Нинди генә эшне башласам да,
Кабул итсәм нинди карарны,
Иң беренче шуны тикшердем мин:
Әткәм сүзенә бу ярармы?

Газиз балаларым көтәр булса
Бер васыять миннән, атадан,
Әткәемнең  изге шул сүзләрен
Кабатлармын мин дә яңадан.

## Оныкларым

Оныкларым минем, оныкларым,
Бәгырьләрем, кызым-улларым.
Сезгә кала бөтен якты дөнья,
Үзем салган сукмак, юлларым.

Калдырам мин үскән агачларым,
Җирдә эзем- бөтен хезмәтем,
Кер төшмәгән исем,
Кешеләрнең
Ихтирамы белән хөрмәтен.

Сезгә кала яшәлмәгән еллар,
Татылмаган күпме хисләрем,
Әле ахырына җиткермәгән,
Бетермәгән күпме эшләрем.

Кала бөтен өмет-хыялларым,
Йөрәк түрендәге моңнарым,
Әйтелмәгән күпме назлы сүзләр,
Җырланмаган күпме җырларым.

Шушы йөкләр хәзер сезгә кала,
Инде сез тартырсыз җигелеп.
Ата-аналарга терәк булып,
Хөрмәт күрсәтеп һәм игелек.

Теләкләрем кала,
Булсын, диеп,
Оныкларым минем бәхетле.
Бирсен Ходай минем өлешне дә-
Биреп бетермәгән бәхетне.

## **Утрау түгел син**

*Оныкларыма*

Океанда утрау түгел бит син,
Тирә-юньдә һәрчак кеше бар.
Адәм балалары кая барса,
Шунда үзенең бер ише бар.

Ялгыз түгелсең син,
Кыен чакта
Ярдәм кулын сузар күршеләр.
Кайгы- хәсрәтеңне бүлешерләр
Туганнарың, якын кешеләр.

Синең куанычны уртаклашыр,
Шатлыгыңа шатлык өстәлер
Туры юлда йөрсәң,
Боргаламый
Адым саен арбаң күчәрен.

Башкаларга ачык йөзле булсаң,
Уңышларга уңыш кушылыр,
Күз алдыңда бәхет нуры уйнар,
Очраган бер кеше дус булыр.

Океанда ялгыз утрау түгел,
Игьтибар ит һәрбер эшеңә.
Ялгыш берәр киртә кормадыңмы
Эшең  белән бүтән кешегә ?

Кеше арасында гомер сөргәч,
Уйлап сөйлә бөтен сүзеңне.
Авызыңнан үлчәп кенә чыгар,
Кеше рәнҗетерлек түгелме?

Көч һәм вакытыңны аямыйча,
Кешеләргә күрсәт игелек.
Онытылмас шундый яхшылыгың,
Җирдә ятмас кылган изгелек.

Чиксез океанда ялгыз утрау,
Диеп хис итмә син үзеңне.
Бер син генә түгел бу дөньяда,
Тыйнак, сабыр да бул, түземле.
Менә шунда халкың искә алыр,
Мактап сөйләр синең сүзеңне.

## Онытым белән әңгәмә

Килче миңа, бик сагындым сине,
Кил алдыма, назлыйм үзеңне.
Матур ачылып та килә телең,
Бик сокланып тыңлыйм сүзеңне.

Тукта әле, нигә инде алай
Бабаеңа русча сөйлисең?
Татарчалап сөйләш,
Татар бит син,
Бәй, татарча әллә белмисең?

Әттәң өйрәтмәдемени сине
Моңлы, гүзәл татар теленә?
Әннәң дә шул,
Сиңа бишек җырын
Башка телдә көйли күренә.

Эх, алар бит үзләре дә белми
Туган телне, татар булса да.
Бик татарча сөйләшерләр иде,
Кечкенәдән аңлар булсалар.

Әйе, шулай.
Мин бит өйрәтмәдем
Татарчага синең әттәңне.
Ул кечкенә чакта гел хупладым
Рус телендә генә әйткәнне.

Шушы хатам бүген сиңа җиткән:
Син дә- телсез татар баласы.
Болай барсак,
Синең токымың да
Үзең сыман телсез буласы.

Туган тел алдында без гаепле,
Без үзебез аны кимсеттек.
Башка телне генә бөек, дидек,
Туган татар телен чит иттек.

Безнең хаталарны кабатлама,
Татар телен өйрән, кечкенәм.
Тик туган тел белән генә сиңа
Үз халкыңнан гайрәт, көч килә.

Үз телеңдә,  татар җырын җырла,
Морадыңа  шул тел ашырсын.
Ерак киләчәктә нәниләрнең
Нәкь татарча теле ачылсын!

## **Кечкенә онытыма**

*Тимерәйгә*

Урам яктан: «Калт-әт-ә-әй»,
Дигән тавыш ишетелде.
Баксам, ул оныгым икән,
Кечкенә шул,
Сакау телле.

Шулай булса да, әйтә бит
Сүзнең гаять бер татлысын.
Җан җылысы, балкып тора,
Аны ничек яратмыйсың!

Куанычы - эчкә сыймас,
Авызы колакка җиткән.
Куллар сузып,
Миңа табан
Йөгерә ул алпан-тилпән.

Мин дә йөгерәм,
Күтәреп,
Кысам аны күкрәгемә.
Йә Ходаем,
Мондый ләззәт
Буладыр ул күктә генә.

И оныгым, син дә берчак
Олы яшькә ирешерсең.
Менә шундый зур бәхетне
Аллам үзеңә дә бирсен!

Сиңа да бер җан йолдызы
Булсын газиз оныкларың.
Минем изге теләкләрем
Тапшыр син аларга барын.
Бәхетле булып үс, җаным!

**Нəниемə**

*Нилүфəргə*

Әттəң дə ярата сине,
Бик ярата əниең.
Килче монда,
Мин дə сине
Яратам бит, нəнием.

Син үзең нəни булсаң да,
Энекəшеңə апа.
Әнə күрəсеңме,
Тешсез
Авызын ерып ята.

Бабаң янында калырга
Телисең дə, нəнием,
Сезнең белəн бала багып
Яшəми шул əбиең.

Әттəң囊 эштə, əнкəеңə
Кыен булыр берьялгыз.
Энекəшеңне карарга
Булдыралмас бер ялсыз.

Син бит өйдə иң олысы,
Тик бердəнбер кыз бала.
Әгəр син ярдəм итмəсəң,
Өйдə бик күп эш кала.

Эшкə өйрəнеп үсəрсең,
Бəхетең булыр алда;
Булдыклы һəм чибəр кызга
Бар да сокланыр шунда.

Ике яшь кенә булса да,
Син инде апа кеше.
Өеңә кайт инде, яме?
Өй тулы ята эшең.

Эшең беткәч, килерсең.
Мин көтәрмен, күрерсең.

## **Елмай, елмай**

*Рәмилгә*

Тәпи йөрми әле малай,
Хәтта мүкәләми дә.
Бер сүзгә дә каршы килми,
Дәшми, үпкәләми дә.

Нәрсә бирсәң, шуңа риза,
Елавы да еш түгел.
Кәеф якларына килсәк,
Гел күтәренке күңел.

Тешсез авызларын ерып,
Һәркемгә дә елмая.
Күзләр ялт-йолт итеп тора,
Күңелләре саф гаять.

Берчак йөри дә башларсың,
Телләрең дә ачылыр.
Әттә-әннә, абый-апа-
Барысы да шат булыр.

Шат күңелең югалмасын,
Елмаюны ташлама.
Елмая белгән кешеләр
Бик күп эшләр башкара.

Бер эштән дә курыкмасаң,
Җитәрсең максатыңа;
Киртәләрне дә үтәрсең
Зыянсыз, ансат кына.

Бер бик асыл егет булып
Үсәрсең, тешсез малай.
Җирдә яшәү мавыктыргыч,
Бәхетле бул, гел елмай.
Елмай, тагын да елмай!

## **Сурәтең алдында**

*Әмиргә*

Хатка салып, фотосурәтеңне
Җибәргәннәр.
Алдым кулыма.
Сурәт карап утырдым бик озак,
Уйга чумып, каткан сын сыман.

Ни тәкъдирләр белән килдең икән
Син, кадерлем, фани дөньяга,
Тылсымлы көч алып килдең микән
Моңарчы бу җирдә булмаган?

Искитәрлек акыл иясеме,
Хикмәт иясеме язмышың,
Тирән уй беләнме, моң беләнме
Җир йөзендә булыр балкышың?

Сабырлыкмы, дөрләп янулармы-
Нинди икән синең киләчәк?
Белмим инде.
Йөрер юлларыңа
Үзем сибәр идем гөлчәчәк.

Хәтерләтсен иде гүзәл гөлләр
Синнән алда киткән җаннарны.
Ата-бабаң рухын юлдаш итсәң,
Сине җиңәрлек көч чыгармы ?!

Минем нәселемнең дәвамы син,
Баглыйм сиңа бик зур өметләр.
Тырыш, тырмаш, югарыга омтыл,
Шулчак табыла ул бәхетләр.

Җибәргәннәр фотосурәтеңне,
Бик яраттым сине, җан гынам.
Акыл, намус, бәхет, туганчыллык
Бирер сиңа Ходай.
Ышанам!

## Онытыма хат

*Рамзатка*

И онытым, кечкенәм,
Алтыным, көмеш кенәм.
Күзләр кара карлыган,
Йөзләрең нурга чумган.

Куанып торам алдан,
Сиңа бәхет юралган:
Изге айдан бит синең
Алган матур исемең.

Рамазан җиткән саен
Гел килә туган аең.
Синең, минем туган көн-
Икебезгә уртак көн.

Миңа күп яшәр еллар,
Бәхетле үтәр юллар
Җәлләми бирде Ходай.
Сиңа да бирсен шулай.

Кадерле дә, бердәнбер
Әткәң белән әнкәңдер.
Нәкъ шуларга иң элек
Синнән булсын игелек.

Апа-абыйларыңа
Ярдәмчел бул барына.
Туганнарыңа-терәк,
Кешеләргә бул кирәк.

Кешелекле-гуманлы,
Намуслы бул, иманлы.
Исәннең бел кадерен,
Үлгәннәрнең-каберен.

Ата-бабаларыңнан
Мирас булган саф ат-нам
Үсәр тырышсаң гына,
Инсафлы булсаң гына.

Һичбер эштән баш тартма,
Ялкаулар кала артта.
Югарыга үрмәлә,
Менәрсең үрләргә дә.

Картәтәңнән нәсыйхәт-
Сабый чагыңнан бу хат.
Васыять, дип, күз алмам,
Укырсың, яме, балам.

## Юлың туры булсын

*Русланга*

И кечкенә оныгым, син мине
Күргәнең юк әле, белмисең.
Җирдә менә шундый хәл дә була,
Дөнья бит ул, дөнья, нишлисең.

Атаң-анаңа син рәнҗи күрмә,
Тулы гаиләләр күргәндә.
Гомер- иң зур байлык,
Аларга син
Рәхмәтле бул гомер биргәнгә.

Син бер ятим түгел шушы җирдә,
Туганнар бар, апа-абыйлар.
Тотрыклы тор басып,
Җебек булма,
Читләр сине тизрәк танырлар.

Һәркемнең үз өлеше бар җирдә,
Һәркемгә дә кояш нуры бар.
Үз язмышы, үз гомере була,
Һәркемнең дә үзгә юлы бар.

Барыр юлын кеше үзе сайлый,
Үз кулында ничек яшәү дә:
Гомер буе пыскып яту булсын,
Дөрләп яну, гөрләп яшьнәү дә.

Вакыт житкәч,
Син дә бер сайларсың
Гомереңдә барыр юлларың.
Һич онытма:
Җитәр максатыңа
Бара торган туры юл барын.

Мин ышанам, туры юлдан йөреп,
Зур бәхетләр җирдә табарсың;
Тырышлыгың, эшчәнлегең белән
Хәтта ташка кадак кагарсың.

## Атлар кешни

Эңгер - меңгер куелана инде,
Җиргә тыныч кына төн килә.
Тавыш-тынсыз кала мизгел, тына,
Ә бераздан  акрын, тыйнак кына
Атлар кешнәгәне ишетелә.

Атлар кешни төндә, атлар кешни,
Ни дип кешни икән бу атлар?
Акбүзе дә, туры бурлысы да,
Кара кашка, ала- коласы да,
Җирән, сорылары һәм чаптар.

Кешнәп- кешнәп әллә сагынамы
Һич ваемсыз колын чакларын;
Күктән кояш иркә нурлар коеп,
Тояк йомшак чирәм назын тоеп,
Киң болында ыргып чапканын?

Һаман хәтерләрдә саклыйлармы
Челтер-челтер сулар акканын;
Анасының татлы сөте тәмен,
Куакларның яшь яфраклы ямен,
Уйнап, юри шунда качканын?

Кешни-кешни искә төшерәме
Тай чактагы шаулы язларын?
Менә кошлар җылы яктан кайта,
Кар сулары гөрләп агып ята,
Умырзая чыга кар ярып.

Ә эшләгән еллар, тирләр түгеп,
Азмыни соң искә алырлык?
Анда байтак авыр хәлләре дә,
Шатлык-куанычлы мәлләре дә
Гомерлеккә истә калырлык.

Барысын үзара сөйләшәләр.
Тик берәве китсә арттырып,
Бик тиз генә шундук беленә ул,
Төн булса да, ачык күренә  ул.
Булмас, диләр атлар, пошкырып.

Төннәр буе серләшәләр атлар,
Кешнәп берсен - берсе аңлаша.
Тик аларга килеп кушылалмый,
Ялгыз мескен, уртак тел табалмый
Көтүен югалткан алаша.

Ә колыннар, тайлар, яшь- җилкенчәк
Тыңларга бик тормый атлыгып.
Ник тыңласын әллә кайчангыны,
Таза, көчле.
Әллә корчаңгымы,
Алда күпме яшәү шатлыгы!

Бездә кайгы - хәсрәт булмас, диләр,
Без бит яңа буын атлары!
Гомер уен - көлке белән үтәр,
Авырлыклар безне читләп китәр,
Ишетелмәс камчы шартлавы.

Ә олырак атлар һаман кешни.
Алар белә гомер юлының
Гел бик тигез генә булмавын да,
Юлында күп киртә торганында
Җан иясе- Алла  колының.

## Сүзләрем сиңа кала

Энҗе бөртекләрен җыйган сыман
Каушый-каушый эзлим кирәген.
Йөрәгемнән чыккан сүзләремне
Язып калдырырга теләгем.

Сүзләр төрле-төрле,
Кайберсендә
Мөлдерәмә тулы күз яше,
Кайгы-хәсрәтләрем, сагышларым,
Җыр, моңнарым –йөрәк сердәшем.

Җан ачысы кергән сүзләр дә бар,
Дин акылы кайбер сүзләрдә,
Бара ата-бабабыздан калган
Тарихтагы изге эзләргә.

Кайбер сүзләр шатлык-куанычлы,
Шуңа үрле-кырлы сикерә.
Кайберәве гүзәл мәхәббәтле,
Шул хисләрдән үзе исерә.

Сүзләрнең бар көлке-шаяннары,
Шаркылдашып көлеп торганы.
Сүздә дусларым бар, уйларым бар,
Дөнья, диңгез, дала, урманым.

Барлык сүзем миннән сиңа кала,
Охшадисә, укып карарсың.
Бәлки , әле искә төшерерсең
Шуны язган татар баласын.

## ӘЙДӘ, ДУСТЫМ, ҖЫРЛАП ҖИБӘР

**И Тукай**

Килгән булса да җиһанга
Бәхет өчен ир бала,
Язмыш аны читкә кагып
Михнәт утына сала.
И Тукай, моңлы Тукай,
Кайгылы, зарлы Тукай.

Чыдам була, тырыш була,
Үсеп җитә бу егет,
Идел суы, Урал суы
Бергә көч биргән кебек.
И Тукай, нурлы Тукай,
Югалмас җырлы Тукай.

Якты дөнья читлеге тар
Ятим үскән шагыйрьгә.
Сазы сынды, үзе сүнде,
Сагыш салып бәгырьгә.
И Тукай, нәүмиз Тукай,
Халкыңа газиз Тукай.

Күктән йолдыз атылгандай
Ялтырап очты Тукай.
Ядкарь итеп Тукай моңын
Җырлый һавада тургай.
И Тукай, бөек Тукай,
Син исән кебек Тукай!

## Эй, татарлар

Чал тарихта лаек урынлы,
Җирдә эз калдырган халык без.
Тырыш татар, эшчән, булдыклы,
Күп калалар салган халык без.
Бөек татар батыр уллары,
Улларга тиң җитез кызлары.
Изге матур ана телебез,
Җан җылысы татар җырлары.
Кушымта:
Э-э-һей,татарлар,
Э-э-һей,татарлар,
Яшен булып яшьнәр халык без,
Җирдә мәңге яшәр халык без.

Зур дәүләтләр корган халык без,
Җир тетрәткән батыр, алып без.
Туган илгә яулар килгәндә
Җан аямый торган халык без.
Авырлыкка безләр бирешмәс,
Морадына дошман ирешмәс.
Киртәләрне ерып чыгарбыз,
Горур татар халкы баш имәс.
Кушымта.

Гомер буе гыйлем эстәгән,
Китаплы да, фәнле халык без.
Төркиләрне бергә туплаган
Илле, җирле, динле халык без.
Ялкыннардан имин чыгабыз,
Ут эчендә янмас халык без.
Дәрья, диңгезләрне кичәбез,
Суларында батмас халык без.
Кушымта.

**Әй Казан**

Кайда гына яшәсә дә,
Казандыр башкаласы.
Чын күңел белән сыена
Шуңа татар баласы.
Әй Казан!
Син гүзәл, Казан.
Әй Казан, нурлы Казан.
Мәчетләре манаралы,
Яңгырый моңлы азан.

Бабаларым яклап сине,
Җаннарын фида кылган.
Аларның эзләре гүя
Урамнарыңда калган.
Әй Казан!
Син батыр, Казан.
Әй Казан, чыдам Казан.
Ата-бабалар мирасы
Туган халкыма язган.

Җирдә Казан гөрләп торса,
Татарлар ятим түгел.
Әй Казан- мөкатдәс кала,
Сиңа тартыла күңел.
Әй Казан!
Син яшә, Казан.
Әй Казан, данлы Казан.
Ачык йөзле дә шәфкатьле,
Баллы да татлы Казан.
Әй Казан!

## Казан каласы

Мең ел буе яши Казаным,
Яшәсен ул тагын, яшәсен!
Картаймасын Казан мәңгегә,
Яшәрсен ул һаман, яшәрсен.
    Кушымта:
    Казан дигән таш кала,
    Татар өчен баш кала,
    Җанга якын шат кала,
    Алыштырмам башкага.

Булак буе, Кабан күлләре,
Мәһабәт Кол Шәриф мәчете,
Тукай  илһам тапкан җир,
Башын имәс Җәлил бәхете.
    Кушымта.

Күтәрел син тагын югары,
Бөтен татар сиңа табына.
Казан диеп, татар җанлана,
Җиңелмәстәй көчләр табыла.
    Кушымта.

## Без кайтырбыз әле

Ерак читләрдә торсак да,
Үз илебездә булсак да,
Бер үк төстә безнең ал каннар.
Туган илкәй сагындыра,
Һаман шунда ашкындыра,
Без кайтырбыз әле, туганнар.

Илне ташлап киттегез, дип,
Безгә үпкәләмәсен тик
Туган җирдә дөнья корганнар.
Сыяр әле барысы да
Газиз туган оясына,
Без кайтырбыз әле, туганнар.

Чит илләрдә солтанмы ул,
Үз илендә олтанмы ул,
Барыбер бит татар булганнар.
Изге Ватан үз улларын,
Хәзер чакыра кызларын,
Без кайтырбыз әле, туганнар.

Матур язлар килгән чакта
Юл салырлар туган якка
Чит илләрдә яши торганнар.
Бергә-бергә татар халкы
Бердәм көн күрергә хаклы,
Без кайтырбыз әле, туганнар.

Туган-үскән илләремә
Кайтып керер көннәремдә
Кояш нурлары кул сузарлар.
Урман, болыннар  һәм кырлар
Очрашуның җырын җырлар,
Без кайтырбыз әле, туганнар.

## Кайтам әле илләремә

Кайтам әле илләремә,
Илкәем гүзәл минем.
Бер җирдә дә табалмадым
Туган илемә тиңен.
Кайтам инде  илкәемә,
Агыйдел буйларына.
Бетәр сагыш, бер юынсам
Агыйдел суларында.

Кайтам әле илләремә,
Сагындым илләремне,
Илләремне генә түгел,
Сагындым чибәремне.
Кайтам инде  илкәемә,
Сөйгән ярым көтәдер.
Минем парым кайтыр әле,
Диеп өмет итәдер.

Кайтам әле илләремә,
Мин шул якның баласы.
Анда урманы да үзгә,
Үзгә сахра, даласы.
Кайтам инде илкәемә,
Туган-үскән ягыма.
Илемне дә, ярымны да
Өзелеп-өзелеп сагынам.

## Сагынам язларымны

Каңгылдашып оча, тезелешеп,
Карап калдым киек казларга.
Еракларга киткән казлар кебек
Очып китте безнең язлар да.
Язда гөлләр дулап чәчәк ата,
Исертерлек иде исләре.
Агым суның ташкыннары кебек
Ярсу иде йөрәк хисләре.

Гомер язларында гүзәл гөлләр,
Алсу чәчәкләргә тиң идек.
Ашкындырып көткән юллары да,
Якты дөньялар да киң иде.
Никтер язлар кыска гомерле шул,
Чәчәкләр дә бик тиз коела.
Истә кала үзәк өзгеч моңы,
Сагышлардан күңел боега.

Язгы кояш нуры яшьлегемдә,
Җилкендереп торды юллары.
Йөрәк янулары, омтылышлар
Тик хәтердә калды нибары.
Тезелешеп оча еракларга,
Бүген озаттым кыр казларын.
Алар кайтыр әле исән булса,
Мин сагынам кайтмас язларым.
Кайтмас инде яшьлек язларым.

## Кайтчы, яшьлегем

*Кунакка булса да кайт, яшьлегем.*
*Абу-ль Атахия*

Сагынып көтәм язларның
Үтә ачык яшелен.
Язлар, җәйләр кире кайта,
Никтер кайтмый яшьлегем.

И яшьлегем- бакчадагы
Ал чәчәкле  мәк гөлем.
Кадереңне белер идем,
Әгәр кайтсаң, яшьлегем.

Ел артыннан еллар уза,
Инде байтак яшьлемен.
Сине бигрәк сагынам бит,
Кайтырсыңмы, яшьлегем?

Чигәләргә бәс төшсә дә,
Күңелемдә яшь көнем.
Кунакка гына булса да,
Кайтчы, кайтчы, яшьлегем!

## Сылуым

Карлыгач канаты кебек
Ике кашың, гүзәлем.
Бер-беренә тияр-тимәс
Иреннәрең - ал гөлем.
Әй сылуым, энҗе тешләр
Үзең тезгән идеңме,
Чык суында юды микән
Әнкәң синең йөзеңне?

Кояш нуры сыман балкып,
Килеп кергән чакларың
Йөрәгемне сузар идем,
Төп-тамырын актарып.
Сине күрсәм, телсез калам,
Синсез юк яшәр хәлем.
Хыялыйлар булам инде,
Табалмыйм тормыш ямен.

Күзләреңдә сихерле көч,
Ут чаткысы сибелә.
Буең зифа, билең нечкә,
Үзәкләрем өзелә.
Толым-толым чәчләреңне
Ни май сибеп үстердең?
Йөрәгемдә сүнмәс утлар,
Нигә сине соң күрдем?

## Китәм инде

Китәм инде, җаным, сиңа
Саубуллашу сүзләрем.
Үзем белән алып китәм
Кайнар сөю хисләрен.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Үзем белән алып китәм
Йөрәгемнең ярасын.

Китәм инде, аерылышу
Үзәк өзәрлек икән.
Сагыну, сагышларыма
Ничек түзәрмен икән?

Китәм инде, хуш, бәгырем,
Китәр вакытлар җитә.
Бер дә аерылмас идем,
Язмышлар алып китә.

## Иртыш моңнары

Гүзәл Иртыш буйларында
Туды минем җырларым.
Дулкын шаулавына куштым,
Моңланып бер җырладым.
Кушымта:
Сихри моң тулы
Иртыш таңнары.
Мәңге күңелдә
Иртыш моңнары.

Дулкыннар үз көен көйли
Сайрар кош белән бергә.
Иртыш ярларга сырыла
Эз салыр өчен җиргә.
Кушымта.

Иртыш -дәрья уртасында
Утравы әрәмәле.
Таралсын бар сагышларым,
Утрауга барам әле.
Кушымта.

Ага дәрья, ага дәрья,
Дәрья өстендә томан.
Иртышымның томаны да
Мине иркәли сыман.
Кушымта.

**Бәгырем**

Бәгырем дияр идем,
Өзелеп сөяр идем.
Әгәр булсаң яннарымда,
Төнне көн дияр идем.

Аерылышу газабы
Җиңел түгел, бәгырем.
Бергә булган минутларның
Ник белмәдек кадерен?

Сагынамын, саргаямын
Без аерым булганга.
Бәгырем диеп җырлыйм мин
Күңелләрем тулганда.

Кавышу көннәре килер,
Аерылмыйк өметтән.
Ашкынып көтәм, бәгырем,
Син дә шуңа өметлән.

## Насыйп булмаган

Серләремне сиңа сөйләр идем,
Син генә бит аны аңлаган.
Күгәрчендәй икәү гөрләшергә,
Серләшергә безгә язмаган.

Хыялымда сине кочагыма
Шашып кысам яңа-яңадан.
Кавышулар бары хыял гына,
Асыл ярым миңа язмаган.

Төшләремдә күрдем ике аккош,
Ялгыш булды төшне юраган.
Пар аккошлар кебек канат кагып,
Бергә очу насыйп булмаган.

## Сагынам сине

Язмыш безне мәңге аерым итте,
Мин боегып берьялгызым калдым.
Айлар үтте, синсез еллар үтә,
Тик басылмый хәсрәт-кайгым.
Аерылып ялгыз калдым,
Үзәк өзгеч сагыш-кайгым.

Бергә үткән көннәр искә төшә,
Күзләремә кайнар яшьләр тула.
Кая барсам, шунда син елмаеп
Карап торгандай тоела.
Син торган күк күз алдымда,
Юксынам ла, сагынам ла.

Сагышларым ташып чыккан чакта
Кулларыма алам сурәтеңне.
Нишләргә соң, ничек онытыйм сине?
Сурәтең дә әйтмәс инде.
Оныталмыйм, нишлим инде,
Өзелеп сагынам, сагынам сине.
Сагынам сине.

## Әнкәем

Сабый чакларымда әнкәй сөя-сөя
Кулларына мине ала иде.
Назлаганда кысып кайнар кочагына,
Җаннарыма рәхәт була иде.
Назлаганда кысып кайнар кочагына,
Балам, җаным, бәхетле бул, дия иде.

Дөнья диңгезләрен ялгыз гизгәндә дә
Әнкәемнән ярдәм күрә идем.
Җил- давыллар явыз орган-суккан чакта
Әнкәй миңа куәт бирә иде.
Җил- давыллар явыз орган-суккан чакта
Әнкәй миңа җиңелмәс көч бирә иде.

Еллар үтте, еллар үтә...
Еллар үтте, гомеремнең көзе җитте,
Мин хәзер дә әнкәемә барам.
Чал башымны каберенә түбән иям,
Яшәү көчен әнкәемнән алам.
Чал башымны каберенә түбән иям,
Яшәү көчен газиз әнкәемдә табам.

## Изге туган җир

Сокланырлык урман, болыннары,
Өзелеп сөям туган җиремне.
Туган җирем гүзәлдән дә гүзәл,
Изгедән дә изге түгелме?
Иделләрем, горур Уралкаем
Канатлыдай итә күңелне.
Туган җирем газиз,
Изгедән дә изге,
Гүзәлдән дә гүзәл түгелме?

Язмыш мине кая ташласа да,
Оныта алмам туган илемне.
Туган илем нурлыдан да нурлы,
Данлыдан да данлы түгелме?
Җырларымда, йөрәк моңнарымда
Саклыйм мәңге туган телемне.
Туган телем моңлы,
Гүзәлдән дә гүзәл,
Изгедән дә изге түгелме?

Җирем, илем, телем
Иң мөкатдәс, газиз,
Изгедән дә изге түгелме?

## Кондырышым минем

Кондырышым минем, Кондырышым,
Киң колачын җәйгән имәннәр.
Тезелешеп баскан чыршылары
Ылысларын түбән игәннәр.
Әй урманым минем, куе урман,
Шомлы шаулый биек наратлар.
Кочаклашып үскән куаклары,
Ак каенлы көләч аланнар.

Кондырышым минем, Кондырышым,
Туган ил-йорт  җәнлек, кошларга.
Искитәрлек ямьле җәйләрендә,
Урман гүзәл карлы кышларда.
Әй урманым минем, кара урман,
Ата-бабам сиңа сыенган.
Килер буыннар да безнең кебек
Җырлап кайтыр урман буеннан.

## Эх Кормаш буйлары

Бик сагындым Кормаш буен,
Шунда кайтасым килә.
Үткән бала  чакларымны
Эзләп табасым килә.
    Кушымта:
    Эх Кормаш буйлары,
    Ялтыр көмеш сулары,
    Яшел хәтфә болыннары,
    Бормалы юллары,
    Сукмаклары, сукмаклары.

Ялан тәпи Кормаш буен
Әйләнеп үтәр идем.
Суларында  чума-чума
Туйганчы йөзәр идем.
    Кушымта.

Быел тагын кайталмасам,
Кормаш, бераз  көт инде.
Балачак табылмаса да,
Мине  син  үз ит инде.
    Кушымта.

## Казаклар авылы көе

Олы юлдан, борылмадан
Күренә безнең авыл.
Җәендә дә, кышында да
Бигрәк ямьле була ул.
        Кушымта:
        Наратлы тау, юкәле,
        Җиләкле тау итәге.
        Кайгыларга баш имәек,
        Без Казаклар бит әле.
        Авырлыкка бирешмәек,
        Без Казаклар бит әле!

Чишмәләрнең татлы суы
Һаман телемдә тәме.
Күз алдымнан мәңге китмәс
Туган авылым яме.
        Кушымта.

Өянкеләр каплап тора
Читән баганаларын.
Авылым чакыра сыман
Таралган балаларын.
        Кушымта.

Казакларның яшьләре дә,
Карты да җырлый икән.
Тәү тәпи баскан туфракны
Онытып булмый икән.
        Кушымта.

## Нигә төшләремә керәсең

Нигә төшләремә керәсең соң,
Нигә  яннарыма киләсең?
Төшләремдә бергә, өнемдә юк,
Эзләсәм дә юк син, китәсең.

Елмаеп син миңа төшләремдә
Ниләр турындадыр сөйлисең.
Үзәгемне  өзеп китәсең  бит,
Үзең генә шуны белмисең.

Күпме  еллар үтте, син юк инде,
Һаман төшләремә керәсең.
Сагынулар белән, сагыш белән
Гомерләрем үтәр, күрәсең.

Нигә төшләремә керәсең соң,
Кабызасың өмет чырасын?
Төшләремдә генә бергә  шул без,
Ә уянсам, юкка чыгасың.

## Печән исе

Болыннарга барсам, печән
Исләренә исерәм.
Яңа чапкан печән исе
Сине искә төшерә.
Хәтеремдә, күңелемдә
Дәртле гүзәл яшь чаклар,
Дөрли-дөрли йөрәкләрдә
Янган сүнмәс учаклар.

Исеңдәме печән өсте,
Миңа очраган идең.
Сөюемне әйтеп бирдем,
Син дә: яратам дидең.
Вәгъдәбезгә тик бер шаһит-
Хуш исле печән иде,
Саф хисләрнең якты нуры
Печәнгә төшкән иде.

Болыннарга барсам, кабат
Йөрәккә ут кабына.
Өзелеп сөйгән ярымны,
Яшьлегемне сагынам.
Кайда тәүге сөйгән ярым,
Кайда калды яшьлегем?
Печән өсте җитте тагын,
Кайтчы, зинһар, яшь көнем!

## Казлар китә

Казлар китә, каңгылдашып
Канатларын кагына.
Алар нигә китә икән
Гүзәл туган ягыннан?
Кушымта:
Казлар китә, казлар китә
Ерак җылы якларга.
Мин моңаеп карап калам
Киткән киек казларга.

Казлар белән китәр идем
Каерылган канатым.
Казлар белми йөрәгемнең
Дөрләп утта янасын.
Кушымта.

Киткән казлар, исән булса,
Кайтыр әйләнеп тагын.
Язган микән миңа күрү
Шул казларның кайтканын?
Кушымта.

## Күл буенда

Күл буенда утырганда
Моңланып бер җырладым.
Сагынуым, сагышымны
Таратсын, дип, җырларым.

Күлдә дулкын, ярга ургый
Таң җилләре искәндә.
Йөрәккәем ярсып тибә
Сылуым искә төшкәндә.

Күлнең дулкыннары сыман
Хисләр ташый күңелдән.
Мәхәббәтем күл суыдай
Коры җиргә түгелгән.

Пар аккошлар йөзә күлдә,
Көнләштем шул кошлардан.
Сөю хисен саклый белгән
Алар бар ялгышлардан.

## Кара бөдрә чәчләрең

Кара бөдрә чәчләреңне
Тарадың да, үрмәдең.
Шунда минем карашымны
Тоймадың син, күрмәдең.
Кара бөдрә чәчләреңне
Тагын тарасаң иде,
Сөю хисләремне сизеп,
Миңа карасаң иде.

Бөдрә чәчең толымнарын,
Кулыма алыйм әле.
Мәхәббәтемне аңларсың,
Күзеңә карыйм әле.
Чәчләреңне үзем тарап,
Үзем үрәсем килә.
Син дә мине сөясеңме,
Шуны беләсем килә.

Сайрар өчен сайлый былбыл
Яраткан алмагачын.
Сиңа гына сайрар идем,
Бөдрә чәч, карлыгачым.
Кара бөдрә чәчләр бигрәк
Килешә гүзәлемә.
Үкенечкә генә калма,
Ут салма йөрәгемә.

## Гармун

Уйный гармун, уйный гармун,
Күңелләрне күтәрә.
Юата да, җырлата да,
Биетеп тә җибәрә.

Кушымта:
Сайрар коштай, сандугачтай
Көмеш телле гармуным.
Тарата бит ул татарның
Бар сагышын, зар-моңын.

Дәртләндерә, ашкындыра,
Йөрәкләрне җилкетә,
Яңгыравык тавышлары
Җансызларга җан кертә.

Кушымта.

Гармун теле- кош канаты
Дәрьяларны кичәргә.
Гармун моңы- дөнья яме,
Гомер тәме яшәргә.

Кушымта.

Ямансулап, моңайганда
Шифа була җаннарга.
Әйдә, гармун, иркәлә кич,
Назла алсу таңнарда.

Кушымта.

## **Ялгыз аккош**

Ялгыз аккош оча һаваларда,
Парсыз калган икән бичара.
Моңлы тавышлары аһ-зар тулы,
Ялгызлыкка тапсын ни чара?

Талгын гына кага канатларын,
Тиз очарга юктыр теләге.
Ялгызлыкта нинди рәхәт булсын,
Беркемгә юк аның кирәге.

Күл өстенә кунып утыра да,
Тагын яңгырата тавышын.
Үзәкләрне өзеп китә икән
Ялгыз калган аккош сагышы.

Шул аккоштай мин дә ялгыз хәзер,
Каерылды очар канатым.
Көтмәгәндә парсыз иттең, Ходай,
Синең алда бардыр гөнаһым.

## Яна йөрәк

Синең зифа буйларыңа
Карап торам сокланып.
Бер мин түгел, күктә кояш
Нурлар сибә, таң калып.
Кушымта:
Яна йөрәк, яна йөрәк,
Тик күренми ялкыны.
Януларын баса алмый
Хәтта котып салкыны.

Сөюемне аңларсың дип
Җырлыйм алсу таңнарда.
Ләкин кайнар хисләремене
Теләмисең аңларга.
Кушымта.

Синдә генә күңелләрем,
Синең хакта уйларым.
Сиңа гына багышлана
Минем йөрәк җырларым.
Кушымта.

Сизәр әле, аңлар әле
Янып көюләремне.
Тыңлар әле, сине генә
Сөям диюләремне.
Кушымта.

## Белә идең сөюемне

Мәхәббәтем сер булмады,
Тирә-юньгә таралды.
Дару синдә генә иде,
Дәваларга ярамны.

Кушымта:
Белә идең, белә идең
Өзелеп сөйгәнемне.
Хыялый бер мәҗнүн сыман
Саташып йөргәнемне.

Күкрәгемнән йөрәгемне
Бирер идем чыгарып.
Күрер идең ялкыннарын,
Йөрәгемдә ут янып.

Кушымта.

Ә син миннән көлдең генә,
Тиң күрмәдең үзеңә.
Кайнар  хисләр сүнәр, дидең,
Күренмәсәң күземә.

Кушымта.

Бәхетем юк минем синсез,
Син дә бәхет тапмадың.
Саф мәхәббәт кирсез иде,
Җиргә салып таптадың.

Кушымта.

## Җыр бәйрәме

Бүген бездә җыр бәйрәме,
Бүген килгән кунаклар.
Җыр артыннан җырлар чаба,
Җиккән кебек пар атлар.

Йөрәк белән йөрәк бәйли
Төрле милләт моңнары.
Соклангыч, дип, җырлыр тыңлый
Гүзәл алсу таңнары.

Һаваларда очкан кошлар
Безнең җырга кушыла.
Монда бит ул һәрбер җырчы
Үзе сайрар кош сыман.

Җырлыйк, дуслар, җырлыйк әле,
Җыр бит күңел көзгесе.
Яңгырасын шаян җыр да,
Моңлысы да, изгесе.

## Тәнзилә

Синең кыйгач кашларың,
Кара бөдрә чәчләрең
Урын алды йөрәгемдә ,
Синсез,  җаным, нишләрмен?
　　Кушымта:
　　Оныталмам мәңгегә,
　　Башкорт кызы Тәнзилә.
　　Язмышлардан юк узмышлар,
　　Аерылыр көннәр килә.

Нәфис зифа буйларың,
Синдә генә уйларым.
Китмә, бәгърем, мине ташлап,
Син шифалы суларым.
　　Кушымта.

Еллар үтәр зар булып
Назлы бер карашыңа.
Һичбер дару ярдәм итмәс
Йөрәгем ярасына.
　　Кушымта.

## Адашып йөрмә әле

Адашып йөрмә әле.
Саташып китмә әле,
Безнең өйне танымыйча
Башкага кермә әле.
Син адашсаң, син саташсаң,
Мин дә шулай итәрмен.
Бер дә сине көтеп тормам,
Синсез генә китәрмен.

Саташып китмә әле,
Хисләргә тимә әле.
Мин сиңа тиң түгелмени,
Борының чөймә әле.
Әгәр шулай бик масайсаң,
Мин дә сине тиң итмәм.
Мин дә беләм масаерга,
Бер сүзеңне ишетмәм.

Адашып йөрмә әле,
Турымнан узма әле.
Үз ярыңа кырын карап,
Ятка кул сузма әле.
Мин дә башка яр табармын,
Үземә бер яраган.
Синең якка күз дә салмам,
Борылып  та карамам.

Адашып йөрмә әле,
Саташып китмә әле.
Яшьли туган хисләремне
Син таптап китмә әле.
Саф сөюне саклыйк бергә
Гүя күзем алмасын.
Тәүге сөю-саф мәхәббәт
Үкенечкә калмасын.

## Идел ярында

Идел буйларына барыйм әле,
Сагышларым салыйм дәрьяга.
Эчем тулы сагыш-хәсрәт минем,
Ялгыз гына башым дөньяда.

Иделемә карап туя алмыйм,
Сулар агышына сокланам.
Сагынуым чиксез-чамасыз бит,
Шуңа күрә һаман моңланам.

Идел ярларында таллар үсә,
Ботаклары суга иелгән.
Алар минем кебек ялгыз түгел,
Ерак түгел сөйгән Иделдән.

Иделкәем суы ярсып ага,
Агышлары тынар бу көздә.
Син шул якта булсаң,  китәр идем
Идел белән бергә диңгезгә.

## Сагынам

Йомшак кына җилләр искән чакта
Ерак туган-үскән ягымнан,
Туган илем күз алдыма килә,
Газиз туган илем сагынам.

Авылымның кичке урамында
Якты утлар балкып кабына.
Авылымны, калган дусларымны,
Үткән яшьлегемне сагынам.

Безнең якта туып үскән кошлар
Канатын да күркәм кагына.
Басудагы тургай,
Бакчадагы
Сандугачны өзелеп сагынам.

Шатланышып язда бар агачлар
Яшел челтәр шәлен ябына.
Туган якның чыршы, имәннәрен,
Балан, миләшләрен сагынам.

Җырларымны моңнар били минем,
Җырларымда сагыш чагыла.
Нишләп сагыш, моңнар булмасын соң,
Туган илкәемне сагынам.

## Җырлыйбызмы?

Җырлыйбызмы, әйдә җырлыйк,
Җырлый торган мәлебез.
Җырсыз дөнья бәхетсез ул,
Җырлап яшик әле без.

Безнең гүзәл җырлар һәрчак
Күңелләрне күтәргән.
Сабырлык та, көч тә биргән
Тормыш юлын үтәргә.

Хәсрәтләрне баса торган
Җырларыбыз бар безнең.
Моңнары да җанга якын,
Шифасы бар һәр сүзнең.

Авыр чакта кара төнне
Җырлар якты көн иткән.
Сагыш кушып, елаткан да,
Көлдергән дә, биеткән.

Җырлыйбызмы, әйдә җырлыйк,
Җырларыбыз яшәсен.
Туган җырлар белән җирдә
Һәрбер татар яшәрсен.

## **Оҗмах кайда?**

*Оҗмах аналарның аяк астында.*
*Татар халык әйтеме*

Оҗмах ерак түгел, диләр,
Аналарның аяк астында.
Игелекле бала булсаң да син,
Гел бурычлы,
Гел бурычлы
Анаң каршында.

Ана һәркемнең дә бердәнбере,
Кирәк сиңа тагын, тагын да.
Гомер буе үкенмәскә, дисәң,
Кадерен бел,
Кадерен бел
Исән чагында.

Ана кочагының оҗмах назын
Сагынмыйча ничек түзәрсең ?
Газиз әнкәеңнең җирдә калган
Бар эзләрен,
Бар эзләрен
Һәрчак эзләрсең.

Оҗмах кайда, диеп сорамагыз,
Ул анаңның аяк астында.
Нинди биек, бөек булсаң да бит,
Син кечкенә,
Син кечкенә
Анаң алдында.

## Сайрамачы, былбыл

Нигә сайрыйсың син, сандугачым,
Чут-чут итеп тәрәз каршында,
Әллә югалтырга уйлыйсыңмы
Кайгы-хәсрәтемнең барысын да?

Минем төшенке лә күңелемне
Әллә күтәрмәкче буласың,
Юатасың килеп
Читтә калган
Сагышлы бер татар баласын.

Бер киткәчтен ерак-еракларга
Кайталмыйм бит туган илемә.
Сагынам да, җирсим,
Туган яклар
Төшләремдә генә күренә.

Сайрамачы, былбыл, сайрамачы,
Яшьләр тулышмасын күземә.
Мин болай да моңнар дәрьясында,
Сагышлардан үзәк өзелә.

## Мәхәббәтем минем

Көтмәгәндә килеп чыктың
Барыр юлларыма.
Язгы йомшак җилләр булып
Кердең уйларыма.
Урын алдың күңелемдә
Алсу чәчәк сыман.
Иркәләдем шул  чәчәкне
Назлап, сылу гынам.

    Кушымта:
    Оныталмыйм, оныталмыйм,
    Уйда көнем-төнем.
    Кайда соң син, кайда соң син,
    Мәхәббәтем минем?

Йөрәгемдә ут кабыздың,
Ялкынында көйдем.
Кара күмер булып яндым,
Шулай сине сөйдем.
Кара төндә миңа син ай,
Көндез кояш үзең.
Бөтен галәм үзәге дә,
Хәтта сулыш идең.

    Кушымта.

Зәңгәр күктә якты йолдыз,
Нурлар сибә җиргә.
Нурлы йолдыз идең син дә,
Нигә сүндең, нигә?
Сагышларым ташып чыга,
Сурәтеңә карыйм.
Үзең юк шул.
Кайдан эзлим,
Кайдан эзләп табыйм?

    Кушымта.

## Кипкән чәчәк

Бүләк иткән идең миңа
Хуш исле бер ал чәчәк.
Шундый гүзәл булсын, диеп,
Безнең уртак киләчәк.
　　　　Кушымта:
　　　　Кипкән чәчәк, кипкән чәчәк,
　　　　Йөрәк телгеч кайтаваз.
　　　　Кайтыр күңелем яшьлеккә,
　　　　Яшьлек кире кайталмас.

Икәү бергә шул чәчәкне
Өметләндем сакларга.
Чәчәк миндә, кипкән инде,
Ә син калдың ятларга.
　　　　Кушымта.

Мәхәббәтнең сүрелүен
Сизмәдек тә, күрмәдек.
Шашып сөю үтте-китте,
Булып язгы гөрләвек.
　　　　Кушымта.

Кулларымда кипкән чәчәк,
Моңсу, гүзәл истәлек.
Яшьлек ярым күренмәсме,
Карасам бер текәлеп.
　　　　Кушымта.

## Китмә, җаным

*Мин бит синсез торалмам*
*Рәзил Вәлиев*

Китмә әле, җаным, мине ташлап,
Китмә инде, бәгърем, күз алмам.
Синсез мин бит Җирдә яши алмам,
Синсез мин бит Җирдә торалмам.
Кушымта:
Белмим, нигә үпкәләдең,
Мине ташлап китәсең.
Калган бөтен гомеремә
Бәхетсез җан итәсең.

Син булмагач, сүнәр миңа Кояш,
Көндезен дә күрмәм яктысын.
Үзең белән алып китәсең бит
Кайнар йөрәгемнең яртысын.
Кушымта.

Ярты йөрәк белән ничек яшим,
Күңелем һаман сиңа тартылыр.
Китмә инде, җаным, мине ташлап,
Иркен дөнья синсез тар булыр.
Кушымта.

## Әнкәемнең зәңгәр күзләре

Еллар үтте, инде онытылгандыр
Әнкәемнең кайбер сүзләре.
Тик онытылмый җанландыра торган
Әнкәемнең зәңгәр күзләре,
Әнкәемнең ялкын күзләре.

Кар-яңгырлар белән җуелгандыр
Әнкәемнең салган эзләре.
Ә күңелдә һаман балкып тора
Әнкәемнең зәңгәр күзләре,
Әнкәемнең нурлы күзләре.

Хаталарым барда сүрелгәндер
Әнкәемнең якты йөзләре.
Шул чакта да мине иркәләде
Әнкәемнең зәңгәр күзләре,
Әнкәемнең назлы күзләре.

Ятлар өчен бәлки күренгәндер
Шул күзләрдә берәр үзгәреш.
Ләкин миңа һәрчак нурлар сипте
Әнкәемнең зәңгәр күзләре,
Әнкәемнең балкыш күзләре.

## Сагынулар

*Мин сагынмый ята алмыйм,*
*Мин сагынмый торалмыйм.*
*Роберт Миңнуллин*

Сагынулы сагыш хисләремдә,
Сагынусыз, ахры, торалмам.
Сагынмыйча  ничек түзмәк кирәк
Еракларда  Идел-Уралдан.

Сагынулар белән иртә торам,
Сагынулар белән көн үтә.
Сагынуга  тулы кичләрем дә,
Сагынулар белән төн җитә.

Сагынулы күпме сәгатьләр дә,
Көннәрем дә үтте-киттеләр.
Айлар, еллар искән җилдәй үтте,
Сагынулар  гына үтмиләр.

## Су сорыйлар гөлләр

*Гөлләр су сорыйлар.*
*Рәдиф Гаташ*

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Ал гөлләрем суга сусаган.
Су сипмәгән алсу гөлләр сыман
Мин сулыгам инде ни заман.

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Юк аларга сулар сибүче.
Мин дә шул сусаган гөл шикелле,
Юк юатып миңа килүче.

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Ник кызганмый икән берәү дә?
Сулган гөлдәй көн дә яна йөрәк,
Тик әйталмыйм шуны берәүгә.

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Су сипмәсәң, гөлләр шиңәдер.
Син еракта инде,
Синсез гомер
Бер сулган гөл кебек нигәдер.

## Тальян гармун

Тальян  гармун  сөя татар,
Яңгыравык телләре.
Әйтерсең лә, саф татарча
Шул гармунның сүзләре.
Тыпыр-тыпыр биетергә
Шушы гармун чакыра.
Биетә дә, сикертә дә,
Барысын шак катыра.

Кулга гармун алса,татар
Оныта кайгыларын.
Оныта хәсрәтләрен дә,
Җирдә сагышлар барын.
Авырлыкка исе китми,
Шатлык тальян гармунда.
Саф мәхәббәт, ялкынлы хис,
Изге өмет бар монда.

Гармун уйнап, күңел ача,
Тавышына куана,
Моңлы гармун белән бергә
Җырлый-җырлый юана.
Көмеш телле тальян гармун
Җырлата бар татарны.
Гармун сайрап торган чакта
Җырланмастай җыр бармы?

## Карурман

Үзәннәргә төшкән томан,
Үзәннәрдә чал томан.
Томан арты кара пәрдә -
Серле, куе карурман.
Карурманга керер идем,
Адашырмын, кич инде.
Күңелемдә сагыш, моң-зар,
Саташырмын шикелле.

Әгәр керсәм карурманга,
Үтсәм борма юлларын,
Урман алып калыр иде
Кайгы-хәсрәт, моң-зарым.
Агачлары миңа гына
Иркә шавын багышлар,
Минем өчен кошлар сайрар,
Таралыр бар сагышлар.

Карурманны үткән чакта
Ишетер дә җырларым,
Кушылыр да, көйләр әле
Үз көйләрен урманым.
Җырлар белән урман көе
Бергә-бергә яңгырар.
Үксеп елап торган күңел
Һәм борчулы җан тынар.

## Соң булыр

Аерылгач, үкенерсең әле,
Мин булмагач, гөлләр тиз сулыр.
Үткәннәрне уйлап, сагынырсың,
Тик соң булыр инде,
Соң булыр.

Үткәннәрне уйлап, сагынырсың,
Күзләреңә кайнар яшь тулыр.
Кайтарасың килер шул елларны,
Тик соң булыр инде,
Соң булыр.

Кайтарыплар булмас шул елларны,
Сагыш гомер буе сузылыр.
Тормыш җырын бергә җырлар идек,
Тик соң булыр инде,
Соң булыр.

## Дөнья иркен, дөнья киң

Сайрый былбыл су буенда,
Дөнья иркен, дөнья киң.
Шул сандугач булып кына
Күренәсең миңа син.

Дөнья иркен, дөньялар киң,
Яннарымда булсаң син.
Бер илдә юк,  бер җирдә юк
Башка гүзәл, сиңа тиң.

Сөям сине, өзелеп сөям,
Җирдә  синсез мин ятим.
Хисләремне бер аңларсың,
Дөнья иркен, дөнья киң.

Яратырсың әле син дә,
Сөярсең, мин кемнән ким?
Икебезгә бөтен галәм,
Дөнья иркен, дөнья киң.

## Җырлап яшик

Җырлар барда уйлар уртак,
Җыр югалса, сүз башка.
Дус-ишләрең җыелганда
Ничек җырлар сузмаска.
Кушымта:
Картайсаң, картаймасаң да,
Күңелдә яшьлек әле.
Фани дөнья мәңге түгел,
Җырлашып яшик әле.

Җырлый-җырлый юлга чыгам,
Озын юллар кыскара.
Юлларында җәфа чигә
Җыр белмәгән бичара.
Кушымта.

Җырлар күтәрә күңелне
Йөрәк янган чагында.
Хәсрәт, сагыш онытылсын,
Җырлыйк әле тагын да.
Кушымта.

Шатлык тулы көннәр килсә,
Күңел тагын җыр тели.
Җырлы кеше җырлап яши,
Җырсыз ул гомермени!
Кушымта

## Эзлим сине

Эзлим сине, таба алмыйм,
Әйтче, бәгърем, нишләргә?
Чыраеңны күрәм сыман
Очраган һәр чибәрдә.

Эзлим сине, таба алмыйм,
Гөлемне җил тибрәтә.
Чәчкәләрнең хуш исләре
Гел сине хәтерләтә.

Эзлим сине, таба алмыйм
Сукмагым, юлларымда.
Җырларыңны ишетәм мин
Сандугач моңнарында.

Эзлим сине, таба алмыйм,
Беләм, табалмам инде.
Саф сөюең утларында
Башка яналмам инде.
Эзләп табалмам инде...

## Сызлама, йөрәк

Уртак ак бәхетләр икебезгә
Гомерлеккә диеп юрадык.
Хыялларда алтын сарай салдык,
Әллә нигезләрен кормадык.
Сызлама, йөрәк, сызлама,
Кыен миңа болай да.
Челпәрәмә килгән хыял
Калды алтын сарайда.

Алда якты юллар тигез иде-
Киләчәккә өмет ителгән.
Хәзер юллар түгел, сукмак та юк,
Киләчәккә өмет өзелгән.
Сызлама, йөрәк, сызлама,
Кыен миңа болай да.
Челпәрәмә килгән өмет
Калды алтын сарайда.

Ихлас белән кайнар сөю хисе
Өмет-хыялларга көч бирде.
Нинди дошман арабызга керде,
Шул хисләрне кемнәр җимерде?
Сызлама, йөрәк, сызлама,
Кыен миңа болай да.
Челпәрәмә килгән сөю
Калды алтын сарайда.

## Ташлама мине

Китәм инде, дисең, җаным,
Китәсең син кайларга?
Мин бит синсез яши алмам,
Еллар түгел, айлар да.
Ялгыз калса, аккошлар да
Чит күрә үз күлләрен.
Ташлама мине.
Ташласаң,
Сагышлардан үләрмен.

Бергә гөлләр үстердек без,
Чәчәкләре алсулар.
Китәсеңне сизгән кебек
Сулган алар, моңсулар.
Син булмагач, чәчәк атмас,
Корыр  инде гөлләрем.
Ташлама мине.
Ташласаң,
Сагышлардан үләрмен.

Китмә, бәгърем, китмә, җаным,
Мине ташлап китмәче.
Икебезне дә берьюлы
Ялгыз, ятим итмәче.
Ташлап китсәң, ялгыз итсәң,
Бу дөньяда нишләрмен?
Ташлама мине.
Ташласаң,
Сагышлардан үләрмен.

## Бергә барыйк

Әйдә, дустым, бергә барыйк
Урманнарга, кырларга,
Сандугачларга кушылып,
Парлашып бер җырларга.

Болыннарның, бар сәхрәнең
Гүзәллеген күрерсең.
Көлтә-көлтә кояш нуры
Икебезгә түгелсен.

Бакчаларда алмагачлар
Ботакларын иярләр.
Хуш ис гөлләр елмаешып,
Пар килгәнсез, диярләр.

Барыйк әле күл буена,
Пар аккошлар йөзәдер.
Безнең кебек бәхетле пар
Булса,  булыр йөзгә бер.

Әйдә, бәгърем, бергә үтик
Алдагы гомер юлын.
Бирәм сиңа йөрәгемне,
Бергә барыйк, бир кулың.

## Аерылма илеңнән

Туган илеңне ташлама,
Туган илдә бәхетең.
Шунда синең газиз халкың,
Шунда синең тәхетең.
Кушымта:
Туган илдәй илләр булмас,
Туган ил берәү генә.
Җанга шундый якын җир юк,
Син туган җирдәй генә.

Сагынырсың, саргаерсың,
Аерылсаң илеңнән.
Киек казлар да моңая
Читтә туган күленнән.
Кушымта.

Ятим итмәс сине халкың,
Туган-үскән илләрең.
Чыланмасын кайнар яшькә
Чит илләрдә күзләрең.
Кушымта.

Халкым моңы, туган көйләр
Һәрчак күңел түрендә.
Сагышларым ташыганда
Өзелеп җырлыйм үзем дә.
Кушымта.

## Ник очрамадың икән?

Яшьлегем таңында сине
Ник очратмадым икән,
Үз парымны эзләгәндә
Ничек тапмадым икән?

Нигә бергә булмагандыр
Элек салган сукмаклар.
Уртак түгел, инде сүнгән
Мин кабызган учаклар.

Дөнья көткән елларымда
Сине һаман белмәдем.
Шатлыгымда, кайгыларда
Яннарыма килмәдең.

Гомер көзе җиткәч кенә,
Балкып чыктың каршыма.
Яшь чактагы кебек хәзер
Карт йөрәгем ярсына.

Көтмәгәндә ярсый йөрәк,
Кинәттән ут кабуы.
Соңгы ярсуларыдыр ул,
Соңгы тапкыр януы.

## Агым сулар

Агым сулар, агым сулар
Үрләргә акмас инде.
Еласаң, еламасаң да,
Яшь гомер кайтмас инде.
Агым сулар туктамас та,
Агар да агар инде.
Качып-посып котылмассың,
Картлыгың табар инде.

Агым сулар аккан сыман
Үтте яшь гомеркәем.
Шунда калды сөйгән ярым,
Туган-үскән илкәем.
Агым сулар ярсый-ярсый
Дулкын бәрә ярына.
Илт син, дулкын, сәламемне
Яшьли сөйгән ярыма.

Агым сулар, аксагызчы
Газиз туган ягыма.
Изге  догам булыгызчы
Туган ил туфрагына.
Агым сулар, җиткерсәгез
Менә шул теләкләрем,
Мин картлыкны яшьлек итеп
Бер сагышсыз яшәрмен.

## Себер татарлары

Җәйрәп ята урманнары,
Киң дәрьялар, далалары.
Туган җирен сөеп җырлый
Шунда Себер татарлары.
Ауга йөргән, балык тоткан
Бай табигать балалары.
Күршеләргә ышанычлы
Дус-иш Себер татарлары.

Илбасарның юлын кискән
Азат ил азаматлары,
Күчүм ханның яугирләре-
Батыр Себер татарлары.
Явыз дошман кулларына
Төшкәндә дә Ватаннары,
Бирешмәгән, баш имәгән
Горур Себер татарлары.

Барабалар, Тубыл буе,
Иртеш, Тура, Том буйлары-
Туган-үскән газиз илем,
Без бит Себер татарлары.
Кайда гомер кичерсә дә,
Бербөтен бит татар бары-
Казандамы, Әстерханда,
Яки Себер татарлары.

## Ямансу

Үкенечле уйлар башымда
Төннәр буе.
Кышкы төн озын.
Ташлап киттең бер сүз дәшмичә,
Ямансулап йөрим ялгызым.
　　Кушымта:
　　Күпме эзләсәм дә, табалмам,
　　Оныталмам, истә син һаман.
　　Әрнеп үтә газиз гомерләр,
　　Өметләрем инде сүнделәр.

Гөрләвекләр ага ярышып,
Ярсып сайрый былбыл һәр язын.
Бер мин генә өнсез-тавышсыз,
Ямансулап йөрим ялгызым.
　　Кушымта.

Ямьле җәйдә чыгам сәхрәгә,
Урманнарга керәм җан сызып.
Адаштыра алмыйм сагышым,
Ямансулап йөрим ялгызым.
　　Кушымта.

Көздә бергә китә шаулашып,
Аккошларның юктыр парсызы.
Мин моңаеп калам озатып,
Ямансулап йөрим ялгызым.
　　Кушымта.

## Аерылышу сагышы

Биек тауларга менсәм дә,
Илкәемне күрмәдем.
Таулар, дәрьялар артында
Калды туган илләрем.
Дөнья гизгән чакларымда
Югалттым юлларымны.
Сизмәдем дә, белмәдем дә
Югалтам дип ярымны.

Су буена төшкән идем,
Кошлар кунган талларга.
Алар да сайраша бергә,
Минем дуслар кайларда?
Йөгерсәм дә, җитәлмәслек
Хәзер безнең аралар.
Көн дә әрни, төн дә әрни
Сагыш тулган яралар.

Язмыш авыр булса, булыр,
Узмыш юк язмышлардан.
Аера ул туган илдән,
Сөйгән ярдан, дуслардан.
Көнләшәм мин аккошлардан,
Күреп канат кагышын.
Юк шул дару басар өчен
Аерылышу сагышын.

## Яшьлегемне эзләдем

Идел буйларына бардым,
Эзләп үткән яшьлегем.
Адашып калмады микән
Бер булса да, яшь көнем.
Әгәр шуны очраталсам,
Яшәр идем сөенеп,
Белеп кадерен шул көннең,
Сөйгәнемнән сөелеп.

Карурманда йөрдем ялгыз,
Эзләп яшьлек җырларын.
Бәлки ишетелер, дидем,
Тыңлап урман кошларын.
Урман шавы, кош сайравы
Күңелләргә хуш килә.
Ләкин яшьлегемнең җыры
Ишетелми һич кенә.

Тугайларны бер әйләндем,
Тойдым йомшак җилләрен.
Җилләр бәлки кайтарыр дип,
Кайнар яшьлек хисләрен.
Чәчләремнән сыйпап җилләр,
Иркәләде үз итеп.
Яшьлек хисләремне генә
Кайтармады җил исеп.

Эзләдем кош сайравында
Урманда, тугаемда.
Эзләп йөрдем яшьлегемне
Туган  дәрьям буенда.
Эзләсәм дә, табалмадым
Үткән гүзәл көннәрем.
Йөрәкләрдә генә калды
Кайталмас яшьлекләрем.

## Онытa алмадым

Гөрләвекләр шаулап аккан язда
Сине тәү кат күрдем, гүзәлем.
Йөрәгемә дөрләп ут кабынды,
Гашыйк булдым, өзелеп үзәгем.
Яшермәдең син дә хисләреңне,
Мин дә әйттем, бердәнберем, дип.
Кайда калды шушы татлы язлар,
Гомерлеккә сөйгән идем бит.

Хыяллар да уртак иде безнең,
Назлы сөюләрдән туймадык.
Бергә-бергә саф мәхәббәт саклап,
Үтәр гомерләр, дип уйладык.
Кайнар хисләр дә бер сүрелерен
Белмәдем шул, мин бит белмәдем.
Уртак учакларда янган утны
Үзең сүндердең бит, сөйгәнем.

Үтте -китте безнең матур язлар,
Гомеремдә җитте көзләрем.
Ләкин һаман ишетелә сыман
Сине сөям, дигән сүзләрең.
Башка берәү белән зур бәхетләр
Табалдыңмы, юкмы, белмим мин.
Тик мин оныталмадым шул язларны,
Гомерем буе сине сөйдем мин.

## Гармун уйныйм әле

Гармун алып уйныйм әле,
Сагышларым таралсын.
Гармун моңы дәваласын
Йөрәгемнең ярасын.
Бәлки ишетерсең әле
Гармун уйнаганымны.
Аңларсың да минем сине
Сөеп туймаганымны.

Гармун очраштырган иде
Безне гүзәл язларда.
Ике йөрәктә дә кинәт
Ут янды шул чакларда.
Яшь йөрәкнең янулары
Татлыдан да татлырак.
Шунда күк тә ачык, зәңгәр,
Кояшы да яктырак.

Язлар үтте, син дә киттең,
Янымда бер гармуным.
Күкләремдә кара болыт,
Йөрәктә боз, кар минем.
Гармун алып уйныйм әле,
Дөньяларым онытып.
Алып китсен язмышымның
Шул кап-кара болытын.

## Барысы да истә

Агым сулар ага,
Үзенә юл таба,
Аккан судай гомер тиз үтә.
Дәрьяларның барын
Бергә кичсен ярың,
Яшьли сөйгән ярга ни җитә.

Гомер юлы төрле,
Бормалары серле,
Сизелми ул бергә үткәндә.
Яшьлектәге дустың
Яннарыңда булсын
Юлның ахырына җиткәндә.

Син җырлаган җырлар,
Күңелдәге уйлар
Моңнар булып калыр хәтердә.
Югалмасын җырлар,
Алда якты нур бар,
Җырлый- җырлый яшә хәзер дә.

Үтә көннәр, айлар,
Артта кала юллар,
Үкенмә син бик тиз үтә дип.
Син яшәгән еллар,
Үзең үткән юллар-
Барысы да синең истә бит.

## Елмаеп бер карале

Барам бүген  мин бакчага,
Син дә шунда бар әле.
Өзелеп сөям бит сине,
Елмаеп бер карале.
Син елмаеп караганда
Кояш  нуры яктырак;
Тарала күктә болытлар,
Ачыла көн ялтырап.

Син карасаң, син елмайсаң,
Күтәрелә бит күңел.
Күккә менәлермен сыман,
Дәртем бетмәле түгел.
Ә син миңа карамыйсың,
Күңелдә моң-зар әле.
Кызган инде мине бераз,
Елмаеп бер карале.

Көн дә торырга әзермен
Җиде юл чатларында.
Бәлки карар идең миңа
Юл үткән чакларыңда.
Синең елмаюларыңа
Мин зар-интизар әле.
Өзмә инде үзәгемне,
Елмаеп бер карале.

## Серләшербез

Күзләр дә бетсен әйдә,
Кышлар да үтсен әйдә.
Язларын да очрашмасак,
Бер күрешербез җәйдә.

Үтәре үтсен инде,
Көткәннәр килсен инде.
Сиңа булган тойгыларым
Иң кайнар хисем инде.

Якты көн килер әле,
Сүзләрем тик бер әле.
Әйтермен үзеңә генә,
Сөюләрем сер әле.

Үткәннәр үтсен әйдә,
Көткәннәр җитсен әйдә.
Очрашулар алда әле,
Бер серләшербез җәйдә.

## Көләч кыз

Оча-куна килә көләч кыз,
Аяклары җиргә тими дә.
Куанычы эчкә сыймаслык,
Атлаулары шуны сөйли лә.
Атлау гына түгел, биюдер,
Йөрәгендә, бәлки, сөюдер.

Бар хисләре аның йөзендә,
Канат җәйгән коштай талпына.
Тирә-якка нурлы елмаеп,
Тагын үз юлына ашкына.
Шатлыклары ташып чыгамы,
Елмаюсыз юктыр чыдамы.

Үз шатлыгын бу кыз һәркемгә
Бүлеп бирер сыман җәлләми.
Куансыннар өчен башкалар,
Шундук эшләр кебек әллә ни.
Ул кычкырып көлә шикелле:
«Яшәү рәхәт, дөнья күңелле!»

Урам тулы халык соклана
Шушы кызның көләч йөзенә.
Куанырлык мондый кәефне
Үлчәп карый һәркем үзенә.
И Аллам, мине дә күрсәнә,
Шундый берәр шатлык бирсәнә
Тик бер генә көнгә булса да.

## Газиз туган илкәем

Газиз туган илкәем,
Туган-үскән җиркәем.
Сагынганда, саргайганда
Еракларда нишләем?

Туган илдән аерылгач,
Җырда тик моң-зар гына.
Дөньялары киң булса да,
Никтер күңел тарсына.

Кайтсам иде илкәемә,
Агыйдел буйларына.
Былбыллар да кушылыр иде
Илемдә җырларыма.

**Агыла ла сулар**

Агыла ла сулар, и ургыла,
Ялмап-ялмап ала яр читен.
Бирми икән Ходай бәндәләргә
Тигез итеп дөнья бәхетен.

Агыла ла сулар, и ашкына,
Дулкыннарын куа җилләрдә.
Аккан сулар кебек үтә гомер
Туган илдән ерак җирләрдә.

Агыла ла сулар, и агыла,
Дулкынына көймә тагыла.
Шул көймәгә утырып китәр идем,
Сулар акмый туган ягыма.

## Туган җирем

Гади генә минем туган җирем,
Искитәрлек бер ни юк сыман.
Ләкин әгәр аннан аерылсам,
Мин һәрвакыт аны юксынам.
Искә төшә иркен басулары,
Инеш, дәрьялары, кырлары.
Шунда үтте минем балачагым,
Шунда туды минем җырларым.

Йөрәк түрләреннән чыга торган
Җырга кушам сине, туган җир.
Чагыштырмыйм сине башка җиргә,
Син кадерле миңа, бердәнбер.
Туган җиргә тиңдәш була алмый
Башка якта һичбер гүзәллек.
Шуңа бер сокланыр өчен дә бит
Юллар үтеп, дөнья гизәрлек.

Гади генә минем туган җирем,
Гадилеге белән сөйкемле.
Аның туфрагы да минем өчен
Алтыннардан кыйммәт шикелле.
Сине һаман җырларыма кушам,
И мөкатдәс минем туган җир!
Шунда гомер сөрү бәхетләрен
Насыйп итсәң иде, и тәкъдир.

## Борылып карарга онытма

Туган якны ташлап
Киткәндә юл башлап,
Ашыгып  атларны арытма.
Сагынырсың әле,
Саубуллашкан мәлне
Борылып карарга онытма.

Еракларга китеп,
Чит якны үз итеп,
Туган якта тамыр корытма.
Тамырсыз гөл сула,
Туган як бер була,
Борылып карарга онытма.

Үтә гомер  диеп,
Сагышларда көеп,
Уфтанып, моңланып яшь йотма.
Сулар үргә акмас,
Үткән гомер кайтмас,
Борылып карарга онытма.
Борылып кайтырга онытма.
Онытма...

## Туган як җилләре

Җилләр исә, йомшак җилләр
Туган -үскән ягымнан.
Сәлам алып килгән кебек
Сабый бала чагымнан.
Башларымны сыйпап үтә,
Әнкәм куллары сыман.
Шул кулларның иркә назын
Тоеп яшим мин һаман.

Әткәм тавышы кушыла
Җилләрнең исүенә.
Моң -сагышы, зары бардай
Гомерләр үтүенә.
Туган якның хуш исләрен
Китерә кебек җилләр.
Әйтерсең лә,
Озак йөрдең,
Илләреңә кайт, диләр.

Исмәгез лә, гел бер яктан,
Болай да моңсу күңел,
Эчем тулы дөрли янгын,
Ут өстәү кирәк түгел.
Бер кайтырмын,
Борылыгыз,
Безнең якка исегез.
Читтәге бала сәламен
Туган якка илтегез.

## Сабантуй

Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Җитте сабан туйлары.
Еракларга ишетелсен
Татар, башкорт җырлары.
Тартып уйна гармуныңны,
Без дә җырлыйк бергәләп.
Милли моңнар яңгырасын
Күңелләрне иркәләп.

Тыпырдатып биеп җибәр,
Җырлап, биергә кирәк.
Сабантуйда биемәгән,
Җырламаган бик сирәк.
Сикереп-сикереп биегәндә
Сөйгәнеңә бер кара.
Ул да биер синең белән,
Аңлашырсыз үзара.

Сабантуйда уен-көлке,
Шатлык,
Халык гөр килә.
Ярышларга чыгам, дисән,
Төрлесе бар, ни телә.
Ат чабышы, йөгерешме,
Чүлмәк вату, дисеңме,
Я көрәштә яулыйсыңмы
Батыр дигән исемне.

Иртәсеннән кичкә кадәр
Бәйрәм бүген көнозын.
Кемне күрсәң, шул дус монда,
Һич калмассың ялгызың.
Ашап-эчим, дисәң, чәй бар,
Ашка казан куелган.
Күпме вакыт дәвам итсен,
Туймам сабан туеннан!

## Яшьлек язым

Йөрәгемә ут кабызган
Тәүге мәхәббәт назын
Алып килде гөлләр белән
Иң гүзәл яшьлек язым.

Ашкындырып күңелләрне
Уйнаткан кебек сазын,
Җырлар булып яңгырады
Сөекле яшьлек язым.

Күзләр җиткәч карап калдым
Очып киткән кыр казын.
Казлар кайтыр,
Кире кайтмас
Бер үткән яшьлек язым.

Кайтмаса да гел тоярмын
Яшьлегем кайтавазын.
Күңелем түрендә мәңге
Чәчәкле яшьлек язым.

## Тәрәзәңне ачып куй

Тәрәзәңннән җилләр иссә,
Суз кулыңны җилләргә.
Анда сагыну сәламе,
Ул сәлам- мин җибәргән.

Тәрәзәңә ай караса,
Моңландырып күзләрне,
Ул китергән сиңа минем
Күңелдәге хисләрне.

Тәрәзәңә кояш төшсә,
Балкып торса яктысы,
Кайнар нурлар алган минем
Янган йөрәк чаткысын.

Тәрәзәңнән йолдыз күрсәң,
Яшеренмә йолдыздан.
Бәлки карашыбыз белән
Шунда очрашырбыз да.

Тәрәзә алдында күрсәң
Төшеңдә мине тагын,
Бу- чиксез сагышка әрнеп,
Үзәк өзелгән чагым.

## Яфраклар коелганда

Кызарган да, саргайган да
Яфраклары коела.
Алмагачым сагышлы да,
Хәсрәтле дә тоела.

Уфтангандай чайкала ул,
Болгый-болгый ботагын.
Җил исмәсә тына.
Аннан
Чайкала башлый тагын.

Син пошынма, алмагачым,
Вакыт җиткәч, яз килер,
Күршеләрең гел ямь-яшел
Киемнәрен киенер.

Күктән кояш барыгызны
Нурлары белән назлар.
Син дә өр-яңа яфраклар
Ярырсың,
Килгәч язлар.

Яшәү көче агачларны
Яшелләтер, яз булгач...
Тик мәхәббәт яшелләнмәс,
Яфрагы бер коелгач.

## **Кайда син?**

Кайда калдың син, җанашым,
Минем тәүге сөйгәнем,
Мәхәббәтнең иң ялкынлы
Утларында көйгәнем ?

Ник аерды безне язмыш,
Киттек төрле юллардан?
Син калдың тик хыялымда,
Уйларымда, җырларда.

Бүген дә син гүзәл килеш
Төшләремә керәсең.
Кашлар сирпеп карыйсың да,
Үзәгемне өзәсең.

Кайтарыплар алыр идем
Тәүге  сөюләр дәртен.
Кайда соң син, кайда калдың,
Беренче мәхәббәтем?

## Сөю

Син барында төн дә якты,
Син югында көн кара.
Нәрсә генә эшлим инде,
Сөюемә юк чара.
Шәфкатьле бул, кызган мине,
Яндырма утларыңда.
Юк калканым сакланырга
Сөйдергеч укларыннан.

Хыялыйлар булам инде,
Зиһеннәрем чуала.
Бер ышанам сөюеңә,
Бер уйласам, шомланам.
Ярсып-ярсып тибә йөрәк,
Күңелләрем җилкенә.
Сүзсез дә аңлармын сине,
Тик яныма кил генә.

Күктән йолдыз алып бирәм,
Әйтсәң кайсы яравын.
Әҗәлгә дарудай миңа
Елмаеп бер каравың.
Кил, кичекмә, салкын җилләр
Җаннарыма тимәсен.
Алып китик икәү бергә
Шушы дөнья көймәсен.

## Беренче мәхәббәтем

Яшьлегем иртә язында
Тәүге сөю кабынды.
Йөрәккәем читлектәге
Кошчык сыман талпынды.
Синең хактагы хыял да
Бирде дөнья ләззәтен.
Кайларда йөрисең хәзер,
Беренче мәхәббәтем?

Синеерактан күрсәм дә,
Ял була иде җанга.
Хисләр йөрәгемә түгел,
Сыймас иде җиһанга.
Яшьлек таңында сөйгәнем
Булмадың шул бәхетем.
Кемгә бәхет булдың икән,
Беренче мәхәббәтем?

Таң кошлары сайравына
Тавышыңны тиңләдем.
Онытылыр, дисәләр дә,
Ышанмадым, күнмәдем.
Һаман күз алдымда сыман
Күренеш, кыяфәтең.
Күңелемдә гүзәл җырдай
Беренче мәхәббәтем.

## Төнге йокыларым качты

Төнге йокыларым качты,
Сагышлы күңелләрем.
Саргайтты  тәкъдир, корытты
Яшьлегемнең гөлләрен.

Төнге йокыларым качты,
Күздә кайнар яшь тулы.
Хушлашу мәңгегә булды,
Йөрәк шуңа ярсулы.

Төнге йокыларым качты,
Хәсрәт миндә көн дә, кич.
Үкенүләр соңлап килә,
Соңлаулары үкенеч.

Төнге йокыларым качты,
Уйлар тулы башкаем.
Кайгылы шул уйларымны
Кая илтеп ташлаем?

**Чикләвек**

Яшел чикләвек куагы
Җәелеп үсә икән.
Яшь гомерне сизми калдым,
Бигрәк тиз үтә икән.
Кушымта:
Тәлгәшендә ничә дистә,
Чикләвек бигрәк уңган.
Чикләвектәй бердәм булып
Тату яшәек, туган.
Яфрак астыннан елмая
Чикләвек тәлгәшләре.
Шул урманда калды микән
Эх, унсигез яшьләрем.

Чикләвек үскән ботаклар
Бөгелә дә, сыгыла.
Яшь гомерең кире кайтмас,
Дигән кебек тоела.
Кушымта.

Чикләвекләр, чикләвекләр,
Өзим икән кайсын соң?
Үткән гомер үткән инде,
Алда булсын яхшысы.
Кушымта.

## Бирче дару

Урманнарга керсәм, моңланам мин,
Күңелләргә тула сагышым.
Бирче, дустым, миңа берәр дару,
Җиңеләйтсен дөнья кайгысын.

Дару бирсәң, йөрәк ярсуларым
Бәлки басылыр да, бетәр дә.
Авыр кайгы баскан йөрәк белән
Бу дөньяда ничек яшәргә?

Эчем тулы дөрләп янган ялкын,
Берәр вакыт шул ут сүнәрме?
Бирче, дустым, берәр даруыңны,
Юкса, сагышлардан үләрмен.

## Карурманнарга керәм

Карурманнарга керәм мин,
Адашам юлларында.
Бу дөньяда ялгыз башым,
Беркем юк яннарымда.

Карурманнарга керәм  мин,
Тыңлыйм сайрар кошларын.
Кош сайравына охшатам
Гомерем агышларын.

Карурманнарга керәм мин
Сагыш, моңнарым белән.
Үземне  үзем юатам
Шунда җырларым  белән.

## Үпкәләмә, җаным

Әгәр кайбер әйткәннәрем
Ишетелсә авыр сүз булып,
Хәтереңдә һич саклама
Шул сүзләрне, җаным, тиз онытып.
Кушымта:
Үпкәләмә, җаным, үпкәләмә,
Болыт капламасын күкләрне.
Көләч кояш балкып торсын,
Елмай әле, югалт үпкәңне.

Илтифатсыз булсам, кичер,
Дөнья бит ул, төрле чагы бар.
Караңгы төн үтәр, китәр,
Чыда бераз, аның таңы бар.
Кушымта.

Кәефеңне кырып торса
Сиңа ошамаган гадәтем,
Ашыкма син үпкәләргә,
Һич туктатма бәхет сәгатен.
Кушымта.

Сөю хисе сүрелә дип,
Үпкәләргә үпкә өстәмә.
Үпкә белән сагыш бергә,
Ә аларга кайгы өстәлә.
Кушымта.

## Аерылышу

Киткән чакта бер тутырып
Карадың күзләрмә.
Ышандыңмы,  йөрәккәем
Янса да, түзәремә?
            Кушымта.
            Күзләремә тулган  яшьне
            Күрсәтмәдем, чыдадым.
            Аерылып  калгач  кына
            Үксеп-үксеп  еладым.

Бик  азга дип киткән идең,
Булып чыкты озакка.
Нигә аңламадык икән
Шуны аерылган чакта?
            Кушымта.

Юллар икегә бүленде,
Юк кушылыр урыны.
Күңелемдә мәңге-мәңге
Яңгырар сагыш моңы.
            Кушымта.

### Әйдә, дустым, җырлап җибәр

Безгә генә килде микән
Замана болгавыры,
Кайгысы да, хәсрәте дә,
Дөньяларның авыры?
Әйдә, дустым, җырлап җибәр,
Имин еллар бар әле.
Кайгыларым дәрья суы
Булып аксыннар әле.

Язмыш насыйп иткән микән
Кыен, тынгысыз чорлар?
Шуңадыр ул сагышлы да,
Моңлы да безнең җырлар.
Әйдә, дустым, җырлап җибәр,
Тыныч айлар бар әле.
Көлгә әйләнсен сагышлар,
Күккә очсыннар әле.

Ярый, килгәч, килгән инде
Шушы боталчык дәвер.
Шул дәвердә үтеп бара
Газиз гомер, бердәнбер.
Әйдә, дустым, җырлап җибәр,
Матур көннәр бар әле.
Караңгы төн мәңге түгел,
Якты таң атар әле.
Сагышларны таратырлык
Җырлар бездә бар әле!

## Асыл кошым

Асыл кошым, диеп  җырлыйм
Сагынганга, гүзәлем.
Сагыш утларында  янам,
Белмим ничек түзәрем.

Асыл кошым, сандугачым,
Без инде бергә түгел.
Икебез ике якта шул,
Шуңа моңая күңел.

Асыл кошым, ник борылдың
Син башка бер юлларга?
Нигә мине дучар иттең
Гел моңаеп җырларга?

Асыл кошым, карлыгачым,
Югалмасын өметләр.
Юллар бәлки кушылыр да,
Килер уртак бәхетләр.

## Яшь чакларда гына

Гармунчының осталыгы
Тик бармакларда гына.
Гармун кебек сайрый күңел
Тик яшь чакларда гына.
    Кушымта:
    Эх яшьлегем, яшьлегем,
    Тилмереп көткән идем.
    Балкып торган яшьлектән
    Беркайчан китмәс идем.

Өзелеп җырлаган җырым
Синең хакларда  гына.
Кайнар хисләр, гүзәл көйләр
Тик яшь чакларда гына.
    Кушымта.

Җилләр җитмәслек шәп атлар
Безнең якларда гына.
Чапкырдай тыялмас тойгы
Тик яшь чакларда гына.
    Кушымта.

Күңел түрендә яшьлекне
Кирәк сакларга гына.
Күңелләреңдә кайтырсың
Тик яшь чакларга гына.
    Кушымта.

## Үпкәләмим сиңа

Үпкәләмим сиңа,
Тик күңел юксына
Сагынып бәхетле көннәрне.
Нигә соң кадерен
Белмәдек, бәгырем,
Төш кебек сихерле өннәрнең?

Хәзер без аерым,
Канатлар каерым,
Очалмам инде мин күкләргә.
Күрмим көн яктысын,
Караңгы барысы,
Нур калды сөекле күзләрдә.

Йөрәгем бер тынар,
Үпкәләмим сиңа,
Сүзеңдә тормаган булсаң да.
Сагышлы гомерем,
Моң - минем тәкъдирем,
Дөньяга бәхеткә тусам да.

## Зәңгәр күзләр

Мәңге янар кояшы бар,
Күк нурга тулган инде.
Синең зәңгәр күзләр өчен
Мин кояш булсам иде.
Нур сипсен иде күзләрең
Тик минем өчен генә.
Көч бирсен иде нурларың
Тик минем җилкәнемә.
Кушымта:
Күктә күрәм күзләреңне,
Зәңгәр күктәй күзләрең.
Тирән сер иде хисләрем,
Әйтер булдым, түзмәдем.

Нурлы күз карашың белән
Мине генә иркәлә.
Шул караштa җан җылысы,
Шуннан йөрәк дәртләнә.
Ишет, җаным, шушы сиңа
Багышланган җырымны.
Күңелеңдә яңгыраса,
Бир син миңа кулыңны.
Кушымта.

## Әлфия

Күктә кояш, күктә кояш,
Кояшыма таң калам.
Җир йөзендә Әлфия бар,
Әлфиягә сокланам.
Нурлы йөзе балкып тора,
Күзләрне камаштыра.
Карашлары саташтыра,
Сихерләп адаштыра.
Кушымта:
Әлфиям, Әлфиям,
Мин сөям, сине сөям.

Көне-төне күз алдымда
Синең зифа буйларың.
Сөю утларында янам,
Синдә генә уйларым.
Челтер-челтер ага чишмә,
Шул тавыш телләреңдә.
Хыял диңгезендә көндез,
Төшемдә - төннәремдә.
Кушымта.

Нигә, җаным, нигә, җаным,
Миңа бер карамыйсың?
Әллә инде йөзләремдә
Син нурлар табалмыйсың?
Син карасаң, син яратсаң,
Минем йөз дә нурланыр.
Икесе дә пар килгән, дип,
Бөтен кеше сокланыр.
Кушымта.

## Гомерем буе сине эзләдем

Яшьлегемнең дәртле язында
Ай-кояшка сине тиңләдем.
Нинди юл чатында югалдың,
Гомерем буе сине эзләдем.
Кушымта:
Эзләдем мин, табалмадым,
Җитте инде кышларым.
Кавышулар язмагандыр,
Очты өмет кошларым.

Әллә ялгыш кына адаштың,
Әллә үзең ташлап киттеңме?
Минем сагынырым белдеңме,
Үзе эзләп килер, дидеңме?
Кушымта.

Китәр идем шул юл чатына
Бүгеннән үк.
Тик син кайт кына!
Сарыларга күптән сабыштым,
Кызганмыйсыңмыни чак кына?
Кушымта.

## Синең өчен

Шушы  җырым синең өчен,
Бәлки, берәр тыңларсың.
Бик сагынган чакларыңда
Кушылып бер җырларсың.

Йөргән юллар синең өчен,
Туры килер юл чаты.
Шул бәхетле юл чатында
Булсын иде очрашу.

Бу гомерем синең өчен,
Син бар диеп, мин яшим.
Кавыштырсын иде язмыш
Мәңгелеккә,  син дә мин.

Бу  хисләрем синең өчен,
Кичер мине, кичектем.
Синең сөю сүзләреңне
Соңлап кына ишеттем.

## Хуш инде, хуш

Җырым сиңа багышлана,
Мәңгелек яр, дигәнем.
Син көткәндә киләлмәдем,
Хуш инде, хуш, сөйгәнем.

Шаян  җилләр тутырмады
Уртак тормыш җилкәнен.
Икебезгә ике каек,
Хуш инде, хуш, сөйгәнем.

Синсез үтте гомер җәем,
Синсез үтә көзләрем.
Язлар гына бергә  булды,
Хуш инде, хуш, сөйгәнем.

Бар уйларым синең хакта,
Синең өчен көйгәнем.
Янында мин түгел, башка,
Хуш инде, хуш, сөйгәнем.

**Туган илкәем**

Бардым болыннарга,
Тонык елгаларга,
Әйтерсең, бар галәм  бер миндә.
Үләннәр хуш исле,
Сулар көмеш төсле,
Мондый болыннар юк чит илдә.

Әрәмәдә йөрдем,
Урманнарга кердем,
Нинди матур безнең урманнар!
Сагыш бетә шундук,
Читтә урманы юк,
Нәкъ безнеңчә шаулый торганнар.

Бардым киң кырларга,
Чыктым басуларга,
Сабан тургайлары сайраша.
Чит якта тар дөнья.
Җанга рәхәт монда,
Көләч кояш, күзләр камаша.

Болын, кырлар иркен,
Урманнары күркәм,
Нинди гүзәл туган  илкәем!
Читтә бәхет тапмам,
Илкәемне ташлап,
Ничек инде чыгып китәем?!

## Көт мине, иркәм

Күптән туктасам да чит җирләрдә,
Ике күзем һаман юлымда.
Ат җигүле тора ишегалды,
Кайтыр юлны карыйм алдымда.
Сиңа гына кайтыр идем,
Каршы алырсың микән?
Сүндермә кич утларыңны,
Көт мине, көт син, иркәм.

Син ашыкма мине онытырга,
Хәтереңнән сызып ташлама.
Оныткандыр инде, дип уйлама,
Йөрәк серең ачма башкага.
Чит илләрдә аңладым мин,
Бердәнберем син икән.
Очып чыгармын юлларга,
Көт мине, көт син, иркәм.

Сүрәнләтмә уртак мәхәббәтне,
Йөрәкләрдә ялкын дөрләсен.
Шул ялкында бергә без янарбыз,
Арабызга ятлар кермәсен.
Тәүге кояш нуры белән
Сиңа кайтырмын иртән.
Таң җилләре назлар безне,
Көт мине, көт син, иркәм.

## Ничек түзәрмен

Сагынмаска вәгъдә бирдем,
Аерылгач та, сагынмам.
Сагынучы ярлар бардыр,
Тик мин булмам сагынган.
Күкне кара болыт баскач,
Күңелсез шул, гүзәлем.
Сагышларда берьялгызым,
Шуңа ничек түзәрмен?

Еракларга китәрмен дә,
Сагынмам, дип уйладым.
Ләкин һаман оныталмыйм,
Синең хакта уйларым.
Кошлар кайта туган илгә,
Ярсып сайрый, гүзәлем.
Ялгыз гына тыңлыйм инде,
Шуңа ничек түзәрмен?

Сагынмам, дип өйдән чыгам,
Кире кайтам сагынып.
Эзләсәң дә,эзләмәсәң,
Син юк монда, тагын юк.
Гөлләр ярсып чәчәк ата,
Хуш ис аңкый, гүзәлем.
Тик бакчада сине тапмыйм,
Хәзер ничек түзәрмен?

## Һаман сокланам

Тагын карыйм,  тагын сокланам мин,
Бирелгән  бит сиңа мул бары.
Алсу йөзең һәрчак балкып тора,
Йөзең тулы кояш нурлары.
Карашыңда йөрәк  җылысы  бар,
Карашыңда сөю назлары,
Шунда-
Саф  мәхәббәт кочагына
Алып кергән яшьлек язлары.
Кушымта:
Һаман карыйм, карап туялмыйм мин,
Инде күптән сиңа гашыйкмын.
Китәр вакытым да җитте бугай.
Китмим әле.
Юк, юк, ашыкмыйм!

Карашыңда язгы дәртле хисләр,
Күңелеңнең  керсез яктысы.
Күкнең  гүзәл төпсез зәңгәрлеген
Күзләреңә биргән,  ахрысы.
Синең күзләреңә кереп батам,
Иркә сүзләреңә уралам.
Йомшак ефәк кебек сүзләреңә
Уралам да, бетәм, югалам.
Кушымта.

Тавышыңда синең җиз кыңгырау,
Аһәңдәштер аңа чишмәләр.
Ялгыш булмас синең телеңне дә
Балдан татлырак  ул, дисәләр.
Синең белән матур язлар килә,
Гөл чәчәкләр сиңа карыйлар.
Синең белән  якты көннәр туа,
Сандугачлар сиңа сайрыйлар.
Кушымта.

## Сирень

Сирень чәчкә  аткан иде
Сине очраткан чакта.
Исенә исергән идем,
Сирень тулы кочакта.
Елмаеп кына карадың,
Онытылды сиреньнәрем.
Чәчкәдән дә сөйкемлерәк
Тоелды иреннәрең.

Сирень чәчәген бер кочак
Бирдем сиңа китереп.
Кемгәдер  ул  чәчкә  генә,
Кемгә-йөрәкнең сере.
Кабул иттең чәчкәләрне,
Никтер мине иш иттең.
Әллә чәчкә белән әйткән
Сүзләремне ишеттең?

Сирень чәчәге  ак була,
Зәңгәр дә, кызыл-көрән.
Өнемдәме кавышулар,
Әллә төшемдә күрәм.
Сирень алып килде бәхет,
Кояш күк  балкыганын.
Сирень генә баса икән
Йөрәктә   ут  янганын.

## И җаным, и күз алмам

Бөтенләй үзеңнең ишең,
Бәхетеңә туган кеше
Була микән?
Йә табылыр, йә югалыр
Бердәнберенә баралыр
Юл бар икән.
Кушымта:
И җаным, и күз алмам,
Синсез җирдә торалмам.

Гомерлек юлдаш булырдай
Кадерле җан табылыр да,
Таныр микән?
Бер-береңне табарга да,
Үз ишем дип танырга да
Авыр икән.
Кушымта.

Мәхәббәт чәчәк атса да,
Бергә булу гөл бакчада
Язган микән?
Сөю сынауны күп күрә,
Язмыш бәхетне тик бирә
Аздан икән.
Кушымта.

## Эзләмә мине

Юллар күптән аерылды,
Аерылды язмышлар.
Якты хатирәләр истә,
Ә күңелдә сагышлар.
Күзләрең гел эзли мине,
Үзәкләрне өзгәләп.
Синең өчен мин юк инде,
Эзләмә син, эзләмә.

Бер урамда очрашсак та,
Ерак безнең аралар.
Якынаеп булмас хәзер,
Ни юлы, ни чара бар.
Кая барма,  синең һаман
Күз карашың эзләнә.
Үткәннәргә сукмак та юк,
Эзләмә син, эзләмә.

Сагынсаң да, сагынмасаң,
Булмый инде кайтарып
Үткән гүзәл мизгелләрне,
Булмый яңа юл ярып.
Өметләнмә, кайтыр, диеп,
Уртак бәхет безгә дә.
Утлар салма йөрәгемә,
Эзләмә син, эзләмә.

## Намаз

Кем дә кем гыйбадәт кылыр,
Биш вакыт намазда булыр,
Мөселман ул шунда гына,
Шунда тугъры иманына.

Тән вә киемен пакь кылып,
Изге кыйблага борылып,
Чын күңелдән кылсаң доган,
Кабул итәр аны Аллаң.

Иртә, өйлә намазларын,
Икенде һәм акшамнарын,
Ястүен дә укый торган
Имин яшәр, күрмәс зыян.

Намаз фарыз мөселманга,
Иман башы, шифа җанга.
Хак Тәгалә ярлыкасын
Намаз кылган һәр баласын.

## Вәгаләйкем-әссәлам

Мөселманда тәртип шундый:
Сөннәттер - бирү сәлам.
Әмма сәлам алу фарыз,
Вәгаләйкем-әссәлам.
Ата-анаң биргән сиңа
Бөтен дөнья, зур галәм.
Игелекле бул аларга,
Вәгаләйкем-әссәлам.

Берәү өйрәтсә әлифне,
Кулыңа бирсә каләм,
Гомер буе рәхмәтле бул,
Вәгаләйкем-әссәлам.
Җылы, йомшак сүзләр белән
Әгәр сиңа дәшсәләр,
Җавабың да күркәм булсын,
Вәгаләйкем-әссәлам.

Саф күңелдән булса ярдәм,
Баш тартма бу нәрсәдән.
Аш атканга ташлар атма,
Вәгаләйкем-әссәлам.
Яхшы эшеңне сөйләмә,
Суга ташла, вәссәләм.
Үзеңә кире кайта ул,
Вәгаләйкем-әссәлам,
Вәгаләйкем-әссәлам!

## ШАЯРЫП, КӨЛЕП КЕНӘ

### Тәүбә иттем

Олыгайсам, акыл тирән
Булыр, диеп, өмет иттем.
Хәзер, шөкер, акыл җитә,
Күп нәрсәдән тәүбә иттем.

Дуслар белән күңел ачтым,
Кыстасалар, хәмер эчтем.
Хәмер дә юк, кыстаучы да,
Эчмим хәзер.
Тәүбә иттем.

Башкаларны тыңламыйча,
Үз сүземне әйтә киттем.
Хәзер мине тыңламыйлар,
Сүз кушудан тәүбә иттем.

Күп гүзәлләр тәкъдим итте
Үз хисләрен, ялкып беттем.
Хәзер исләре дә китми,
Сөюдән дә тәүбә иттем.

Инде акылга ирештем,
Куйган морадыма җиттем.
Эх, шәраб та эчәр идем,
Дусларга сер сөйләр идем,
Гүзәлләрне сөяр идем,
Дәрт-дәрман юк.
Тәүбә иттем!

## Телефон газабы

Япь-яшь кенә бер хатын
Онытып бар дөньясын
Көнозын ләчтит сата,
Телефон да шаккаты.

Сәгать буе тел чарлап,
Галәм хәлләрен барлап,
Сөйләмәгән сүз калмый,
Ничек телләре талмый?

Арыса бер сүздәше,
Таба башка сердәшен.
Сүзен башлый яңадан,
Чыгып китә чамадан.

Сүзгә сүзе ялганыр,
Кайдан сүз табыладыр;
Ял бирми бер минутка,
Чыда шундый холыкка!

Нишләсен соң телефон,
Хуҗа кулында закон;
Теләсә, гел эшләтер,
Күрмәгәнне күрсәтер.

И телефон, телефон,
Телле җанга ипле сан.
Нигә бер ватылмыйсың,
Бу хәлдән котылмыйсың?

Син ватылсаң, хатын да
Уйлар үзе хакында;
Өенә салыр көчен,
Тормас тик ләчтит өчен.

Үз эшләрен караса,
Бик зур файда ләбаса.
Бәлки шунда өйрәнер,
Инде азрак сөйләнер?

## Эмансипация

Эмансипация диеп,
Шатланалар хатыннар:
Ирләр эшен эшләргә, ди,
Хәзер минем хакым бар.

«Рәхәтләнеп» бетон ташый
Корылыш эшләрендә.
Атлыгып барып керә ул
Янган ут эчләренә.

Металл коя, ташлар вата,
Авыр йөкләр күтәрә,
Тәмәкесен дә көйрәтә,
«Чирттереп» тә җибәрә.

Иренең дә кадере юк,
Балалар да кирәксез,
Тормышы да бәрәкәтсез,
Гаилә дә терәксез.

Чәчләр кыска, тупас тавыш.
Ирләр чалбарын киеп,
Йөри хатын-кыз шатланып:
«Хокуклар тигез», -диеп.

Калышмый бит ир-аты да
Үзгәрергә тырышып,
Берсен-берсе узар өчен
Чын күңелдән ярышып;
Алка тага колагына,
Озын чәчләр үстерә,
Тасма тага чәчләренә,
Толым-толымлап үрә.

Карасаң, танып та булмый,
Әллә хатын, әллә ир.
Тик алар төрле җенес бит,
Арасы күк белән җир!

Кешенең табигатенә
Болар бит каршы килә.
Нәрсә булып бетәр бу хәл,
Тик Алла гына белә.

## Гаиләдә кем хуҗа?

Көннәрдән бер көн ирләрне
Гәпкә дип чакырганнар.
Хатын-кызлар килмәсен дип,
Алдан әйтеп куйганнар.

Билгеләнгән вакытында
Үз ирләрен ияртеп
Килеп җиткән бит хатыннар,
Барысы да диярлек.

Алга куелган әңгәмә
Тик ир-ат өчен булгач,
Хатын-кызлар чыгып киткән,
Ирләр җайлап утыргач.

Шунда гына сүз башланган,
Кем хуҗа гаиләдә:
Ирме, әллә хатынымы,
Кем тарта дилбегәдән?

Җыелган ир-ат мактана,
Кәнишне, мин хуҗа, дип,
Хатын үкчәсе астында
Йөрергә юк нужа, дип.

«Әй җәмәгать,- дигән берсе,-
Сүзне туктатып торыйк:
Өйдә хуҗа булган ирләр
Җыелышып утырыйк.

Хатыннары хуҗа булса,
Сул якка утырсыннар».
Менә шуннан киткән күчеш,
Алмашынган урыннар.

Мин, дип мактанучы ирләр
Астыртын, шыпырт кына
Күчә башлаган сул якка,
Баш иеп, качып кына.

Бераздан соң карасалар,
Искитәрлек күренеш:
Уң  якта тик бер генә ир
Утырып калган, имеш.

Кызыксынып, көнләшеп тә
Сорау биргәннәр моңа:
«Безне дә өйрәтсәң икән,
Ничек  булдың син хуҗа?»

«Кая инде гаиләдә
Хуҗа  булу ирләргә,-
Дигән икән бу бичара,-
Хатын кушкач, нишләргә?
Хатын нәкъ шул урындыкка
Утыртты да, китте бит.
Шуннан кузгаласы булма,
Дип ныгытып әйтте бит».

«Хәлләр бертөрле икән»,- дип,
Ир-ат шунда көлешкән,
«Гаилә терәге хатын»,-
Дигән сүзгә килешкән.

Хәзер монда «Мин хуҗа», дип
Мактанган  ир юк, имеш.
Гаиләләр дә бик тату,
Һич бозылмас, нык, имеш.

## Дуамал эт

Китеп барам беркөн урам буйлап,
Шыгырт-шыгырт итә ап-ак кар.
Кояш күктә көлә, ә мин җирдә,
Шатланышып атлый аяклар.

Күпләр йөри бүген менә монда
Шундый гүзәл көнгә сокланып.
Карда аунап уйный бала-чага,
Урам киңлегенә шатланып.

Кинәт әллә кайдан килеп чыкты
Өрә-өрә  бер эт, кечкенә,
Башка беркемгә дә игътибар юк,
Очып килде миңа тик кенә.

Атылып та килде, ябышты да,
Теткәли бит чалбар балагын.
Тарта, ерта, ырылдап та ала,
Туктатмастан мине талавын.

Йомшак кына дәшәм моңа шулчак,
Тукта, мәйтәм, син, эт баласы.
Теткәләмә  ыштанымны, мәйтәм,
Кунакка бит минем барасы.

Бүтән кешеләр дә бар ич, мәйтәм,
Ябырылдың миңа нахакка.
Башкаларга өрмәдең дә, мәйтәм,
Үзең уйлап кара шул хакта.

Сиңа һичбер зыян иткәнем юк,
Каршы бит бер сүз дә әйтмәдем.
Без таныш та түгел икәү, мәйтәм,
Тату  булыйк, дип тә өстәдем.

Ә эт тыңламый да, элеккечә
Үз эше - эш, һаман талаша.
Китәргә дә миңа ирек бирми,
Аягымны тешләп маташа.

Көч-хәл белән эттән ычкындым мин,
Кәефләрем тәмам бозылды.
Кояшы да кырын карый сыман,
Көн дә ямьсез кебек тоелды.

Кайтып киттем кире өйгә табан,
Бер уй килде кинәт башыма:
Кайберәүләр шул дуамал эттәй
Килеп чыга бит нәкъ каршыңа.

Ябыша да шулай бер сәбәпсез,
Теткәли ул йомшак күңелең.
Гүя син бурычлы исбатларга
Инсан син, ә дөя түгелең.

Бу дөньяда кеше төрле-төрле,
Яхшысы бар аның, яманы.
Бигрәк кыен, әгәр очрап калса
Ахмак эткә охшап торганы.

## Камали үгетләре

Юк, Мәчтүрә, синдәй кызга
Тач миндәй егет кирәк.
Загысына барыйк әле,
Язылып кайтыйк тизрәк.

Син мине мут дисең инде,
Шул чаклы мут түгел мин.
Һәрбер кыз алдында эреп
Савытымнан түгелмим.

Шәмсебикә сөйгән дисең,
Булды Шәмсебикәсе,
Ник сөймәсен Ходайның бер
Миндәй кашка тәкәсен!

Газизәсе, Җәмиләсе
Булды тик ялгыш кына,
Алар белән сөешкәнем
Бик аз, ярты кыш кына.

Биш-алтысын әйтеп тормыйм,
Әллә кайчан үткән хәл.
Шулар артыннан йөгереп
Үткән гомерләрем жәл.

Гөлбанудан көнләшәсең,
Менә чибәр ичмасам!
Аңа бар егет гашыйктыр,
Әгәр сукыр булмаса.

Юк, юк, Мәчтүрәкәй, син дә
Киптергән балык түгел,
Көрәйтелгән тана сыман,
Шуңа ашкына күңел.

Көнләшмә инде,
Башкалар
Бер дә сиңа тиң түгел,
Синең бер кашың гына да
Чабатадан ким түгел!

Эшләгән эшең дә бик шәп,
Үзе бигрәк төшемле.
Эттән ач, беттән ялангач
Яшәмәбез шикелле.

Загысына барыйк хәзер,
Язып бирик  гариза.
Әткәңнең зур фатирында
Яшәргә мин  бик риза.

Ә мутлык ул, Мәчтүрәкәй,
Азрак булыр, пожали.
Чамасыннан узып китсә,
Исемем булмас Камали!

## Буа буарлык

Ярый, килсәң өйләнергә диеп,
Бездә кәләш буа буарлык,
Уңган, эшчән, менә дигән чибәр,
Күрсәң, акылыңны җуярлык.

Блондинкасы, шатенкасы дисәң,
Күпме кирәк, шунча табылыр.
Дөнья тулы сылу брюнеткалар,
Йөрәгеңә утлар кабыныр.

Ак каендай зифа әллә күпме,
Ошатсаң, бар аз-маз түгәрәк;
Озын буйлы гүзәлләр дә бездә,
Теләсәң, бар бераз тәбәнәк.

Ходаема шөкер, кызларыбыз
Саф йөрәкле, камил акыллы.
Ә син, егет, үзең нинди кеше?
Әйтик, характерың алтынмы;
Җитмеш төрле һөнәр беләсеңме,
Кулыңнан бар эш тә киләме,
Әллә берәр акыл иясеме,
Шуңа даның дөнья күләмле?

Шул сыйфатлар берсе дә юк, диген,
Алай икән...
Юк шул, эш пешмәс.
Акыллы кыз берәр булдыксызны
Үз гаиләсенә баш итмәс.

Юкка гына, егет, күңел белән
Синең паратларны тугардык.
Синең кебек ялкау, җебек буйдак
Үзебездә буа буарлык.

## Артистлар

Бик күп артист килгән, имеш,
Кәмит куеп яталар.
Берсеннән дә берсе оста,
Болар ләчтит саталар.

Берсе әйтә:
Менә мин, ди,
Алып китсәм сезне, ди,
Иртәгә үк оҗмахларга
Кертәм үзегезне, ди.

Икенчесе:
Бергә барыйк,
Бөтен өмет миндә, ди,
Минем кебек тәҗрибәле
Кеше юктыр җирдә, ди.

Тагын берәү:
Астын өскә
Китерәм, ди, дөньяны.
Сизми дә калырсыз әле
Ничек рәхәт булганын.
Ачлык җилекне суыра,
Дигән сүзгә ышанма;
Илдә чыпчык үлмәс, чыда
Минем, ди, ни кушканга.

Чыга бүтән,
Туры юлны
Мин генә беләм, диеп,
Үзем иң алдан барам, ди,
Кызыл күлмәгем киеп.

Берсе:
Акрын барырбыз, ди,
Чамалап, иплəп кенə.
Икенчесе:
Йөгерик, ди,
Йə атлыйк шəп-шəп кенə.

Бəхəслəшеп тə китəлəр
Үзара бераз шунда.
Бүлешəлəр, кем утырыр,
Нинди җылы урында.

Валлаһилар, биллəһилəр
Ике сүзнең берендə.
Никтер кəмит бер мəгънəсез,
Тозсыз кебек күренде.

Кырт уяндым.
Йоклаганмын
Телевизор алдында.
Артист түгел, кандидатлар
Торган икəн каршымда.

Шулар икəн чиратлашып
Оҗмах вəгъдə итүче.
Берсенə дə ышаныч юк.
Сүндерим дə, китимче.

## Уены бар,  чыны бар

Исмәгыйль ул бик шук кеше,
Уены-чыны бергә.
Телен тыймый, сөйләп бирә
Ни теләсә әйтергә.

Көннәрдән бер көн  мактанып
Кордашлары каршында,
Исмәгыйль бик күп сөйләде
Хатын-кызлар хакында.

Тегендә дә, монда да бар,
Имеш, сөяркәләре,
Гүр кызларыннан ким түгел
Назлары, иркәләве.

Бигрәк кызып киткән чакта
Хатирәләр кичәсе
Исмәгыйлем шып туктады,
Монда икән бичәсе!...

Нинди давыллар узгандыр
Өйләренең эчендә,
Исмәгыйль күренмәс булды
Иртәсен дә, кичен дә.

Шуннан бирле Исмәгыйльдә
Тирә-юньгә игътибар,
Сүзе саллы.
Ни дисәң дә,
Уены бар, чыны бар.
Шаяруың  -шаяру ла,
Кыен шул аңлатулар.

## Җиңги бераз ялгышкан

Өйләнергә уйладым бит
Чибәрнең чибәренә.
Болай итәм, тегеләй итәм,
Карамый чибәр генә.
Уйламыйм ниләр генә!

Берничек тә юлын тапмыйм
Үземә каратырга.
Ярамыйм микәнни соң мин
Чибәрләр яратырга?

Иза чиктем.
Ярый әле,
Җиңги хәлемә керде.
Сихерчегә барам да мин,
Рәтлим бу эшне, диде.

Ул юнәлтер чибәреңне
Нәкъ сине, ди, сөяргә,
Күрерсең, ди, тиздән бу кыз
Сиңа чыгар кияүгә.

Сихерчегә мактап мине,
Чөеп күкләргә кадәр,
Кайтты җиңги.
Тиз арада
Ишетелде бер хәбәр.

Чибәр вәгъдә биргән икән
Бер гармунчы егеткә.
Җырчы, сабантуй батыры,
Нәкъ әзмәвер кебеккә.

Җиңги мине мактаганда
Бик арттырып тырышкан.
Минем исememне генә
Әйтмәгән шул, оныткан.
Чибәремнән колак кактым
Менә тульке шунлыктан!

## Чибәркәй

Кайттым мәллә яшьлегемә,
Әллә шашам акылдан:
Яшьли өзелеп сөйгән ярым
Үтеп бара алдымнан.

Элеккедәй зифа буйлы,
Кояш нуры йөзендә.
Юктыр артта үткән гомер,
Юкка чыгам үзем дә.

Кыйгач кашлар, серле күзләр,
Кара бөдрә чәчләре
Кинәт ут кабызды.
Дөрли
Күптән сүнгән дәртләрем.

Телемне дә йоттым бугай,
Өнемме бу, төшемме?
«Кайдан син,Тәнзиләм, -дидем,-
Әллә күктән төштеңме?»

Шып туктады бит чибәрем,
«Ялгышасыз, бабай, -ди,-
Минем әбием Тәнзилә,
Буталмагыз алай»,- ди.

«Кичерегез, бик ашыгам,
Мин,- ди,- озак торалмам
Сөйләп бусын-тегесен;
Көтеп тора бик түземсез
Мине сөйгән егетем».

Китте чибәр, очраштылар,
Шунда күрдем кызыгын:
Кызны кочып үпкән егет,
Баксаң, минем оныгым!

## Чегән кызы

Кешеләргә бәхет юрарга
Чегән кызы чыккан урамга.

Кызыл зур чәчәкле күлмәге
Төсле сәдәп белән каптырган.
Итәкләре урам себерә,
Өстерәлеп бара артыннан.
Алкалары, күпме йөзекләр,
Беләзекләр алтын- көмештән.
Кара бөдрә чәч, чем- кара күз
Чегән кызына бик килешкән.

Очраган бар белән сөйләшә,
Уч тотырып бәхет өләшә.

Бөтен дөнья малы бу кызда,
Кулында бар сыман әллә ни.
Һәркемгә дә бирә тотырып,
Бәхет өләшә ул җәлләми.
Сәламәтлек, байлык, мәхәббәт-
Белә кемгә, нәрсә кирәген.
Әллә ачаламы һәркемнең
Бар хисләрен, йөрәк серләрен?

Барысының белә язмышын,
Ни күрәсен, ниләр кылмышын.

Кайчак ялгышкандай була ул,
Туры килми әйткән сүзләре.
Исләре дә китми андыйга,
Төзәтәләр аны үзләре.
Киләчәккә баглап өметләр,
Ышаналар чегән кызына.
Канатланып китә кешеләр,
Никтер канатсыз күк кыз гына.

Бу юмарт  кыз кемгә пар икән,
Үзендә дә бәхет бар микән ?

### Сиңа кем кирәк тагын?

Чибәр кызга күзем төште,
Ул миңа карамады.
Туктале син, ашыкмале,
Кай җирем ярамады?

Мин кемнән ким?
Карап торсаң,
Менә дигән егет мин.
Такталарга элә торган
Бер плакат кебекмен.

Акыллым син, матурым дип,
Назлый мине әнкәем.
Ана булгач, ялгыш әйтмәс,
Беләдер  бит бәбкәен.

Минем куе чәчләремә
Күпме кызлар соклана!
Менә күзләрем дә, бәлки,
Исләрендә саклана.

Мин сөярлек түгелмени,
Буйчан үзем, мәһабәт.
Текәлеп бер генә кара,
Тоярсың чын мәхәббәт.

Аз-маз кимчелек тә бар ул:
Колак тырпаеп тора;
Борын ялпәк, авыз бик зур,
Тешләр ыржаеп тора;
Аякларым алпан-тилпән
Атлар өчен яралган;
Күзләр чекерәеп тора,
Зиһен бераз таралган.

Ялкаулык та бар бугай шул,
Бик яратмыйм күп эшне.
Чокынсаң ни, кимчелекләр
Табылыр ул, кәнишне.

Андый якларга карама,
Үзара аңлашырбыз.
Вак-төякне күп уйлама,
Бик тиз яратышырбыз.

Бүтән егет эзләмә дә,
Монда кара, аппагым.
Яныңда мин басып торам,
Сиңа кем кирәк тагын?

Эчтән сөйлим моны кызга,
Борылып та карамый.
Үзенә тиң егет эзли,
Сайлый, һаман аралый.

Бу якка сал күз карашың,
Монда мин дә бар әле.
Китмәле син  болай гына,
Миңа да бер карале!

## Татар мунчасы

Эх, татарның мунчасы,
Борынгылар мирасы.
Кунакка мунча ягу-
Татарларның йоласы.

Кызу татар мунчасы,
Шартлатып чабынасы,
Юынасы, коенасы,
Юк  аны онытасым!

Татарның шул мунчасы
Көн дә яккан булсачы.
Тирләреңне түгәргә
Әзер генә торсачы.
Эх татарның мунчасы
Көн дә әзер булсачы!

## Әби буламыни?

Кызыл трамвай, пассажирлар  шыгрым тулы.
Кысылган бер карчык, сизми аяк-кулын.
Калмаган тын алыр хәле, мескен карчык,
Ни алга китәргә юл юк, ни артка юк.

Яшьләр шаяра, бер-берсен этеп-төртеп,
Ялвара боларга карчык, түзем бетеп:
«И балалар, тик торыгыз, туктагыз,-ди,-
Башкаларны шул кадәрле кысмагыз»,-ди.

Бер мәһабәт чибәр егет менә шунда
Иптәшләрен кысырыклый анда-монда:
«Егетләр,-ди,-әйдә  читкә тайпылыгыз,
Әби карчыкка бер урын тиз табыгыз».

Көтмәгәндә  генә  карчык үпкәләде,
Яшь егеткә күзен текәп, болай диде:
«Нигә әле хатын-кызны кимсетәсең,
Нигә оялмыйча «Әби»,  дип әйтәсең?
Яше бераз олыгайса,  олыгайсын,
Әби  буламыни инде, ул сүз калсын.
Олыракмын,-ди,-тик «Әби» нишләп инде?!»
Трамвай тулы халык,
Кәеф бик шәп иде.

## Ирлек хикмәте

Сәмигулла агай ава-түнә
Кайтып җитте ихатасына.
Шактый күп төшереп алган, ахры,
Туры китте карчык каршына.

Авар-аумас кына торса да ул,
Ир кеше бит, дөнья тетрәтә.
Карчыгына гүя кан дошманы,
Ачы телләп очкын чәчрәтә.

Эттән алып этка салып аны,
Син, ди, миңа коллык чылбыры;
Үзеңә бер кара, тефү, шыксыз,
Ник дәшмисең, шайтан алгыры?

Мин, ди, иләс-миләс бәндә түгел,
Башка яшәмәм, ди, тинтерәп.
Чыдам бетте, көрчегемә җиттем,
Килә яшисем, ди, типтереп.

Баш әйләнү бераз тынган чакта
Карчыгына ныклап караса,
Котсыз калды Сәмигулла агай:
Бу - карачкы икән ләбаса!

Ул бакчада әтәчләнгән икән.
Ярый әле, Ходай саклады-
Моны карчык күреп калмады...
Сәмигулла агай башын иеп,
Акрын гына өйгә атлады.

## Өйләнергә уйладым

Кырык яшьне  узып барам,
Әле буйдак мин пока.
Өйләнергә вакыт, ахры,
Сайланып йөрмәм башка.

Бер яшь чибәр табылса ни,
Булдыклы, тырыш, уңган,
Бик  ягымлы, кайгыртучан,
Миңа шул җитеп узган.

Иртүк торып өй караса,
Эшенә  дә өлгерсә,
Миңа тагын  нәрсә кирәк,
Балаларны үстерсә.

Гүзәллеген, тыныч холкын
Гомергә саклап торса,
Уйламыйча да өйләнәм,
Бүген,  Алла боерса.

Тик нигәдер яшь чибәрләр
Миңа кырын карыйлар.
Миндәй төпле ирне түгел,
Яшь-җилкенчәк сайлыйлар.
Белмим инде, әллә кызлар
Сөю хисе тоймыйлар.

Өйләнергә уйладым,
Шул уемны куймамын.

## Автобуста

Автобуска кергән идем,
Автобус шыгрым тулы.
Минем йөрер юлларымда
Боларның да бар юлы.

Күзем төште бер чибәргә,
Хатын дисәң, вәт хатын!
Колакларда ялт-йолт гәүһәр,
Бармакларында алтын.

Чем-карадыр бөдрә чәчләр,
Күзләрдә уйный ялкын.
Үзенә карата бит бу
Автобусның бар халкын.

Гашыйк булам бугай инде
Тулы иреннәренә.
Сокланам киемнәренә,
Хушбуе исләренә.

Мәгърүр йөзе.
Беләдер шул
Чибәрлеге турында.
Бер үзе генә утырган
Иркенләп киң урынга.

Бер егет тә җөрьәт итми,
Мин дә барып утырмам.
Эх, мне б такую, диеп,
Тик эчтән жырлап торам.

Шушы гүзәл манзараны
Бозды- куйды бер карчык.
Таяклы, ә кулларында
Турсыкмы, әллә капчык.

Урын табалмагандыр шул,
Кыендыр басып тору.
Ни дисәң дә, карт аякка
Зарур тизрәк утыру.

Кыяр- кыймас кына килеп,
Утырмак булган иде,
Капчыгын да утыргычка
Сак кына куйган иде.

Чибәремә ниләр булды?
Үрле- кырлы сикерде,
Мескен карчыкка акаеп
Зәһәрләнеп җикерде.

Карчыкның исе әшәке,
Үзе дә ифлас, имеш.
Нишли кеше арасында
Картаеп беткән килеш?

Эт тә җыймас
Бу хатынның
Авызыннан чыкканын.
Чиелдавы үзәкләргә
Үтеп керә бит тагын.

Карчык бер ни әйтәлмәде,
Күзенә яшь тыгылды.
Капчыгын алды,
Чак атлап
Артка таба борылды.

Карап торам, кая китте
Мин сокланган яшь хатын?
Кайда аның гүзәллеге,
Күздәге иркә ялкын?

Алтын- гәүһәре бер тиен,
Үзе тормый тиен дә.
Пычрак телне төргәннәр бит
Ялгыш матур киемгә.

Бер борылып карамам да
Шушы кабәхәт җанга.
Мондый түгел,
Күркәм хатын
Тулы безнең җиһанда.

Бик бәхетсез булса, очрар
Ир- ат мондый хатынга.
Ходай җибәрмәсен сине
Мондыйларга якын да!

## Вокзал

Вокзал шыгрым тулы икән,
Шул кадәр күп кешеләр.
Яше дә бар, карты да бар,
Шунда минем ишеләр.

Кайберләре бигрәк юан,
Кайберсе нечкә , ябык.
Берсе килә, берсе китә,
Агылып тора  халык.

Төртешеп кереп китәләр,
Юк беркемгә  игътибар.
Менә мин кунакка барам,
Боларның ни эше бар?
Нишләп йөри соң болар?

## Очрашу

Яшь идем шул, гашыйк булдым
Мин бер чибәргә.
Үзәкләрем өзелүгә
Ничек түзәргә?

Зифа буе, көләч йөзе,
Серле  күзләре,
Акылларымнан яздыра
Әйткән сүзләре.

Шома гына атлап китә,
Калам тын гына.
Очып кына барыр идем
Аның янына.

Ал чәчәкләр җәяр идем
Йөргән юлына.
Тик ул игътибар да итми
Сөю колына.

Сөйгәнемә күңелемне
Ачып салмадым.
Мәхәббәтемне сөйләргә
Аңа базмадым.

Бераздан аерды безне
Язмыш юллары.
Еракларда үтте минем
Гомерем еллары...

Яшьлегемне сагынып кайттым
Туган җиремә,
Үз илемнең төтене дә
Татлы күренә.

Авылымны айкап чыктым,
Кат-кат урадым
Сагыш катнаш шатлык белән
Авыл урамын.

Урамда бер ябык кына
Карчык очрады.
Сәлам биреп, ул текәлеп
Миңа карады.

Мин дә карыйм.
Бу карчыкның
Сүнгән күзләре,
Тирән җыерчыклар тулы
Аның йөзләре.

Нигә соң бу карчык миңа
Бик таныш сыман?
Өнемме бу, төшемме, дип,
Мин карап торам.

Бу бит минем яшьли сөйгән
Гүзәлем икән!
Үткән еллар бигрәк шулай
Аяусыз микән?

Кайда югалган соң аның
Зифа буйлары,
Кайда калган  күзләренең
Серле нурлары?

Каушаганнан сүзсез калып,
Йөгердем өйгә.
Тизрәк барып  карадым мин
Бер зур көзгегә.

Көзгедә бер ябык чал карт
Аптырап тора,
Сирәк-мирәк калган чәчләр
Тырпаеп тора.

Йөзләрендә җыерчыклар
Торадыр тулып,
Бөкерәеп басып тора
Бичара булып...

Яшьлек үтми, диюләре
Ялган икән шул,
Яшьлегем тик җырда гына
Калган икән шул.

Яшьлегемне сагынганда
Төшә исемә
Гүзәл бер кыз һәм кыюсыз
Яшь егет кенә.

## Елмаясың

Ник елмаеп карыйсың,
Әллә мине таныйсың?
Яшьлек хисен уятасың,
Киләсиңа ярыйсым.

Әй чибәр кыз, алай миңа
Бик елмаеп карама.
Син елмаеп караганда
Зиһеннәрем тарала.

## *ТАҺИР БАБАЙ*

### Авылымның Хуҗа Насретдины

Безнең авылда бар иде
Данлыклы бер Таһир бабай,
Әле дә хәтерлим,
Шулчак
Мин бер җебек борын малай.

Булмаса да гомер буе
Авылыннан чыгып йөргән,
Таһир бабай сүзгә
Бигрәк
Оста кеше, күпне белгән.

Кесәгә сүз эзләп кермәс
Авылыбыз кешеләре,
Тапкыр телле.
Тик күп булмас
Таһир бабай ишеләре.

Хәзер авыл бик үзгәргән,
Шул бабайлар инде юклар,
Башка буын яши монда –
Өсте бөтен, тамак туклар.

Ходаема шөкер,
Болар
Ачлык-кытлык күрми үскән,
Кәлҗемәне белмиләр дә,
Онытылган ул да күптән.

Бәп-бәләкәй, сеңгән иде
Җиргә Таһир бабай өе,
Хәзер шунда сарай тора,
Эшләпәсен күккә чөеп.

Никтер менә тыкырыктан
Күренер күк Таһир бабай,
Күтәренке күңел белән,
Кызык сүзгә һаман да бай.

Менә хәзер авылымның
Хуҗа Насретдины тагын
Хәсрәтләрне таратыр күк,
Кирәкле җор сүзләр табып.

Сагынганга авылымның
Халкын, аш-су, икмәкләрен,
Сөйлим әле сезгә дә мин
Таһир бабай хикмәтләрен.

**Аучы**

Күз алдымда Таһир бабай,
Сикереп атлап йөрүе,
Ышанмаслык сүзләрен дә
Чынлап сөйләп бирүе.

Бабай аучы,
Маэмае бар.
Ау эте булмаса да,
Урманда йөрергә иптәш,
Бүреләр кумаса да.

Ханнар заманыннан калган
Мылтык бабай кулында.
Шуны тотып көннәр буе
Йөри урман, болында.

Урмандагы аюларны
Кеше күптән корыткан.
Болан, поши ишеләрне
Урман үзе оныткан.

Ләкин бабай һаман йөри,
Авылда бер аучы бит.
Үрчеп киткән бүреләрдән
Авылны саклаучы бит.

Сирәк кенә кайта аучы
Куян асып биленә.
Мондый чакта бабай горур,
Бар авылга күренә.

Бәйнә-бәйнә сөйли
Кайда,
Ничә куян күргәнен,
Иң симезен сайлаганын,
Куян куып йөргәнен.

Ә гадәттә Таһир бабай
Аудан кайта буш кулы.
Тик анда да сер бирми ул:
«Атмадым, -ди,- бу юлы.

Куян унбер иде, атмыйм
Уникегә тулганчы.
Тимәдем мин, үссеннәр, дим,
Бозау хәтле булганчы.

Киләсе ел мин куяннның
Бер иң зурын атырмын.
Бар авылны ашатырлык
Итен алып кайтырмын».

Таһир бабайның сүзләре
Бала-чагага  ошый.
Күңелендә  куян итен
Авыз тутырып ашый.

### Балыкчы

Таһир бабай балык тота,
Маэмае да янында.
Көннәр буе утыра ул,
Авыл күле ярында.

Тал чыбыктан кармак сабы,
Үзе ясый кармагын.
Тимерчыбыкны  бөккәчтен
Игәүлисе  бар тагын.

Җәтмә белән тотар иде,
Юк бит җәтмәсе генә.
Аның бәясе нихәтле,
Җиңел әйтәсе генә.

Балык тотарга бабайның
Мурдалары да була.
Ләкин балык никтер керми,
Бакалар кереп тула.

Сирәк-мирәк  вак-төяк көс
Бабай тотып кайткалый.
Мондыйны мин ашамыйм, ди,
Песигә бу да ярый.

Балыксыз гына кайтса да,
Сер бирми ул беркемгә.
Бүген менә тотмадым, ди,
Ял итәрмен бер көнгә.

Бер  зур шүкә эләкте, ди,
Анттыр, метрлык менә.
Алып кайтыйм микән, диеп,
Карап тордым  күзенә.

Ике якта акайганнар
Бәрәңгедәй шар күзе,
Авыз тулы очлы тешләр,
Койрыгын бәрә үзе.

Күлгә кире җибәрдем, ди,
Шүкә балыкмыни ул?
Безнең кебек балыкчыга
Шүкә тансыкмыни ул?

Таһир бабай авылдагы
Иң данлыклы балыкчы.
Әйдә,бабай,
Булса балык, булмаса да,
Тагын кармак салыйкчы!

## Ярты бакча кәлҗемә

Авыр еллар.
Язда бөтен авыл
Көрәк белән җирдә казына.
Гел бәрәңге бакчасында халык,
Гүя бар күмелгән хәзинә.

Юк, хәзинә чыкмый бакчаларда,
Алтын-көмеш түгел чыкканы.
Кышта туңган черек бәрәңге ул,
Кулга алырга да чирканыч.

Бәрәңгеләр алган чакта көзен
Ялгыш җирдә калган монысы.
Күренмичә кала вак-төяге,
Күренә бит эре, олысы.

Шул черектан пешерелгән көлчә
Кәлҗемә ул.
Шуны ашыйсың.
Ашарлык та түгел, ни эшлисең,
Нәрсә белән тамак ялгыйсың?

Кәлҗемәнең тәме, аның исе
Көне буе күңел болгата.
Тик бер Таһир бабай шат күңелле,
Көләч йөзле бабай гәп сата.

Менә, ди ул, кәлҗемәне әйтәм,
Бигрәк туклыклы шул ашамлык.
Тәмен аңлый белсәң, тәмле үзе,
Кәлҗемәне көн дә ашарлык.

Язын бакчабызда бәрәңгенең
Ялгыш калганнарын чүплибез.
Бик аз бит ул, диеп куя бабай,
Инде башка төрле эшлибез.

Көзләр җитсен әле, диеп өсти,
Ярты бакчама һич тимәм мин.
Бәрәңгесе калсын җир астында,
Черер инде, жәл бит, димәм мин.

Аның каравына, язлар җиткәч,
Әллә күпме булыр кәлҗемәм.
Җитәр рәхәтләнеп ашарга, ди,
Мин ачлыктан болай мәлҗемәм.

Белмим, калдырганмы Таһир бабай
Кәлҗемәгә ярты бакчасын.
Ләкин шаккатырып көлдерде ул
Шулай авыл халкын барчасын.

## Ашап кем туйган

Таһир бабай яшәгән чор
Безнең туган якларда
Туры килгән ачлы-туклы
Кырыс, кытлык чакларга.

Ашаганы алабута,
Бәрәңге, сыек умач.
Өйдә бәйрәм була инде,
Өстәлгә менсә токмач.

Ипие юк бер туярлык,
Бабай тәм-том күрмәгән.
Күпме төрле ризык барын
Ишетеп тә белмәгән.

Ач-ялангач яшәп, бабай
Килгән шундый карарга,
Беркайчан да булмыйдыр, дип,
Туйганчы бер ашарга.

Күпме халык,
Барсына да
Ничек җиткермәк кирәк?
Бөтенесе туйсын өчен
Нихәтле ипи кирәк?

Ул хәзер дә комар түгел,
Корсагым тулсын, димәс.
Бераз ашагач та, туктар,
Ризыкка бүтән тимәс.

Нигә, бабай, ашамыйсың
Туйганчы бер, дисәләр,
Җавап әзер.
Соңрак аны
Кабатлыйлар дистәләр.

Таһир бабай әйтеп сала:
«Ашап, кем туйган, дисең ?
Туеп, ашаудан туктамый
Бәндә.
Әллә белмисең ?

Туйганчы, диеп, ашама,
Туялмассың ашап син.
Ялыккач та, тукта.
Шуннан
Башкалар да ашасын.

Ризык аз, диеп зарланма,
Ялыкканчы җитә ул.
Ач карынны уйлама да,
Туймый торган нәстә ул».

## Мунча

Таһир бабай ярата
Мунчада юынырга,
Каен миллеге белән
Эсседә чабынырга.

Эш ашыгыч булса да,
Озак ята мунчада.
Тир атылып чыкканчы,
Пар аяктан екканчы.

Бүрек кия башына,
Эссе сала ташына.
Ләүкәсендә утыра,
Тирләре ага тора.

Бер ятып, бер утырып,
Ике рәт тир катырып,
Ике- өч кат чабынгач,
Кайта, чәен сагынгач.

Беркөн тиз-тиз мунчадан
Кайткан,
Күп тә булмаган.
Өйгә кереп утырган,
Чәй эчәргә тотынган.

Өйдәгеләр шаккаткан,
Ни булган, дип баш ваткан.
Сорыйлар
Ник бик тиз, дип,
Чабынгансың җитез, дип.

Бабай сәбәбен белә,
Эченнән генә көлә.
Ничек соң чабынасы,
Ягылмаса мунчасы!

Таһир бабай сер бирмәс,
Өрә-өрә чәй эчә.
Үзе сөйли
«Ягылган
Мунча бик эссе кичә.

Әле дә эссе.
Чабындым.
Тик җил өрә тыштанмы?
Шуңа салып тормадым
Чабата һәм ыштанны».

Өстәп куя ахырда,
Чәй эчүдән туктагач:
«Мунча керү озакмы,
Шунда бер чишенәсе,
Киенәсе булмагач».

## Киндер күлмәк

Таһир исемле бер малай
Киндер күлмәк киеп үскән.
Киндер күлмәк, киндер ыштан,
Тагын киндер кием өстән.

Туктап тору юк хәяттә,
Ел артыннан еллар үткән.
Җәен-кышын шул бер кием,
Егетебез үсеп җиткән.
Аягында киндер чолгау,
Киндер күлмәк -ыштан киеп,
Таһир кызлар сайлап йөри,
Үзенә тиңнәрен сөеп.

Өйләнгән ул, ата булган,
Балалары үсеп килә,
Әти -әниләре кебек
Киндер кием киеп кенә.

Шулай үткән озын гомер,
Уллар киткән калаларга.
Сирәк-мирәк кайткалыйлар
Монда,
Ата-аналарга.

Олы улы беренче рәт
Яшь кәләше белән кайткан.
Шул киленнең киемнәре
Пөхтә, бик кыйммәтле заттан.

Нечкә билле, зифа буйлы
Килен матур күлмәк кигән.
Кыска җиңле җиңел күлмәк
Аңа бик килешкән икән.

Таһир бабай әйткән имеш:
«Килен, ярый, чибәр икән.
Тик   күлмәге бигрәк юка,
Кыш суыкта нишләр икән?

Материал җитмәгәндер
Җиңнәренә, итәгенә.
Үтә күренмәле үзе,
Киндергә ни җитә менә.

Җылы, җайлы озын була,
Ник кимәгән киндер күлмәк?»
...
Шөкер инде, Таһир бабай,
Киндер чоры үткән, димәк.

## ШӘХЕСЛӘР

*Шушы бүлектә китерелгән мәкаләләр Казакъстанда яшәүче татарларны халкыбызның хәзерге заман әдипләре иҗаты белән якынрак таныштыру максаты белән язылган иде. Алар барысы да, берсеннән гайре, Татарстанда һәм Башкортостанда яшәүче атаклы татар әдипләре иҗатына багышланган; Алматыда, Астанада чыгып килгән «Фикер» гәзите битләрендә басылган. Мәкаләләрнең берсе Алматыда яшәүче шагыйрь Равил Гозаиров иҗатына багышланган; бу мәкалә аның «Шул бәхет миңа җитә» (Казан, 2014 ел) дигән китабында басылып чыкты.*

### Рабит Батулла

Рабит Батулла (Роберт Мухлисович Батуллин) 1938-елда Татарстанның Зәй районы Түбән Олоҗы авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Урта мәктәпне, аннары Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесын, Бөтенсоюз театр институтының режиссерлар курсын, Әдәби институт янындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый. Казанда курчак театрының һәм телевидениенең режиссеры, Камал театрының актеры булып эшли, әдәби иҗат белән шөгыльләнә.

Рабит Батулла драматургиягә курчак театрлары өчен язылган әсәрләре белән килеп керә. Аның «Төш вакытындагы могҗиза», «Курай уйный бер малай», «Тылсымчы белән сихерче» һ.б. ш. пьесалары киң тарала, Казан, Донецк, Саратов, Кемерово, Барнаул курчак театрлары сәхнәләрендә куела.

«Кичер мине, әнкәй!», «Өчәү юлга чыктык», «Туйлар узгач», «Сират күпере», «Мин Америка ачтым» һ.б. ш. драма әсәрләре тамашачы тарафыннан яратып кабул

итеlə. Казан, Омск, Салават, Махачкала һәм Рәсәйнең башка байтак шәһәрләренең театрларында аның драматик әсәрләре зур уңыш белән тамашачылар игътибарына җиткерелә.

Рабит Батулланың публицистик әсәрләре-укучыларның, чыгышлары- тыңлаучыларның ихлас игътибарын җәлеп итә. Милләтчелек мәсьәләләренә караган аның фикерләренә кушылмаган кешеләр табылыр микән «олы агай» исәбенә кермәгән милләт вәкилләре арасында? «Минемчә, милләтчелек- ул милли һәм социаль басымга каршы протест,- ди Рабит Батулла.- Шовинистлар басымына каршы, милли гаделсезлеккә каршы. Аерым алган һәрбер милләтчелектә милләтнең үзбилгеләүгә омтылышы бар, ә үзенең искиткеч аермачылыгына, башкалардан югарылыгын исбатлауга омтылышы түгел». Татар халкының танылган улларына «милләтче» дигән исем тагып, юкка чыгаруларын ачынып күрсәтә ул. «Мин горурланып үземне милләтче димен! - Һәрбер халык баласы да милләтче булырга тиеш, ягъни үз халкының гасырлар буенча килгән традицияләрен дәвам итүче, гореф-гадәтләрен саклаучы булырга тиеш. Бу начармыни? Башкалар өчен зыянлымыни? Мин-милләтче, ләкин трамвайда мин аңламаган телдә сөйләшүчеләргә беркайчан да шелтә ясамам. Ә татарлар шундый шелтәгә адым саен очрый. Мин- милләтче, ләкин мин беркайчан да башка милләтләрнең мәктәпләрен бернинди сылтау белән дә япмам... Мин татар милләтчесе, ләкин беркайчан да урыстагыдан күбрәк хокукны үземә таләп итмәм. Миннән тартып алынган хокукларны гына кайтарасым килә».

Совет хакимиятенең Кырым татарларына, чеченнарга һәм башка халыкларга карата кылган эшләрен Рабит Батулла шовинизм дип бәяли, Россия хакимияте мондый

халыклардан гафу үтенергә тиеш икәнлеген ассызыклый. Фашистлар яулап алган СССР территориясендә полицайлар тулысынча диярлек урыслардан, украиннардан, белоруслардан торганын, С.Бандера тарафдарлары Совет Армиясенә каршы сугышканнарын искә төшереп, Рабит Батулла: «*Ләкин без бу халыкларны хаин димибез, аларны туган илләреннән кумыйбыз*»,- ди. Шулай булгач, нигә инде башка халыклар гаепле дә, хаин да, сатлык җан икән?

Татар халкына карата күрсәтелгән гаделсезлекләргә дә йөрәге әрни язучының. Әрнер дә шул, безнең ата-бабаларыбызны көчләп чукындыруларына, аларны мәҗбүри урыслаштыру сәясәте үткәрүләренә, Казан паркы капкаларына «Этләргә һәм татарларга паркта йөрергә рөхсәт ителми» дип язып куюларына, татар мәктәпләрен ябуларына күп тә үтмәде бит! Алай гынамыни, үзебезнең күз алдында безгә, татарларга, үзебез теләгәнчә язу әлифбасын сайлауны тыймадылармыни?! Үз халкының язмышын кайгырткан кеше мондый күренешләргә битараф булалмый, әлбәттә. Рабит Батулла да шулай. Мондый күренешләр турындагы үзенең карашын ул турыдын-туры, ачык әйтеп бирә.

Тарихи проза Рабит Батулланың иҗатында аерым урын алып тора. Бу әсәрләре аны чын милләтпәрвәр, туган халкының язмышы өчен җаны әрнегән татар баласы итеп сыйфатлый. Татарларның 1552-елдагы фаҗигадан соң көчәйгән милли-азатлык көрәшен тасвирлаган «Мортаза» исемле хикәя, Габдулла Тукайга багышланган «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» исемендәге повесть, татар мәдәнияте әһелләренең эшчәнлеген тасвирлаган күпсанлы хикәяләр һәм мәкаләләр моны дәлилли. «Кылдан нечкә, кылычтан үткен» әсәрен автор тарихи хикәя рәтендә «кыйсса» дип атаган. Батулланың «Апуш-

Тукай» романы Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» исемендәге автобиографик әсәре нигезендә язылган.

«Сөембикә» исемендәге тарихи романны яза башлаганчы Рабит Батулла тарихны, шул чордагы вакыйгаларны җентекләп өйрәнгән. Романда тасвирланган вакыйгалар Сөембикәнең туган җирләре- нугай далаларында, я ханлык башкаласы Казанда, я Мәскәүдә, я тагын башка урыннарда бара. Бу урыннарның һәрберсен дә автор шул чактагы күренешләре, шундагы хәлләр аша күрсәтә. Рабит Батулла шул чордагы Казан ханлыгының дөньядагы ролен, Мәскәүгә, Төркиягә, Кырымга йогынтысын ачып бирә. Сөембикә көчле шәхес, дипломат, халык мәнфәгатьләрен яклаучы сыйфатында сурәтләнгән. Сөембикәнең Сафагәрәй кабере алдындагы елау эпизодын укыганда дулкынланмаган, йөрәге сыкрамаган татар табылмас.

Рабит Батулланың иҗатында ислам дине зур бер урын биләп тора. Монда, беренче нәүбәттә, аның «КОРЪӘН аятьләренең татарча мәгънәләре» исемендәге хезмәте турында әйтү кирәктер. «Коръән - ул могҗиза,- дип расный язучы.- Беренче кат укып чыккач, әлләни исем китмәде, гап-гади сүзләр, кайсылары аңлашылмый, сүзен аңласаң да, мәгънәсенә төшенеп булмый. Кат-кат укыдым. Сораулар арткannan-арта барды. Үз галимнәребез Ногманины, Иманколый китапларын, төрек профессорлары әзерләгән тәрҗемәләрне, тәфсирләрне, Америка, Лондон чыгарган, рус авторлары Крачковский, Порохова әзерләгән нөсхәләрне кат-кат укыдым». Шундый хәзерлек белән башланган тәрҗемә эше сокланырлык нәтиҗәгә алып килә. Бу нигезле хезмәт яңа өстәмәләр, төзәтүләр белән алтынчы мәртәбә басылды инде. Татарстан Җөмһүрияте мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакый шушы хезмәтнең

беренче басмасына ук түбәндәгечә югары бәя биргән иде: «Ана телебездә чыккан башка тәфсирләрдән нәрсәсе белән аерыла ул? Иң беренчесе: саф Ана телебездә укый алган һәр кеше аңларлык телдә язылуы белән. Икенчесе: Коръән аятьләренең мәгънәләре асыл нөсхәгә бик якын итеп язылуы белән. Өченчесе: киң аңлатмаларның мавыктыргыч итеп язылуы белән. Дүртенчесе: әдип китап ахырында күрсәткеч урнаштырган. Кайсы сүрәдә, кайсы аятьтә урнашканлыгына карап, укучы үзен кызыксындырган сорауларга җиңел генә җавап таба ала». Рабит Батулла үзе: «Ислам диненә мине әбием алып килде,- ди.- Эссе җәй көнендә рамазан аенда ул ураза тота иде. Ипинең валчыгы да, суның тамчысы да юк, ә ул көйдергеч кояш астында көнозын басуда эшли. Менә шул- Аллага ихлас инануның мисалы булды... Әбием миңа гарәп хәрефләрен һәм иң мөһим сүрәләрне өйрәтте».

Рабит Батулла татар теленең сафлыгын, нечкәлекләрен саклауга һәрвакыт игътибар итә. «Без инде ана теле дип өйрәнгәнбез, мәктәптәге уку әсбапларында да ул ана теле. Соңыннан татар теле дип, ә аннары - туган тел дип язу тәртипкә керде. Ләкин бу синонимнарны куллану уңай якка микән, әллә инде, киресенчәме? Мин туган тел димәс идем, ана теле дияр идем, чөнки барлык төрки телләрдә ул ана теле дип йөртелә, - ди ул.- Телне сакларга тырышабыз, ләкин телебез, шул исәптән рус теле дә «чүпләнә» башлады... Яшьләр арасында төрлесе - ана телендә матур итеп сөйләшүчеләр дә, телне чуарлап рус сүзләрен кыстыручылар да бар. Моны кайберәүләр тел байый дип кабул итә. Әгәр ул рәвешле «баетабыз» икән - тел бетә дигән сүз... Татар теле белән турыдан-туры эшгамәл кылучыларның теле саф булу шарт».

«Күк капусы ачылганда», «Рудольф Нуреев. Ватан белән саубуллашу» исемендәге фильмнәргә сценарий яз-

ган әдип тә Рабит Батулла. Татарстан телевидениесендә барган «Батулла дәресләре»нең авторы һәм алып баручысы да ул үзе. Бу тапшыруларда Батулла халкыбызның язмышы һәм тарихтагы роле турында, татар халкының күренекле уллары турында фикер йөртә. Сатира һәм юмор остасы, «Батулла мелла хикәятләре» исемендәге җыентык авторы да Рабит Батулла.

Рабит Батулланың иҗатына, аның иҗтимагый хезмәтенә югары бәя бирүчеләр аз түгел, һәм моңа ул чынлап та лаеклы. Мисал өчен Татарстан Премьер-министрының элеккеге урынбасары Зилә Вәлиеваның сүзләрен китерик. «Рабит Батулла берәүгә дә охшамавы, беркемне дә кабатламавы белән аерылып тора. Ул - тынгысыз кеше. Әдәбиятның төрле жанрларында үзен сынап караганнан соң, Батулла сценарийлар язуга кереште һәм ул татар киносы белән мавыга. Әгәр ул бу юнәлештә шулай даими рәвештә эшләп торса, безне дә канатландырса, һичшиксез, кино сәнгате үсеш алыр.

Батулла гел планнар белән яши. Әдәбиятта һәм мәдәнияттә ул янгын сүндерүче ролен уйный дип әйтер идем. Кайда нәрсә эшләнеп бетмәгән, кайда нәрсә җитешми, ул шунда ук күзенә чалынган проблеманы хәл итәргә омтыла. Балалар өчен әкиятләр кирәк булса - ул да әзер, сценарийлар юк икән, аларны яза башлый. Татар әдәбиятындагы, мәдәниятендәге олуг шәхесләр турында аның кебек тәфсилле итеп язган тагын кем бар икән?! Әйтергә кирәк, нәкъ менә аның язмалары аша без күренекле шәхесләр турында күбрәк мәгълүмат алуга ирешәбез. Бүгенге көндә дә Р.Батулла документлар җыю, аларны халыкка җиткерү белән мавыга, бу юнәлештә янып йөри. Шуның нәтиҗәсе буларак, күптән түгел аның китаплары да дөнья күрде. Татарда егет кешегә җитмеш һөнәр дә аз дигән мәкаль бар. Рабит Батулла исә

һөнәрләргә бай һәм ул үз эшчәнлеген нәкъ менә халкы өчен башкара. Киләчәктә дә сезгә иҗади уңышлар юлдаш булсын, тынгысызлык сезне ташламасын!»

Әйе, Рабит Батулла-чынлап та күпкырлы талант иясе, татар әдәбиятында үзенә лаек югары урынны биләп торучы шәхес. Татар халкы сәләтләргә бик бай шул ул. Бәлки шуның өчендәдер, үзенең күренекле шәхесләрен дә юньләп кайгырта белми; «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән үзенең әйтеменә дә исе китми. Атаклы улларын, кызларын аларның юбилейлары вакытында, яисә алар бу дөньядан киткәч кенә хәтеренә төшерә. Менә Рабит Батулла хакында да 2013-елда аңа 75 яшь тулу уңаеннан мәкаләләр басылган иде, ә быел юк, быел юбилей түгел ләбаса! Үзебезнең шундый шәхесләребезне һәрвакыт искә алырга, аларны үзләре исән вакытта югары күтәреп торырга берәр вакыт өйрәнербез микән? Үз балаларын данлый белмәгән милләт чит халык балаларының даны күләгәсендә, мескен хәлендә яшәргә дучар була бит ул.

Нәкъ шуларны искә алып, без дә атаклы шагыйрь һәм драматург, публицист һәм сатирик, балалар өчен хәзерләнгән әкиятләр һәм тапшырулар авторы, танылган язучы һәм сценарист, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Халык язучысы, Гаяз Исхакый исемендәге һәм Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге премияләре лауреаты Рабит Батуллага багышланган кечкенә мәкаләне Казакъстанда яшәүче милләттәшләребезгә тәкъдим итәргә уйладык. Гәрчә быел Рабит Батулланың юбилее булмаса да.

*«Фикер» гәзите №1( 82)2014 ел, Алматы.*

## Разил Вәлиев

Шагыйрь һәм прозаик, драматург һәм тәрҗемәче, танылган дәүләт эшлеклесе Разнл Вәлиев... Татар дөньясында бу шәхесне белмәгән кеше табылса да, бик аз булыр. Кырыктан артык китапларның авторы, татарлар яшәгән байтак төбәкләрдә булып, милләттәшләре белән йөзмә- йөз очрашып, сөйләшеп, аларның шатлыкларын да, хәсрәтләрен дә уртаклаша белгән кеше ул.

Разилнең чыгышына, язмышына, тормыш юлына күз салсаң, «Менә бит нинди тырышлык!»-диясе килә. Чынлап та, гади генә бер татар авылында ишле гаиләдә дөньяга килгән бу малай үзенең тырышлыгы, максатчанлыгы, үҗәтлеге аркасында әнә нинди биеклекләргә менәлгән ләбаса!

Разил Исмәгыйль улы Татарстанда, Түбән Кама районының Ташлык авылында 1947 елның 4 гыйнварында туган. Туган авылында башлангыч мәктәпне тәмамлагач, күрше Шәңгәлче авылының сигезьеллык мәктәбендә укуын дәвам иткән. Аннары Түбән Кама шәһәрендәге урта мәктәптә укый, ә 1965 елда ул- Казан дәүләт университетының журналистика бүлеге студенты. Аның бу университетка укырга керүе, шушы факультетны сайлавы очраклы гына түгел, әлбәттә. Мәктәптә укыган елларында ук Разил шигырьләр, хикәяләр яза башлый, район газеты каршында оештырылган әдәби берләшмәнең эшендә катнаша, газетта шигырьләре басыла.

Университетта ике генә ел укып өлгерә Разил. Аның сәләтлелеген сизеп, белеп алганнар инде, «Ходай Тәгалә Разилгә сәләтнең төрлесеннән дә мул биргән»,-дип академик Миркасыйм Госманов юкка гына әйтмәгән бит! Татар әдипләре Разил Вәлиевнең киләчәк язмышын бик дөрес билгелиләр: Татарстан Язучылар берлеге аны Мәскәүгә,

СССР Язучылар берлегенең М. Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга юллый. Менә шунда Разил үзенең әдәби осталыгын чарлый. Биш ел дәвамында шушы институтта укыган елларында Разил Вәлиев шигърият, проза, драматургия өлкәсендәге әсәрләре билгеле булган әдип тә, шигырьләр җыентыгының авторы да булырга өлгерә.

Әдәбият институтын тәмамлагач, Разил Казанга кайта, «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы сәркатип булып эшли. Ул үзенең әдәби хезмәтен тагын да җанландырып җибәрә, балалар өчен шигырьләр, проза әсәрләре иҗат итә, тәрҗемәләр белән дә шөгыльләнә башлый, яңа китаплары да чыга тора. Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең карары нигезендә Разил Вәлиев Чаллы шәһәрендәге Язучылар берлегенең җитәкчесе булып эшли. Дүрт ел эчендә шушы яңа Берлекне аякка бастырып, ныгытып, Разил яңадан Казанга кайта.

Казанда Разил Вәлиев Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәис урынбасары итеп сайлана, Татарстандагы иң төп китапханәнең- Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директоры булып эшли.

Разил Вәлиевнең җәмәгать эшләре белән кызыксынуы, халык мәнфәгатьләре өчен эшләргә һәвәслеге күптән билгеле. Аның милләтчелек хисе үсмер чагында ук формалашкандыр, мөгаен. Разилнең: «Түбән Камада мәктәптә укыганда, шәһәр малайларының, безне, авылдан күчкән малайларны, «татарва» дип мыскыллап, кыйнарга килүләрен күргәч, үз милләтем өчен ачыну хисе уянды», -дигән сүзләре шуңа дәлил дә була аладыр.

Рәзил Исмәгыйль улы Татарстанның Язучылар берлегендә актив эш алып бара. Татарстанда гына түгел, Рәсәйнең башка регионнарында да татар шигърияте, татар җыры кичәләре, татар әдәбияты атналыклары оештыруга ул күп көч сала. 1985 елның җәендә Ра-

зил ике ай дәвамында Әфганстанның байтак төбәкләрен әйләнеп чыга. Сугышка чумган шушы илгә ул үзенең милләттәшләрен, якташларын эзләп табу, аларның хәлен белү максаты белән бара. 1986 елда Разил Вәлиев әсирлеккә төшкән якташларыбызны, яраланган солдатларыбызны эзләп, Чечняга һәм Ингушетиягә юл тота. Госпитальләрдә, качакларның лагерьларында дарулар, азык-төлек тә тарата ул. Җыйнап алып кайткан мәгълүматларын республика халкының игътибарына тәкъдим итә.

Чаллыда эшләгән елларында ук Разил Вәлиев шәһәр советы депутаты булып сайлана. Быел исә Татарстан халкы аны алтынчы мәргәбә инде Татарстан Дәүләт Советына депутат итеп сайлаган. Разил Вәлиев- Дәүләт Советының Президиум әгъзасы, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе. Минтимер Шәймиев әйтүенчә, Разил Вәлиев «һәрвакыт бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып эшли, аның тормыш-көнкүрешен яхшырту турында кайгырта, туган мәдәниятебез, телебез, гореф- гадәтләребезне саклау һәм үстерү очен тырыша».

Шушы җәмәгать эшләренә карасаң, иҗат өчен аның вакыты да калмаска тиеш шикелле. Ләкин барысына да өлгерә бит! Авыл малае- авыл малае инде ул, кечкенәдән үк эшкә өйрәнеп үсә, бигрәк тә узган гасыр авылларында. Туган авылында яшәгәндә бу малай, башка кордашлары кебек үк, «киң профильле» хезмәткәр булыр үсә: кулына балта да, чалгы да, сәнәк тә, көрәк тә ябышып тора; атны да яхшы белә ул, авылдагы техника белән дә таныш. Шуңа күрә Разил бер төрле эштән курыкмый, эштән читкә тайпылмый да. Әнә студент елларында да Мәскәү автомобиль заводының тимерчелек цехында, тагын бер фабрикада кара эшче булып эшли, вокзалларда вагон бушатып та йөри. Болары да кулыннан килә бит!

Разил Вәлиевнең яңа әсәрләре, яңадан-яңа китаплары укучыларга барып житә тора. Карап торсаң, аның иҗаты күпкырлы, шул ук вакытта иҗатының төп юнәлеше- шигърият, дию дөрестер. Аның шигырьләре тирән фәлсәфи уй-фикергә бай, укучыны уйландыра торган әсәрләр. Мисал өчен, «Дисбе» исемендәге шигырьне карыйк. Шигырьнең эчтәлеге гади генә сыман: әбисенең дисбесе хакында сүз куерта автор. Әмма шул дисбегә бәйләп, әбисен искә алып, ул өч буынның язмышы турында фикер йөртә, һәркемгә дә иң кадерле булган гамәлләрне- өй салу, балалар үстерү, үз туган иледә гомер кичерүне- алга куя:

*Йорт салыгыз, уллар үстерегез,*
*Бәхет керсен, диден өйләргә...*
*Насыйп булсын, диден, туган җирдә*
*Буразнага ятып үләргә.*
*Дисбең исән...Күрсәң иде, әби,*
*Дөнья хәзер ничек үзгәргән...*
*Ә мин һаман тугрылыклы сиңа:*
*Дисбе тезәм, әби, сүзләрдән.*

«Игенчеләр нәселе» исемендәге шигырендә Разил Вәлиев үзенең тормышка мәсләген, нәселе белән горурлануын кыскача гына, сүзләрне бәрәкәтле генә кулланып, әйтеп бирә:

*Нәселемә мин хыянәт итмәм !-*
*Игенчеләр безнең ыруда.*

Ә менә түбәндәге юлларда шагыйрьнең иң кыйммәтле әхлакый сыйфатлары, принциплары сурәтләнә:

*...үлем белән якалашканда да*
*Акны кара диеп сөйләмәм.*
*Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,*
*Матурлыкны күреп тезләнәм.*
*Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,*
*Йә булмаса, үзем үзгәрәм.*

«Тик минеке» исемле шигырендә автор тагын да үзенең әхлакый принципларына туктала:

*Җилләрдән мин сафлык таләп иттем,*
*Болытлардан аклык сорадым.*
*Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә*
*Тирәнәйде маңгай сырларым.*
*Аклык эзләп гомер иткәнгәме,-*
*Ап-ак булды чигә чәчләрем.*
*Шатлыгымны җилгә сибеп йөрдем,*
*Тик кайгымны җиргә чәчмәдем.*

Аз гына сүзләр белән, кинаяләп кенә бер төпле фәлсәфи фикерне әйтә белә Разил Вәлиев. Мисал өчен, бер шигырендә ул урмандагы юкә, миләш агачлары турында сөйли: «Төне буе көлде алар», -ди. Аннары карурман куаклары усал гайбәт тараткан, имеш. Нәтиҗәдә юкә ялгыз калган, миләшнең дә бәхете юк:

*Урманда көз. Орлыклы һәм*
*Җимешле агачлары.*
*Тик юкәнең каны зәңгәр,*
*Миләшнең бәхете сары.*

Татар иленең газиз бер баласы икәнлеген, шушы җирнең хуҗасы икәнлеген Разил Вәлиев турыдан- туры ассызыклый:

*«Без килемешәк түгел бу җирдә...» дип*
*Каным белән әзер язарга.*

(«Казан вокзалы» шигыреннән).

«Ватаным» дигән җырында автор үзенең Ватаны белән горурлана, аның батыр уллары белән мактана:

*Сез кайсы халыктан?-дисәләр,*
*Батырлар исемен атадым.*
*Батырлар утларга керделәр,*
*Тик исән булсын, дип, Ватаным.*

Туган ягыңа, туган илеңә карата булган тойгылар, уйлап карасаң, мәхәббәт, сөю хисләреннән дә көчлерәк икәнен шагыйрь менә ничек аңлата («Чакырма» исемле шигырьдән):

*Чакырма туган ягыңа,*
*Чакырма, диңгез кызы.*
*Җибәрми туган ягымның*
*Давылы, кары, бозы.*

Әйе шул, туган якның кары, бозы да кешегә кадерле бит. Менә шундый гади генә күренгән сыман чагыштыру белән Разил Вәлиев бик тирән фикерне аңлата укучыга.

Разил Вәлиев туган телнең иң югары әһәмияткә ия икәнен күрсәтә шигырьләрендә. «Туган телдә дәшсәм генә» исемле шигырендә ул болай дип язган:

*Туган телдә җырлый чишмә,*
*Туган телдә шаулый таллар.*
*Туган телдә дәшсәм генә,*
*Туган җирем мине аңлар.*

Туган халкының ачы язмышы хакындагы уйлар шагыйрьнең «Сөембикә» исемле җырында ачык чагыла:

*Ай моңлана зәңгәр күктә,*
*Казан һаман сине көтә.*
*Язмышыма хуҗа булып*
*Кайтчы, зинһар, Сөембикә.*

«Казан күле сыман» дигән җырда да Разил Вәлиев туган халкы өчен борчыла, ләкин шулай да алда өмет барлыгына ышанычын белдерә:

*Салды безне еллар*
*Язмыш учагына...*
*Кабан күле мәңге*
*Казан кочагында.*
*Кабан күле якты*
*Халкым йөзе сыман.*
*Кабан ярларына*
*Безнең язмыш сыйган.*

«Борынгы Болгарда» исемле шигырендә Разил Вәлиев татар баласының изге Болгар җирендә туа торган хисләрен ачкан:

*Болгар җире, Бөек Болгар иле...*
*Тарихка мин саклыйм зур үпкә.*
*Бабамнарның мәгърур җаны кебек*
*Күтәрелә тургай биеккә.*
*...Болгар иле- бабамнарның иле,*
*Тургай моңы- минем моңнарым.*
*Мин тургайны түгел, бүген гүя*
*Бабамнарның җырын тыңладым.*

Туган авылына мәхәббәтен җырламаган шагыйрь сирәк очрыйдыр ул. Разил дә моннан читтә калмаган. Бөек рус шагыйренең «И дым Отечества сладок нам» дигән сүзләре һәркемгә дә таныш бит. Ә менә Разил Вәлиев «Авылга кайту» исемендәге шигырендә туган якның төтенен бөтенләй башкача тасвирлый:

*Ал кояшка таба йөзне тотып,*
*Күпме юллар үттем!*
*...Дөньяда тик безнең авылдадыр*
*Ипи исле төтен.*

Әйе, менә монысы- нәкъ татар рухында бит! Чынлап та, авылдагы татар өйләренең төтене дә ипи исен алып килә шул. Шагыйрь туган авылына, туган ягына тагын берничә сыйфат өстәп куя:

*Олы хисләр, олы омтылышның*
*Туган якта башы.*
*Шушы җирдә туган хыялларым*
*Шунда чынга ашты.*

Ә «Тау кызына» исемендәге шигырьдә туган якны сагыну хисен сыйфатлау өчен автор башка бер образны тапкан:

*Әфлисуннар лимон булды*
*Туган ягын сагынып.*

Татар халкының тарихи язмышы шундый булган ки, халыкның күп өлеше туган туфрактан аерылган. Алай гына да түгел, элек-электән туган якларыннан китәргә

мәҗбүр булып, чит илләрдә торып калган татарларның бүгенге нәселләренә яңа заман татарлары да кушыла торды. Боларын инде туган илен сагынып, җирсәп яшәүчеләр, дияргә кирәк. Разил Вәлиев татар шагыйре буларак, бу теманы да читләп үтә алмый:

*Бәхет туган җирдә икәнлекне*
*Ышандырган вакыт аларга.*
*Кара түбәтәйле картлар кайта*
*Шул туфракта ятып карарга.*

«Кайтам инде дөнья урап» дигән җырда да шуңа охшаш фикерләр чагыла:

*Кайтам инде дөнья урап,*
*Адашам урманымда.*
*Минем язмыш туры килде*
*Юлларның уравына.*
*Чит илләрдә, чит җирләрдә*
*Газиз гомерләр үткән.*
*Диңгез суы нигә тозлы?-*
*Әллә күз яше микән?*

Адәм заты нинди генә яшькә җитмәсен, аның күңеле картаймый, диләр. Дөрестер дә шул. Разил Вәлиев та әнә шул фикерне иске көймә образы аркылы ачып бирә. Шунда ук автор көймәнең дә туганякларны ташлап китә алмавын өстәп куя, шуның белән ул сүзне туган як темасына тоташтыра:

*Карт көймәнең күңелендә сагыш,*
*Япа-ялгыз калгач, нишләсен?*
*Дулкын бәргән саен, талпына ул,*
*Онытадыр, ахры, үз яшен.*
*Онытгылар мине, онытгылар,*
*Урын, диләр, сиңа музейда.*
*Бу якларны ташлап китә алмам...*
*Тән тузса да, йөрәк тузмый ла.*
*(«Иске көймә зары» шигыреннән).*

Үзенең иҗатында Разил Вәлиев җирдә тынычлык өчен көрәшүче булып та чыгыш ясый. Шагыйрь атом бомбасы куркынычы астында яшәү мөмкин түгеллеген раслый:

*Илләр бүләр өчен атом бүлеп,*
*Сак йокысын бүлеп кешенең,*
*Бәхеткәме, ләхеткәме икән,*
*Тарих, безгә юллар түшәдең?*
*Җәй җиттисә, шомлы күк күкрәде,*
*Без яшенгә кушылып яшәдек.*
*Мин яшьтәше атом бомбасының-*
*Икәү бергә чакта яшәү юк!*

Разил Вәлиевның «Әфган дәфтәре»ндәге «Адаштым мин Кабул урамында» дип аталган шигыре дә нәкъ дөньядагы тынычлык өчен көрәшнең бер мисалы булып тора ала. Монда ул яшь әфган солдаты образын үзәккә куя:

*Япь-яшь солдат нидер сөйли миңа,*
*Кабалана, ымлый, ашыга,*
*Һәм аннары...чәчәк кадап куя*
*Мылтык көпшәсенең башына.*
*Күрсәтә ул аннан ал кояшка,*
*Күрсәтә ул таулар ягына.*
*...Беләм, дустым, берсүзсез дә аңлыйм:*
*Тынычлыкны җаның сагына.*

«Елмайсын сабыйлар» шигырендә Разил Вәлиев тынычлык темасын башка яктан карый. Монда ул сугышның хәсрәтле, кайгылы нәтиҗәләре кешене гомерлек сагышка салуын күрсәтә:

*Агара, чалара әнием чәчләре...*
*Агармый тик кайгы карасы.*
*Мәйданда Мәңгелек ут яна,*
*Ул-минем йөрәгем ярасы.*

Саф, самими дуслык хисләрен югары күтәргән әсәрләрендә Разил Вәлиев халык күңеленә ятышлы сүз тезмәләрен бик оста куллана. Моны аның сүзләренә язылган «Бер алманы бишкә бүләек» дигән күркәм җырда бик ачык күрергә була:

*...Кайгы төшсә безнең башка,-*
*Бер кайгыны бишкә,әй, бүләек.*
*...Күңелләргә шатлык күчсә,-*
*Бер шатлыкны бишкә, әй, бүләек.*
*Шатлык килде, шатлык төште...*
*Бәхетләр соң кем өлеше...!*
*Бәхет булып алма пеште,-*
*Бер алманы, әй, бишкә бүләек.*

Чынлап та, бер алманы бишкә бүлә белү, шуңа омтылу- сокланырлык образ бит ул!

Разил Вәлиевнең байтак шигырьләре әниләргә багышланган. Шагыйрь ана алдында түбәнчелек белән баш ия, ананың кайгы-хәсрәтен үз өстенә алырга тели. Шушы фикер «Нигә, әни, нигә картаясың?» исемле җырда да ачык күренә:

*Нигә, әни, нигә картаясың,-*
*Уйлыйсыңмы дөнья афәтен?*
*Күчсен, әйдә, безнең йөрәкләргә*
*Бар уйларың, бөтен хәсрәтең.*

«Сагынам» дигән җырда исә ананы чиксез сагыну хисе урын алган:

*Офыкларга карап, һәр көн саен*
*Сине уйлыйм, синә табынам.*
*Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк,-*
*Сине, әнкәй, сине сагынам.*

Олыгая барган саен, кеше үткән гомер, язмыш турында ешрак уйлана башлый, үткәннәр сагындыра, теге яки бу хаталар өчен җан әрни. «Көз» исемле шигырендә Разил Вәлиев шул темага да кагыла:

*Кабат кайтмас яфракларын сагынып,*
*Бар агачлар ятып елады.*
*Агачларга кушылып, мин еладым,*
*Сагындым да үткән елларны.*

Ләкин байтак кына башка каләмдәшләреннән үзгә буларак, Разил теманы оптимистик рухта тәмамлый:

*Кышны уйлап моңсуланып йөрдем,*
*Каурыйларын койган казлардай.*
*Бар өметем минем кышта инде...*
*Кыш артында чөнки язлар бар.*

Разил Вәлиев иҗатында, аның җырларында мәхәббәт, саф сөю темасы үзгә бер урын алып тора. «Урман чишмәсе» исемле җырында шагыйрь үзенең сөйгәнен менә ничек тасвирлый:

*Зифа каендай синең буйларың.*
*Карадым сиңа, карап туймадым.*
*Чишмә суыдай акты чәчләрең,*
*Чишмә суыдай җанга чәчрәдең.*

«Иң якты йолдыз» исемле җырында исә ул сөйгәнен һәм аңа булган мәхәббәтен башкача тасвирлау мөмкинлеген таба:

*Йолдыз төсле күзләрең...*
*Нигә моңсу йөзләрең?*
*Күктә йолдыз атылганда*
*Ничек түзәрмен?*

Мәхәббәтне югары күтәреп, шагыйрь аны шундый үзгә бер халәт дип күз алдына китерә ки, хәтта аны табар өчен бер генә яшьлекнең җитәрлегенә шөбһә белдерә:

*Мажаралар дөньясында*
*Мажаралар бетәрме?*
*Бер мәхәббәт табар өчен*
*Бер яшьлегем җитәрме?..*

Татарлар һәм башкортлар арасында иң популяр җырларның берсенә әйләнгән «Таң җыры»нда исә шагыйрь мәхәббәт хисе - яшь кызлар да, яшь егетләр дә туктаталмый торган бер көч икәнлеген күрсәтә:

*Уңда юллар, сулда юллар...*
*Юлларга кемнәр чыгар?*
*Танда егет җырлап узса,*
*Кыз күңеле ничек чыдар?*
*Уңда юллар, сулда юллар...*
*Кайтмыйча ничек чыдар?*

«Сана, кәккүк, сана таңнарымны» дигән җырында Разил Вәлиев сөйгән кешең белән аерылу сагышын тасвирлап, мондый хәлгә йөрәк тә түзәлмәслеген аңлата:

*Уртак иде язлар,*
*Уртак иде көзләр.*
*Синнән башка йөрәк*
*Ничек соң түзәр?*

«Зинһар өчен, кермә төшләремә» исемле җырда тирән сагыш кешенең бөтен гомерен биләп алганлыгы күрсәтелгән:

*Зинһар өчен, кермә төшләремә...*
*Таң атуга төшләр өзелә.*
*Көннәремне, елларымны алдың.*
*Төннәремне калдыр үземә.*
*Зинһар өчен, кермә төшләремә...*
*Минем хәлгә кемнәр төшенә?*
*Сөям хәзер бары хыялымда,*
*Яшим хәзер бары төшемдә.*

«Мин бит синсез торалмам» исемле җырда саф мәхәббәтнең никадәр көчле хис икәнлеге түбәндәгечә ачылган:

*Саубуллашмый китеп бардың,*
*Кайтып кер исәнләшеп.*
*Мин бит бары сине көтеп,*
*Җан асрыйм, исән яшим.*
*Син югалган юлга карап,*
*Сагышларга уралам.*
*Сагышларыма уралам,*
*Мин бит синсез торалмам.*

Разил Вәлиев -ике йөздән артык җырларның авторы. Татарстанның атаклы композиторлары аның сүзләренә бик теләп яңа җырлар иҗат итәләр. Бу җырлар халык күңелендә урын ала, бара-бара халык җырына әйләнеп тә китә. Монысы инде- шагыйрьнең дә, композиторның да чын-чынлап үз халкының эчке тойгыларын сиземләве,

туган халкының теләкләрен гамәлгә ашыруы, дияргә була. Татарстанның  халык шагыйре Марсель Галиев әйткәндәй, «Урал аръягындамы, Ерак Себердәме, Истамбул яки Хельсинкидамы, Австралия яки Америкадамы яшәгән татарлар бердән яратып моңлана торган җыр язуга ирешү- һәр шагыйрьнең эчке хыялы түгелмени?»

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстанның һәм Рәсәйнең атказанган мәдәният хезмәткәре, Рәсәй Гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, тарих фәннәре кандидаты, «Планетада цивилизацияне, яшәешне һәм мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә керткән хезмәтләре өчен» Халыкара көмеш медаль иясе, АКШ һәм Англиянең биографик үзәкләренең идарә әгъзасы, «Кем ул кем» дип аталган Халыкара энциклопедиягә кертелгән, биш ел рәттән дөньяның иң атаклы шәхесләре исемлегендә теркәлгән, АКШ Төньяк Каролина штатындагы Америка биографик институты тарафыннан «XX гасыр кешесе» исеме бирелгән. Менә болар барысы да бер үк Разил Исмәгыйль улы Вәлиев хакында әйтелгән сүзләр.

Миңа бүләк иткән китапларының берсенә Разил түбәндәге сүзләрне язып куйган иде: *«Гриф туганга -каләмдәшкә, милләтебез кайгысы белән кайгырып, милләтебез шатлыгы белән шатланып яшәүче дустыма-олы ихтирам белән»*. Минем өчен чиксез кадерле шушы сүзләрне мин Разил Вәлиевнең үзенә әйтер идем. Халык язмышын кайгыртучы, туган ил борчылуы белән борчылучы, милләтенә фидакарь хезмәт итүче ватанпәрвәр милләттәшемә ихлас күңелдән озын, бәхетле гомер телисем килә. Милләтем менә шундый уллары белән көчле, менә шундый, Разил Вәлиев кебек милләттәшләрем татар халкының үзаңын саклауга һәм ныгытуга бәяләп бетермәслек өлеш куша.

*«Фикер» гәзите №4-5 (85-86) 2014 ел, Алматы.*

## Роберт Миңнуллин

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе, Муса Җәлил исемендәге яшьләр премиясе һәм Абдулла Алиш исемендәге премия лауреаты, Г.Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортостанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Мөгаллим улы Миңнуллинга 65 яшь тулды.

Атаклы шагыйрь Роберт Мөгаллим улы Мңнуллин Башкортостаның Илеш районындагы Нәҗәде авылында дөньяга килгән. Аның балалык еллары шул ук районның Шәммәт авылында уза. Авыл мәктәбен тәмамлап, урта белем алгач, ул район газетасының әдәби хезмәткәре, районның комсомол комитеты секретаре булып эшли.

1968-1973 елларда Роберт Миңнуллин Казан дәүләт университетында белем ала. Студент чорында ук ул әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнә башлый: университетта оештырылган «Әллүки» исемендәге әдәби берләшмә әгъзасы була, аның шигырьләре матбугатта еш-еш күренә, ул яшь шагыйрьләрнең Бөтенсоюз фестивалендә катнаша. Университетның тарих-филология факультетын уңышлы тәмамлаганнан соң Роберт Миңнуллин «Яшь ленинчы» исемендәге республика газетасының корреспонденты, Татарстан Язучылар берлегенең секция секретаре, секция рәисе, «Казан утлары» журналының бүлек редакторы, Татарстан телевидениесенең баш редакторы булып эшли. Шул ук вакытта ул «Шигъри тәлгәшләр», «Көзге» һәм «Ихлас» исемендәге телевизион тапшыруларның авторы һәм алып баручысы да була.

1990 елда Р.М.Миңнуллин Татарстан Республикасының халык депутаты итеп сайлана һәм үзеннең әдәби хезмәтен сәяси эшчәнлек белән бергә алып бара башлый. Татар-

стан Республикасының язмышында зур роль уйнаган байтак документларга  депутат Миңнуллинның туры-дан-туры катнашы бар. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы сыйфатында Роберт Миңнуллин республиканың билгеле дүләт һәм сәяси хезмәткәрләре арасында киң таныла.

Шагыйрьнең иҗатында иң төп темаларның берсе-Изге Ана темасы, дисәк, ялгыш булмас. Роберт малай чагыннан ук әтисез кала; әтисе вафат булганнан соң, бу малай гаиләдә иң өлкән бала гына түгел, ир-ат затыннан да иң өлкән кеше булып кала. Берсеннән-берсе кечкенә балаларны үстерү, аякка бастыру бер гади авыл хатыны-татар хатынының җилкәсенә төшә; һәм ул шушы искиткеч катлаулы бурычны намус белән җиренә җиткерүгә ирешә.

*Без биш бала үстек  -бер йодрык,*
*Тик үсмәдек иркә кочакта.*
*Без әнкәйнең биш шатлыгы булдык,*
*Биш кайгысы булдык кайчакта, -*
*дип яза шагыйрь.*

Әлбәттә, Анага рәхмәтле булу тойгысы булачак шагыйрьнең йөрәгендә җуелмас эз калдыра. Шул сәбәптәнме, башка сәбәпләр аркасындамы, ләкин шагыйрьнең лирикасында Изге Ана сокланырлык биеклеккә күтәрелгән:

*Әнкәй дә картайган инде,*
*Чәчләре дә агарган:*
*Нур сибелә, нур чәчелә,*
*Нур бөркелә алардан.*
*Бик килешә aклары да,*
*Сагынам карасын да.*
*Мин агарткан чәч тә бардыр*
*Ул чәчләр арасында.*

Роберт Миңнуллинның Анага багышланган шигырьләренә күп кенә җырлар язылган, алар халык арасында таралып, татарларның яраткан җырлары арасында урын алган. «Әнкәй», «Әнкәйнең ак чәчләре», «Әнкәмнең догалары», «Исән-сау бул, әни» исемендәге җырлар күптән инде халык җыры итеп кабул ителә. Җырлар турында сүз чыккач, Роберт Миңнуллин -берничә дистә җырның сүзләрен иҗат иткән шагыйрь икәнлеген әйтеп китү дә урынлы булыр. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә дә «Әбиләр чуагы», «Сөндыр шул, сөндыр», «Яратыгыз», «Рамбар юллары», «Кайтырсыз әле бер» исемендәге һ.б.ш. җырларны яратып җырлыйлар.

Роберт Миңнуллинның байтак шигырьләре балалар өчен язылган. Шул авторның балалар психологиясен тирән аңлавы да, нәкъ балалар телендә сөйләшә белү сәләте дә ачык чагыла. Мисал өчен, авторның «Мин барсын да булдырам» дигән шигырен тулысынча китерик.

*Мин җил кебек улый беләм,*
*Яңгыр кебек елый беләм,*
*Кояш кебек көлә беләм,*
*Чишмә кебек җырлый беләм.*
*Агач булып шаулый алам,*
*Күгәрчендәй гөрли алам.*
*Бик тырышсам, балык кебек*
*Сөйләшми дә йөри алам.*

Балалар темасын шагыйрь Ана темасы белән бәйләп, чын тәрбияви әһәмияткә ия булырлык «Әниемә ял кирәк» исемендәге шигырен язган.

*Әй, кызлар! Әй, малайлар!*
*Тик торыгыз, тыныгыз!*
*Аз гына да чыкмасын*
*Сезнең тавыш-тыныгыз!*
*Кошкай, син дә җырлама!*
*Пескәй, син дә мырлама!*

*Бозау, син дә мулама!*
*Акбай, син дә улама!*
*Шаулама син дә, тирәк!*
*Әниемә ял кирәк!*
*Ул эшеннән*
*Туктасын!*
*Тизрәк ятып*
*Йокласын,*
*Ял итсен,*
*Көч тупласын!*
*Әнием, син болай да*
*Ял итәсең бик сирәк!*
*Сиңа да бит ял кирәк!*
*Арыгансың бит инде,*
*Әнием, ял ит инде –*
*Мине йоклат та тизрәк!*

Тәрбияви мәсьәләләргә кагылсак, Роберт Миңнуллинның иҗатында бу юнәлеш тә зур урын алып тора. Чынлап та, аның Изге Анага багышланган һәрбер шигыре дә тәрбия чарасы булып хезмәт итәрлек. Татар халкының гореф - гадәтенә, аның мәдәниятенә туры килә торган идеяләрне алга сөрүче әсәрләр бит алар. Халкыбыз юктан гына «Оҗмах Аналарның аяк астында» дип әйтмәгән бит инде.

Татар халык мәдәниятенең тагын бер сокланырлык күренеше икмәккә мөнәсәбәт белән бәйле. Икмәк шулкадәр югары куела ки, икмәкне алырга үрелгәндә кирәк булса, хәтта изге Корьәнгә дә басарга рөхсәт ителә. Шуңа охшаш күз карашы Роберт Миңнуллинның «Икмәккә мәдхия» исемендәге шигырендә күренә.

*Икмәк безнең- кешеләрнең*
*Иң беренче*
*Изге ашы!*

*Якты кояшлы тормышның,*
*Кешелекнең*
*Нигез ташы.*
*Кызлар йөзенә елмаю,*
*Көлү булып*
*Күчкән икмәк.*
*Батырлар беләгендәге*
*Уйнап торган*
*Көч тә –икмәк!*
*Икмәк үсә игенченең*
*Тиреннән дә,*
*Каныннан да.*
*Шуңа күрә гомер бакый*
*Шул икмәккә*
*Табынганнар...*
*Сөйләгәннәр,*
*Җирне, имеш,*
*Китлар, филләр*
*Күтәрә, дип.*
*Ә бактисәң,*
*Җирнең үзен*
*Икмәк кенә*
*Күтәргән бит!*
*Икмәк кенә*
*Күтәрә бит!*

Шагыйрь сатирадан да ерак тормый, ул үпкәләмәслек итеп көлә дә белә. Мисал өчен, татарлар арасында киң таралган бер күренешкә тукталыйк. Билгеле булуынча, татар ата-аналары яңа туган балаларына төрле-төрле ят халыклар исемнәрен бирергә ярата (Шул хисаптан, «Роберт», «Гриф» исемнәрен дә татар халкының милли исемнәре, дип әйтеп булмый инде). Шул темага кагылып, Р. Миңнуллин үзенең «Архимед белән Спартак» исемендәге шигырендә менә ничек яза:

*Безнең авыл-данлы авыл,*
*Ышанасыңмы, туган:*
*Архимед та, Спартак та*
*Безнең авылда туган!*
*Беләм әти-әниләрен,*
*Беләм бабаларын да.*
*Туганнары авыл тулы –*
*Беләм мин аларын да.*
*...*
*Архимед физикадан гел*
*«Өчлеләр» алгалаган.*
*Ә Спартак ярышларда*
*Гел артта калгалаган.*
*Ә шулай да мактый халык.*
*Чыннан да мактарлык та –*
*Спартак Гапсаттаров та,*
*Архимед Акмалов та!*

Кечкенә генә газета мәкаләсе кысаларында Роберт Миңнуллин кебек шагыйрьнең күпкырлы иҗатына җитәрле дәрәҗәдә тәфсилләп анализ ясау мөмкин түгелдер. Алдыбызга андый зур бурыч куелмады да, әлбәттә. Без халкыбызның атаклы әдибе Роберт Миңнуллинның иҗатына тарихи Ватаныбыздан читтә яшәүче милләттәшләребезнең игътибарын тагын бер мәртәбә җәлеп итү максатын гына куйдык. Халкының сокланырлык шәхесләре белән татарлар да (башка халыклар кебек үк) мактана ала бит!

Илледән артык шигъри җыентыклар авторы Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин татар шигъриятенең иң күренекле вәкилләреннән берсе ул. Аның әсәрләре төрле телләргә тәрҗемә ителгән, аның иҗаты белән татар телендә генә түгел, рус, башкорт, удмурт һәм башка телләрдә дә танышырга була. Әйтергә кирәк, шушы арада Казакъстандагы «Айкын» газетасы Р. Миңнуллинның берничә шигырен казакъ телендә басып чыгарды.

Роберт Мөгаллим улын юбилее уңае белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез. Тагын күп еллар дәвамында үзенең иҗаты белән дә, иҗтимагый эшчәнлеге белән дә туган халкыбызга хезмәт итәренә иманыбыз камил. Үзенең укучыларына соклангырлык китапларын тагын да бүләк итәр әле ул.

*"Фикер" гәзите №6(74) 2013 ел, Астана.*

## Айдар Хәлим-публицист

Күренекле шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимгә 70 яшь тулды.

Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) Башкортостанның Миякә районы Кече Керкәле авылында мәктәп укытучысы гаиләсендә дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы фронтларында әтисе һәлак булып, малай ярым ятим хәлендә үсә. Колхозда эшли, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Яшь егет үзенең мөстәкыйль тормыш юлын Астрахань-дагы разведка бораулавы конторасында бораулаучының ярдәмчесе сыйфатында башлый. Менә шунда ул нефтьчеләрнең авыр хезмәте белән үз тәҗрибәсендә турыдан-туры таныша, Тенгиз нефть чыганагын тәүге тапкыр ачучыларның берсе була. Аннары ул Башкортостанда Чишмә- Белорецк тимер юлын, Себер- Татарстан нефтепроводын салучы, Уфада журналист.

Айдар Хәлим Казан университетының журналистика факультетын һәм Мәскәүдә Югары әдәби курсларны тәмамлый. Үзенең бар көчен, сәләтен әдәби хезмәткә һәм иҗтимагый эшкә багышлый. «Аргамак» журналының баш мөхәррире, Татарстанның Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан Татар Милли Мәҗлесенең рәисе була. Бүген ул кырыктан артык китаплар авторы. Аның әсәрләре татар һәм урыс укучыларына киң танылган. А.Хәлимнең «Өч аяклы ат» исемле китабы буенча кинофильм төшерелгән.

Аның шигъриятенә, шул хисаптан балаларга багышланган шигырьләренә, чәчмә әсәрләренә, драматургиясенә бик күп авторлар югары бәһа бирәләр. Монда Айдар Хәлимнең публицистикасы турында берничә сүз әйтәсе килә.

Аның иҗатында публицистика чынлап та үзәк урын алып тора, дисәк тә, ялгыш булмас. Юкка гына түгелдер, ул үзе дә бит: «Публицистика- шигъриятнең иң югары формасы», -дип билгели. Бу сүзләрне дәлилләү өчен Айдар Хәлимнең «Хәсрәт китабы яки Абориген язмалары» («Книга печали или Записки аборигена»), «Империяне үтерергә» («Убить империю»), «Үзгәртәбез паспортны...» («Переправим паспорт...») һәм башка китапларын атап үтү дә җитәдер.

А. Хәлимнең публицист рәтендә бөтен Советлар Союзына киң танылуы, халыкара мәйданга чыгуы, мөгаен, 1988 елда «Дружба народов» исемендәге бөтенсоюз журналында басылган «Язык мой -друг мой» дигән мәкаләсеннән башлангандыр. Олы яшьтәге кешеләр хәзер дә хәтерлидер әле минемчә: ничек ашыгып-йотлыгып, шундагы фикерләрне хуплап, шул милләттәшнең кыюлыгына сокланып һәм эчтән генә мактанып та, андагы фикерләрне танудан ачынып та укыдык без шул зур мәкаләне! Чынлап та, СССР шартларында татар халкының милли яктан кызганыч хәлдә калганлыгын, телен югалта баруын ачыктан- ачык итеп, Мәскәүдә басылган журнал битләрендә әйтеп бирер өчен Айдар Хәлим булырга кирәк булгандыр.

Менә минем алдымда Айдар Хәлимнең тагын яңа бер китабы - «Жить хочется» дип исемләнгән, 614 бит күләмендәге китап- публицистик әсәрләр җыентыгы. Анда авторның үз кулы белән язылган, минем өчен бик кадерле булган багышлау да бар: «*Тарихчы, күренекле милләт хадиме Гриф Хәйруллага автордан бер күрергә зарынтизар булып*». Бу китапта А.Хәлимнең мәкаләләре, дәүләт җитәкчеләренә юлланган мөрәҗәгатьләре, хатлары тупланган.

Бу әсәрләрдәге фикерләр барысы да төпле, нигезле; кайчан язылган булуларына карамастан, алар

бүгенге көнгә караган кебек. Айдар Хәлимнең шундый фикерләреннән берничә мисал гына китерик:

- 20-40-елларда безнең ата-аналар: «Эх,минем балам урыс телен, үз телен белгән кебек белсә икән!» дип көрсенә иде, хәзерге ата-аналар киресенчә офтана: «Эх, минем балам үз телен, урыс телен белгән кебек белсә икән!» (171-бит);

- Азык-төлек мәсьәләсе беркайчан да милли мәсьәләне чишә алмый, ә менә милли мәсьәләне дөрес чишү, шулай ук милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсен дөрес чишү табигый юл белән бөтен социаль мәсьәләләрне уңышлы чишүгә алып килә (183-бит);

-Тарихны бозып, күчереп язалар, ә бит күчмә халыклар үз вакытлары өчен бөек цивилизация корганнар (192-бит);

-Заманалар үзгәрде. Хәзер бер генә милләт тә –кечкенә булса да, яки зуррак булса да- башка милләткә кол булып яшәмәячәк (204-бит);

-Милләтебез өчен караңгы, сагышлы елларда татар: «Балаларның каны урыс каны булса да, мин аларны татар дип атармын»,- дип җырлаган; чөнки ул ике халыкның да телен, мәдәниятен белү зарурлыгын аңлаган (214-бит);

- Онытырга кирәкми - Америка колонизацияланган һәм эмигрантлар тарафыннан корылган. Рәсәй булса, халыкларны үз җирләрендә колонизациялау юлы белән корылган. Шулай итеп, мин беренче нәүбәттә татармын. Шуннан соң гына россиялымын (267-бит);

- Рәсәйнең игелеккә бару юлы бердән бер генә -үз халыкларын колонизациядан азат итү, шуннан соң гына, аларның үз теләге белән генә яңадан җыйнау (282-бит);

- Кешенең һәм милләтнең туган теленә хокукы -яшәүгә хокуктан кала икенче урында тора. Үз туган телен, туган мәдәниятен яратмаган кеше, башкаларның телен һәм мәдәниятен дә ярата алмый (484-бит);

- Без үзебезне үзебез якларга тиеш. Башкаларга үпкәләмичә, һәр милләт, башкаларга тимичә генә, башкаларның милли рухын кимсетмичә генә, дөньякүләм игелеккә таба бара (535-бит);

- Без булдырабыз. Әгәр бик чынлап теләсәк... Татар халык җырының тәэсир көче дәүләтсез калган халыкның күпгасырлык интегүенә, җәфа чигүенә тиң (546-бит);

- Халыкларның юкка чыгу процессын ясалма рәвештә тизләштерергә ярамый. Ул тик Ходай ихтыярында. Империяләрнең гомерен дә ясалма рәвештә иксез -чиксез озайтып булмый. Ул да Ходай ихтыярында (568-бит);

-Тәрбия эшендә кешенең туган теле, мәдәнияте, гыйлеме һәм тарих -әхлакый мирасы катнашмаса, шул кешедән гражданин, үз иленең патриотын тәрбияләп буламы? (580-бит).

Шушы гына мисаллардан да бу китапта никадәр фикер байлыгы бар икәнен аңларга була. Ә бит бу мисаллар-китаптагы фикерләрнең бер бик кечкенә өлеше генә. Бу бит әле Айдар Хәлимнең бер китабыннан алынган мисаллар гына!

Әйе шул, Айдар Хәлим -тирән уйлы фикер иясе, милләтпәрвәр, туган халкына җаны-тәне белән бирелгән кеше.

Татар халкы фикер ияләренә һәрвакыт бай була алды. Менә нәкъ шул сыйфат та аның эреп бетмәвендә, үзенүзе гасырлар дәвамында саклап кала алуында мөһим роль уйнагандыр. Татар милләтенең иң караңгы, өметсез вакытларында да аның рухын шундый фикер ияләре саклаган бит. Бүгенге көндә исә милләтебезнең милли рухын ныгытучылар арасында Айдар Хәлим һичшиксез лаеклы урын алып тора.

*«Фикер-Өмет» гәзите №1(65) 2012 ел, Алматы.*

## Хатыйп Миңнегулов

Киләсе елда Бөек Җиңүнең 70 еллыгы бәйрәм ителәчәк. Бөек Ватан сугышында катнашкан баһадирларга багышланган китаплар, кинофильмнар чыгарылыр, Хезмәт фронтында фидакарь хезмәт иткән ватандашларыбыз хакында да язарлар. Сугыш елларында бөтен авырлыкны үз җилкәләренә алган хатын-кызларга мәдхия укылыр. Сугышка киткән ирләрнең эшен көч-хәл белән җиренә җиткерергә тырышып йөргән яшь үсмерләргә дә җылы сүзләр табылыр. Һәм болар бөтенесе дә дөрес, бөтенесе дә урынлы.

Шул арада тагын бер төркем совет кешеләре игътибардан читтә кала бит әле. Сүз Бөек Ватан сугышы башланганда кечкенә сабый булган кешеләр турында бара. Аларны Бөек Ватан сугышы чоры балалары дияргә ярыйдыр. Шундый балаларның байтагы, бәхетсезлеккә каршы, Советлар Союзының көнбатыш регионнарында иде. Ут астында калып, оккупацияне башыннан кичереп, бу балалар да күп җәфа күрделәр. Аларның язмышы хакында да кайбер материаллар күренгәли. Ә менә СССР ның башка регионнарындагы сугыш чоры балаларының язмышы ничегрәк булган икән? Минемчә, моңа игътибар иткән кеше дә юк. Мисал өчен, Идел-Урал регионын алсак, сугыш елларындагы ачлык-ялангачлык күпме баланың башына җитте икән? Шул балаларның исән калганнары арасында нindирәк шәхесләр бар икән? Яз буе черек бәрәңге кәлҗемәсен ашап, бераз үләннәр чыккач та, урысча әйткәндәй «подножный корм» га күчеп, фәкыйрьлектә үскән балалар бит алар. Шуның өстенә күбесенең аталары сугыш кырларында ятып калган, сугыштан кайталган аталар да гарип -горабә бит.

Баксаң, болар да башка буын балаларына бил бирмәслек булып үскәннәр икән ләбаса. Мисалга ерак

барасы да юк: Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев та шул буын вәкиле бит. Кечкенәдән күргән кыенлыклар бу буын балаларын авырлыкларга баш ими торган үҗәт кеше итеп үстерде микән әллә? Һәр хәлдә сугыш чоры балалары арасында да дәүләт эшлеклеләре дә, фән хезмәткәрләре дә, язучылар, шагыйрьләр дә аз түгел. Алар арасында күренекле шәхесләр дә җитәрлек.

Шундый шәхесләрнең берсе- Хатыйп Миңнегулов, менә быел гына ул үзенең 75 яшен билгеләп үтте. Татарстанның Зәй районындагы бер авылда дөньяга килгән бала ата назын да туйганчы татый алмаган. Аның әтисе Йосыф Миңнегулов 1944 елда фронтта һәлак була. Ана кеше ятим калган дүрт баланы үстереп, аякка бастыра. Татар хатыннары, Бөек Ватан сугышы толларына нихәтле генә мәдхия укысаң да, аз булыр...

Хатыйп җидееллык мәктәбне тәмамлагач ук колхозда эшли, аннары авыл мәктәбендә укыта. Урта мәктәпне тәмамлагач, бәхет эзләп Таҗикстанга, Ленинабад өлкәсенә барып чыга, заводта эшли. Туган якларына әйләнеп кайткач, клуб мөдире була, Казан дәүләт университетында укый, мәктәп укытучысы һәм директоры, КПСС райкомы хезмәткәре була. 1967-елдан башлап Хатыйп Йосыф улының хезмәте Казан дәүләт университеты белән бәйле. Монда ул татар әдәбияты тарихының үзенчәлекләрен тирән өйрәнә, кандидатлык, соңрак докторлык диссертацияләрен яклый. Үзенең фәнни эзләнү нәтиҗәләрен ул кырыклап китабында һәм берничә йөз мәкаләләрендә чагылдырган.

Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловның игътибарын иң нык җәлеп иткән чор-әдәбиятыбызның Борынгы һәм Урта гасыр чоры, шул хисаптан Алтын Урда дәвере, дисәк, ялгыш булмас. Галим төрки халыкларның уртак байлыгы булган байтак әдәби әсәрләргә анализ ясап,

аларның төп фикерен, хәзерге дәвер өчен әһәмиятен ачып бирә. «Безнең халыкның якынча мең ел ярымлык дәүләтчелек һәм язу тарихы бар. Шушы вакыт эчендә ул гаять бай рухи мирас, интеллектуаль хәзинә туплаган»,- дип күрсәтә Х.Миңнегулов. Менә шул байлыкны ачуга, аны туган халкына җиткерүгә багышлаган үзенең хезмәтен галим.

Мисал өчен, Х. Миңнегуловның «Котадгу белек» («Бәхет гыйлеме») исемендәге әсәргә багышланган хезмәтен алыйк. Китапның авторы, соңрак Йосыф Баласагунлы исеме белән танылган кеше, Чу үзәнендәге Баласагун каласында дөньяга килгән, шушы китапны ул 1070 елларда тәмамлаган.

Китапның эчтәлеген тәфсилләп өйрәнеп, Х.Миңнегулов төреклекнең төп, нигезге принциплары булган дүрт принципны ачыклый: гаделлек-тугрылык, бәхет-сәгадәт, гакыл, канәгатьлелек. Йосыф Баласагунлы әсәрдәге дүрт персонажга менә шул дүрт принципка караган символик мәгънә биргән. Шул дәвердәге әдәби ядкәрләрдә хөкемдар, гадәттә, сорау бирүче ролендә генә була. Бу китапта исә хан әңгәмәдә катнашып, үзенең шәхси мөнәсәбәтен дә белдерә. Шулай итеп Йосыф Баласагунлы хөкемдарга куела торган кайбер таләпләргә дә туктала. Гади генә адәм баласына килсәк, ул белемле, һөнәрле, әхлаклы, акыллы, ярдәмчел, сабыр, шәфкатьле, ихлас, намуслы, гадел булырга тиеш, дип раслый Баласагунлы; һәр кеше үзенең бурычларын белергә, аларны җиренә җиткереп башкарырга тиеш. Китапның шундый үзенчәлекләрен ачып, Х. Миңнегулов: бу әсәрдә «тормыш тәҗрибәсе тупланган. Авторның төп максаты- укучыны яшәргә өйрәтү, аңа күпгасырлык рухи тереклек тәҗрибәсен җиткерү... Бу китап- акыл-хикмәтнең тулы сандыгы, төкәнмәс бер чыганагы. Анда бүгенге көнгә аваздаш яклар да бихисап»,-дип, әсәрне хәзерге заман тормышына бәйли.

Китапның лирик ягына да игътибар итә Хатыйп Миңнегулов. Китапның «Яшьлекне сагыну һәм картлык турындагы» дип аталган бүлекчәсе – «лириканың гаҗәеп күркәм бер үрнәге», дип нәтиҗә ясый ул.

Хатыйп Миңнегулов Алтын Урда чоры шигърияттен өйрәнү өлкәсендә күп көч салган галим. Атаклы шагыйрь Сәйф Сараиның тормыш юлын һәм иҗатын аның кебек үк төпле өйрәнгән башка берәр галимне күрсәтеп тә булмыйдыр, мөгаен. Алтын Урда чорындагы төрки-татар әдәбиятының югаргы ноктасы - Сәйф Сараи иҗаты, дип бәһалый ул. Шагыйрьнең «Китабе Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан китабы»)-шигъри әсәр, монда сигез төп бүлек бар. Алар хөкемдарлар тормышына, дәрвишләрнең холыкларына, аз гына белән канәгать булуга, дәшмәүчелекнең файдасына, мәхәббәт һәм яшьлеккә, картлык һәм хәлсезлеккә, тәрбияләүнең әһәмиятенә, үзара аралашу кагыйдәләренә багышланган. Бүлекләрнең һәрберсенә дә Х.Миңнегулов төпле анализ ясый. Әсәрнең гомуми төзелешен ул «тартмалы композиция»дип атый, чөнки монда уртак сюжет юк, ул аерым хикәятләрдән, нәсыйхәтләрдән һәм хикмәтләрдән төзелгән.

Сәйф Сараиның икенче бер безнең замангача сакланган һәм табылган язмасы «Ядкәрнаме» берничә шигырьне һәм «Сөһәйл һәм Гөлдерсен» исемендәге поэманы үз эченә ала. Поэма саф мәхәббәт темасын югары күтәрә, тугылык, кыюлык сыйфатларын мактый. Х.Миңнегулов поэмадагы тагын бер элементка игътибарны җәлеп итә: монда Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүенә ишара ителгән икән. Шулай итеп, шушы фәнни проблеманың чишелешен Коперникка кадәр үк Сәйф Сараи тапкан икән бит!

Урта гасыр төрки -татар әдәбиятының ядкәре булган бер чәчмә әсәр- ул «Нәһҗел фәрадис» («Оҗмахларның

ачык юлы») 1358 елларда тәмамланган. Аның авторы-Бөек Болгарда туган укымышлы кеше Мәхмүд бине Гали бине Гомәр әс-Сараи әл-Болгари әл-Кәрдәри. Дини-әхлакый рухтагы бу әсәр дүрт бүлектән гыйбарәт. Китапның ике бүлегендә Мөхәммәд пәйгамнәрнең, аның якыннарының, беренче хәлифәләрнең, имамнарның тәрҗемәи хәлләре, эш-гамәлләре китерелә, шул затларга мөнәсәбәтле сюжетлар бирелә. Киләсе ике бүлек Аллаһы Тәгаләгә якынайта торган һәм Аңардан ераклаштыра торган эш-гамәлләргә багышланган.

Һәр бүлекнең гомуми корылышында охшашлыклар барлыгын ачыклый Х. Миңнегулов. «Автор, кагыйдә буларак, әүвәл Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисен китерә, аның эчтәлеген, төп мәгънәсен аңлата, төрле абруйлы кешеләргә мөнәсәбәтле аерым фикерләрне, эпизод-күренешләрне бирә,- ди ул.- Алга таба исә хәдис темасына туры килешле хикәятләр тәкъдим ителә. Ахырда әйтелгәннәргә йомгак ясала, нәтиҗәләр чыгарыла».

Х.Миңнегулов китапның тәрбияви ягына игътибар итә, әсәрнең тормыш дәреслегенә, тәрбия китабына якынлыгын, шушы вазифаны күп гасырлар дәвамында үтәп килүен дәлилли. Мәхмүд Болгари «аеруча инсанга, аның иман-ышанычына, үз-үзен тотышына, әхлагына игътибар бирә,-дип күрсәтә Хатыйп Миңнегулов.-Шуңа күрә аның әхлакый йөзе, эш-гамәлләре җисеменә лаек булырга тиеш». Инсанның сабырлык, тугрылык, гыйлемлелек, тыйнаклык, ата-ананы хөрмәт итү, Тәңрегә бирелгәнлек, Тәүбә кылу, кичерә белү, хәләл көч белән гомер кичерү кебек сыйфатларын, эш-гамәлләрен Мәхмүд Болгари зурлап, мактап күрсәтә. Шул ук вакытта, дип күрсәтә Х. Миңнегулов, «аларның капма-каршыларын (тәкәбберлек, гайбәт сөйләү, комсызлык, икейөзлелек, үч тоту, ялган сөйләү, мәкерлелек, зина кылу һ.б.) кискен тәнкыйтьли». Бөтен начарлыкның, гөнаһларның нигезен Мәхмүд Болгари хәмер эчүдән күрә.

Хатыйп Йосыф улы Казан ханлыгы чорындагы ата-бабаларыбызның әдәби мирасын да тирән өйрәнгән галим. «Татар халкы –элек-электән әдәби талантларга бай кавем,- дип яза Х. Миңнегулов.- Шулай килеп чыккан ки, аларның күпчелеге Казан белән бәйләнешле. Безгә мәгълүм мәшһүр шагыйрьләрнең берсе Мөхәммәдьяр Мәхмүд Хаҗи углы әнә шундыйлардан. Аның тормышы, иҗаты Казан каласы белән табигый берешкән».

Мөхәммәдьярның (1497-1549) безнең замангача сакланып калган өч поэмасы билгеле: «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге»), «Нуры содур» («Күңел нуры»), «Нәсыйхәт». Х. Миңнегулов беренче нәүбәттә Мөхәммәдьярны нинди мәсьәләләр борчыганы белән кызыксына һәм шагыйрьнең кеше проблемасын үзәккә куюын ачыклый. Мөхәммәдьяр фикеренчә, кешенең кем һәм нинди булып үсүе, яшәве тәрбиягә, җәмгыятькә, адәм баласының үз-үзенә мөнәсәбәтенә бәйле икән.

«Мөхәммәдьяр әсәрләрендә «камил инсан» төшенчәсе шактый ачык төсмерләнә,- дип яза галим.-Ул диндар, тыйнак, киң күңелле, юмарт, гадел, ярдәмчел, белемле. Автор бу төп сыйфатларның асылын, өстенлеген еш кына махсус рәвештә, аерым-аерым тасвирлый... Шунысы үзенчәлекле: автор...уңай инсани сыйфатларны еш кына аларның капма-каршылары белән бәйләнештә сурәтләргә ярата». Кешеләр игелекле эш-гамәлләр кылырга, кыен хәлдә калучыларга ярдәм итәргә, башкаларның күңелен бары «яхшылык берлә» алырга тиеш. Шунда гына синең яхшы исемең мәңгелеккә калыр, дип раслый Мөхәммәдьяр.

Җәмгыятьне сафландыру, кешеләрне бәхетле итү, Мөхәммәдьяр фикеренчә, инсаннарның белемле, әхлаклы булуы белән беррәттән хөкемдарларның гаделлегенә, зирәклегенә, мәгърифәтлелегенә бәйле. Хатыйп Йосыф улы шагыйрьнең иҗатындагы тагын бер үзенчәлеккә игътибар итә: Мөхәммәдьяр хатын-кызны

ихтирам итәргә, аны ир-атлар белән тиң күрергә чакыра.

Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловның анализларыннан күренгәнчә, татар халкының алдынгы вәкилләре элек-электән үк инсанның иң мөһим кешелекле сыйфатларын югары күтәргәннәр икән. Димәк, шундый әсәрләрнең әһәмияте бүген дә югалмаган, алар хәзерге буын балаларын тәрбияләү эшендә урын алырга лаеклы икән. «Урта гасыр әдәби мирасы-халкыбызның гасырлар буе туплаган күңел хәзинәсе, акыл-тәҗрибәсе, фәлсәфәсе. Аны өйрәнү укучыларга эстетик, әхлакый, гуманистик, милли тәрбия бирүгә көчле йогынты ясый»,-ди Х. Миңнегулов. Галим: « ...алдынгы халыкларның мәгариф нигезенә милли тәрбия бирү салынган,-дип күрсәтә. -Бу аңлашыла да. Чөнки милли үзаңны үстерми торып, милләтне яшәтеп булмый. Әхлакый, эстетик һәм тәрбиянең башка төрләре бары тик туган телгә, мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә, милли тарихка нигезләнеп алып барылганда гына нәтиҗәле була».

Әдәбият белгече, филология фәннәре докторы, профессор, Русия Гуманитар фәннәр академиясенең академигы, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстанның Дәүләт бүләге лауреаты, Русиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Кол Гали, Зәки Валиди, Гаяз Исхакый исемендәге бүләкләр иясе, Казакъстандагы «Тюркология» журналының һәм Төркиядәге «Билге» журналының редколлегия әгъзасы... Саналганнардан башка да атаклы исемнәре, бүләкләре, танылган хезмәтләре дә җитәрлек Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловның. Ул бүген дә тикшеренүдә, бүген дә үзенең уңышлы фәнни эшләрен дәвам итә, шунда аның милләтпәрвәрлеге күренә. Чынлап та, «Халкыңның тарихын, телен, мәдәниятен белү- милли яшәешнең төп шартларыннан берсе. Шунсыз теләсә нинди кавем инкыйразга, бетүгә йөз тота, хәтерсезлек упкынына чума» (Хатыйп Миңнегулов).

*«Фикер» гәзите №3(84) 2014 ел, Алматы.*

## Әхәт Зәйнетдин улы Нигъмәтуллин

Әхәт Нигъмәтуллин 1923 елда Оренбург якларындагы бер авылда дөньяга килгән. Шул дәвердәге барлык кыенчылыкларны, кытлыкны, ач-ялангачлыкны үз башыннан үткәргән ул. Бөек Ватан сугышында катнашып, татар халкының батыр улы «Ватан сугышы», «Кызыл Йолдыз» орденнары һәм күп санлы медальләргә лаек булган.

Ә.З. Нигъмәтуллин Казан дәүләт университетын тәмамлаган, Башкорт дәүләт университетында (Уфа) кафедра мөдире булып эшләгән. «Акчарлаклар» исемендәге әдәби түгәрәк оештырып, һәвәскәр шагыйрьләргә дә зур ярдәм күрсәткән ул. Башкортостан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Башкортостан язучылар союзы әгъзасы, Русиянең журналистлар союзы әгъзасы, «Сәнәк» журналының 2004 елдагы лауреаты, филология фәннәре докторы, профессор Әхәт Нигъмәтуллинның югары квалификацияле педагоглар хәзерләү өлкәсендәге хезмәте җәмгыятьчелек тарафыннан киң танылган.

Әхәт Зәйнетдин улы -билгеле шагыйрь дә, аның шигырьләре һәм поэмалары җыентыклар булып басылып чыккан. Авторның иҗатында фәлсәфи мәсьәләләр, яшәеш хакындагы уй-фикерләр билгеле бер урын алып тора. Бигрәк тә алар авторның күләмле әсәрендә- «И, гомерем үзәннәре-үрләре» исемендәге поэмасында- ачык чагыла. Бу поэманы авторның автобиографиясе дип түгел, ә аның дөнья, гомер, кешенең дөньяга килүе-китүе белән бәйләнешле, бу җирдәге урыны һәм кешелек бурычлары турындагы тирән уйлары, фикер йөртүләре дип аңларга була. Бу поэма турында кечкенә язмалар кысасында түгел, ә күләмле мәкалә кысаларында сөйләргә булыр иде (Һәм шулай булырга тиеш тә).

*Гомернең гүзәллегенә сокланып, шагыйрь:*
*Ничек булса да, һәркемдә*
*Гомер үзенчә чибәр,-*
дип раслый.

Язмыш һәм кеше тормышы арасындагы бәйләнешкә тукталып, автор: «Кеше үзе өчен үзе җавапгар»,- дигән фикерне алга сөрә.

*Ходам, раббем, чиксез кодрәтле син:*
*Тапкан-яраткансың дөньяны;*
*...«Сезгә язмыш бүлеп бирү миннән,*
*Ничек яшәү сездән»,-дигәнсең.*

Туган якларына, туган авылына багышланган шигъри юллар авторның тирән хисләрен ачык күрсәтә. Чынлап та, менә мондый сурәтләү кемне битараф калдырыр икән?

*Авылның йолдызлы күге,*
*Тылсымлы таллары бар;*
*Елга буенда бик хозур*
*Усагы-таллары бар;*
*Әкият дөньясы кебек,*
*Камышлы күлләре бар;*
*Я, мондый урынны кемнең,*
*Кайларда күргәне бар?*
*...Тау итәге чишмәләрнең*
*Агышлары гайрәтле;*
*Эчсәң, суы тәнгә шифа,*
*Җилкендерә йөрәкне.*

Мәхәббәткә багышлап шигъри юллар тезмәгән кеше бик сирәктер ул дөньяда, бөтенләй юктыр да, бәлки. Бу теманы Әхәт Нигъмәтуллин да читләтеп үтмәгән, саф сөю хисләрен тасвирлаган шигырьләре дә байтак аның. Ләкин монда яңа чагыштырулар табу, яңа образлар тудыру ифрат та кыендыр, бик күпләр тарафыннан сугарылган бакча бит инде ул. Шулай да Ә.Нигъмәтуллин үзенә хас юллар таба, укучыга яңа карашлар тәкъдим итә.

*Үрмәле гөлгә охшатам*
*Чәчеңнең бөдерәсен.*
*Бөдрәң белән, үрмә гөлдәй,*
*Күңелгә үреләсең,-*

дип яза ул үзенең «Чәчләргә чәч бәйләнгән» исемле шигырендә.

«Моңлы җыр булсам иде» исемле җырында Ә. Нигъмәтуллин мәхәббәткә бирелгән яшь егетнең хисләрен түбәндәгечә тасвирлый:

*Җыр булып тусам иде дә*
*Уеңа кунсам иде.*
*Күңелеңә татлы ләззәт,*
*Ямь биреп торсам иде.*
*...Моңлы җыр булып уеңа*
*Тирән уелсам иде.*
*Йөрәгеңдә сүнми торган*
*Хис булып калсам иде.*

Сөю хисенең искиткеч бай, катлаулы, төрлечә чагыла торган күренеш икәнен шагыйрь ике дүртьюллыкта ачып күрсәтә. «Яшерен сөю» дип аталган дүртьюллыкта автор:

*Мәхәббәтнең серле чагы-*
*Яшерен сөю.*
*Ә ләззәте, сиздермичә,*
*Сөенеп көю,-*

дисә, «Тыйнак һәм тыйнаксыз мәхәббәт» исемендәге дүртьюллыкта исә:

*Мәхәббәт- ул тыйнак чакта*
*Йөрәккә үтә;*
*Мәгәр тыйнаклыгын җуйса,*
*Керләнеп бетә,-*

дип бәһа бирә.

Шагыйрьнең иҗатында сатирик әсәрләр байтак урын алып тора. Шундый әсәрләрендә автор кешеләрнең иң түбән сыйфатларын, әхлак кагыйдәләренә туры килми торган күренешләрне сурәтли. Җиңел аңлаешлы тел белән язылган, ритмик яктан үзенә тартып торган мондый шигъри юлларның халык арасынды киң таралуында шөбһә юк, әлбәттә. Халкыбызның бай сөйләмендә кулланыла торган, төп мәгънәсеннән аерулы файдаланылган

сүзләрне һәм сүз тезмәләрен автор үзенең тасвирламасына бик оста рәвештә кушып куя. Мисал өчен, «Эт үпкәсе» исемле шигырьне алыйк. Эт исеменнән сүз йөртеп, автор кешеләргә тирән үпкә белдерә:

*Мине начар кешегә тиңлиләр,*
*Кешеләргә минем үпкәм бар,-*

дип башлый ул. Кайбер кешеләргә хас булган яман сыйфатларны автор этнең сыйфатлары белән чагыштырып тәнкыйть итә:

*Кеше исереп пычракта ауный,*
*Эт исереп аунап ятамы?*
*Кеше «эт» дип исерекне сүгә,*
*Төзәтегез сез бу хатаны!*
*Кеше дулый, берсен-берсе сата,*
*Этләр берсен-берсе сатамы?*
*...Кеше кешеләр акчасын урлый,*
*Бер-берсенең өйләрен баса.*
*Кеше шундыйны да эткә тиңли.*
*Эт андый эт түгел ләбаса!*
*Дуслык өчен эт утка ташлана,*
*Кешедә юк андый бәдәнлек.*
*...Тугрылыкка этләр нык тугры,*
*Сез дә тугры була белегез!*

Шулай итеп, Әхәт Нигъмәтуллинның шигърияте күләмле тематиканы үз эченә ала. Сайлап алган һәрбер темада ул оригиналь фикерләрне шигъри юллар аша укучыга җиткерә. Тормышның, дөньяви хәлләрнең кайсы ягына тукталса да, шагыйрь аларны үзенә хас иҗади алымнар ярдәмендә тасвирлый. Автор укучыларның игътибарын җәлеп итү сәләтенә ия, үзенең бай тормыш тәҗрибәсенә таянып, һәртөрле проблемалар буенча да кешелек әхлагына туры килерлек фикерләрне алга сөрә.

Танылган шагыйрь һәм галим Әхәт Зәйнентдин улы Нигъмәтуллинга озын гомер һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар телисе килә.

*«Фикер» гәзите №7 (75) 2013 ел, Алматы.*

## Равил Гозаиров шигъриятенә бер караш

*(Йөрәк сагышы)*

Дөньяга сибелгән, таралган татар балаларының берсе- Равил Якуп улы Гозаиров- күптән инде Алматы шәһәрендә яши. Ул Башкортостанның Стәрлебаш районында туып үскән. Халкыбызның байтак татар яшь егетләре һәм кызлары кебек, бәхет эзләп, туган якларыннан киткән; Казагыстанга, Алматы каласына барып чыккан – шушында төпләнеп, торып калган. Равил монда гаилә корган, монда балалар үстергән, монда ул үзенең сагышын моңлы җырлар белән баскан. Алматыдагы татар яшьләренең ансамбльләрен дә оештырган тынгысыз җанлы кешеләрнең берсе ул.

Туган якларыннан еракта яшәүчеләрнең күңелләре бераз нечкәрәк буладыр инде: алар җырга, шигъриятькә ешрак биреләләр. Кайда гына нигезләнсәң дә, тәү тәпи баскан туфрак онытылмый бит ул. Алай гына да түгел, туган-үскән яклар көннән көнгә тагын да гүзәлрәк булып күз алдына килә, сагындыра. Тирән сагыш үзенә юл эзли, күпләрне шигъриятькә алып килә. Менә шулар үзләренең эчке хисләрен, моң-зарын шигъри юллар аркылы ачып күрсәтергә омтылалар.

Читтә яшәүче татарлар үзләре арасындагы каләм осталарын кайчагында күбрәк тә таныйлардыр. Болар бит нәкъ мондагы, туган җиреннән аерылган татарларның моңнарын, тирән сагышларын тасвирлый, онытылмас туган якларын, газиз туган халкын җырларына куша. Бер сүз белән әйткәндә, туып-үскән төбәкләреннән аерылган татар балаларының җирсүен шигъри юлларга сала.

Шигърият шаукымыннан Равил Гозаиров та читтә кала алмаган. Бүгенге көндә ул берничә шигъри җыентык авторы, аның сүзләренә байтак җырлар да иҗат ителгән.

Равил Гозаировның шигырьләре киң тематиканы үз эченә ала. Алар барысы да авторның пакь, самими хисләрен үзенә сыйдырган. Аның шигырьләрендә төп юнәлешне алып торган тема: «Татарлык, милли хисләр, тарихи Ватанга ихтирам» -дисәк, ялгышмабыз, мөгаен. Чынлап та:

*«Халкымның Син-алтын бишеге,*
*Милләтемнең алмаз терәге!*
*Сине уйлап яшәгәннәрнең:*
*«Ватаным!»-дип тибә йөрәге!»,*

дип язган кеше («Мәңге яшә, Татарстаным» исемле шигыреннән өзек) тарихи Ватанына ихлас күңелдән бирелгән чын милләтпәрвәр бит ул! Равил әфәнде меңьеллык Казан каласына соклана, аны үзенең дә башкаласы итеп саный:

*Шөкер, монда чит түгелмен-*
*Тынычланды инде күңелем!*
*...Мин оныттым газабымны,*
*Күрәм, күрәм Казанымны!*

Күп кенә шигырьләрендә Равил Якуп улы үзен бербөтен татар милләтенең баласы итеп таныта, татар булуын көчле пафос белән белдерә. Мисал өчен, аның «Мин-татармын!» исемле шигыре –әнә шундыйлардан.

Икенче бер бер шигырендә Р. Гозаиров туган халкының менә нинди гүзәл сыйфатларына игътибарны җәлеп итә:

*Ялтырап Кояш та чыкты-*
*Изге Айга нур иңде!*
*...Азан әйтә мәгърур халкым-*
*Намуслы, тырыш, динле...*

Автор туган халкы белән ихлас күңелдән горурлана, аның булдыклы, эшчән булуына, тарихына соклана:

*Халкым минем-моңлы халык,*
*Күпне күреп белгән халык,*
*Һәрбер эштә уңган халык,*
*Тарихы бай данлы халык.*

Шул ук вакытта Равил Гозаиров туган халкының язмышына ачына, аның таралып яшәвенең сәбәпләрен дә эзли:

*Мәҗбүр булдык, газапланып,*
*Сибелергә төрле якка.*
*Моң тумыйча, нәрсә тусын,*
*Заманалар авыр чакта.*

Хәзерге татар халкының ата-бабалары бөтен дөньяга танылган зур дәүләтләр корганын искә ала Р.Гозаиров. Кайбер даирә әгъзаларының бүгенге шартларда да татар халкына карата дошманлык хисләре тудырырыга маташуына йөрәге әрни аның:

*Аяк чалалар*
*Бүгенге көндә*
*Тозак коралар*
*Караңгы төндә.*
*Шул тозакларга*
*Төшмичә генә,*
*Сугыш утына*
*Көймичә генә,*
*Яшәсәк иде*
*Үз җиребездә,*
*Гел акыл белән*
*Эш итеп кенә!*

Тарихтан билгеле: татарлар, Язмыш аларны кайда гына илтеп ташламасын, шунда йортлар торгызганнар, мәдрәсә-мәктәпләр ачканнар, күршеләре белән дус-тату яшәгәннәр. Дошман явы килсә, яңа Ватаннарын, җирле халык белән беррәттән, кыю яклаганнар. Шуңа күрә башка илләрдә дә үзләренең батырлыклары, рухи матурлыклары белән танылган татарлар бихисап. Бу күренеш тә Равил Гозаировның иҗатында үзенең уңай чагылышын таба.

Шундый шәхесләрнең берсе – 1944 елда Кытайның Синьзян округында азатлык өчен булган халык күтәрелешендә зур фидакарьлек үрнәкләре күрсәтеп һәлак булган 28 яшьлек Хәмит Садыйк улы Мөслимов.

Аңа багышланган шигырь «Хәмит батыр» дип атала (Хак эш өчен шәһит киткән татар егетен җирле халык чынлап та шулай атап йөртә икән!).

*«Бәйсезлекне яулап алабыз!- дип,*
*Күңелләрдә янды өметләр...*
*Милләтемнең йөзек кашы булып,*
*Күтәрелде батыр егетләр!*
*Шундыйларның берсе- Хәмит батыр!-*
*Йөрәкләрдә мәңге яшәр ул...*
*Халык каһарманы-якты йолдыз,*
*Безне алга әйдәп, дәшәр гел!*

Равил Якуп улы үзенең тормыш юлында очраткан, якыннан белгән әдәбият-сәнгать әһелләренә- татар халкының мактанычы, горурлыгы булган күренекле шәхесләргә дә багышлаган шигырьләрен. Гариф Ахунов, Гөлшат Зәйнашева, Тәүфикъ Әйди, Шаһинур Мостафин, Риф Гатауллин, Фердинант Сәләхев, Мирсәет Сөнгатуллин һәм башка танылган исемнәр балкый аның шигъри юлларында. Аларның барысына да үзенең ихтирамын, тирән хөрмәтен күрсәтә алган шагыйрь.

Туган якларны сагыну, аларның гүзәллегенә соклану тойгылары Равил Якуп улының иҗатында аерым урын алып тора. Язмыш дулкынннары белән туган җиреннән аерылган татар балаларының самими-садә хисләре «Яшәтә сагындырып», «Күңелем ничек сабыр иткән?», «Йөрәгемдә тулы сагыш», «Туган яктан китмәгез!», «Балачак иле», «Әллә кайдан дәшеп тора», «Күңелем һаман шул тарафта» һәм башка шигырьләрендә тасвирланган. Мисал өчен, «Сагындыра балачагым» исемендәге шигырь:

*Ялан тәпи үткән яшьлегеңә*
*Барып кайт син, балам, барып кайт!-*

дигән сүзләр белән башлана. Аннары туган авылын ничек сагынганын автор түбәндәгечә тасвирлый:

*Урман юлларыннан чабар идем,*
*Чабыш атларына атланып.*
*Киткән юлларымнан кайтыр идем,*
*Туган авылыма, шатланып!*

«Ашкынам мин туган ягыма» исемендәге шигырьдә җирсү хисләре менә нинди юлларда ачык чагыла:

*Әйләнер идем, җәяүләп,*
*Сукмакларын, юлларын...*
*Янмас иде йөрәккәем,*
*Эчсәм чишмә суларын!*

Нәкь менә шундый сүзләр читтә яшәгән татарларның рухи халәтләрен, йөрәк сагышларын ачык күрсәтеп тора да инде.

Изге күңелле ата-аналарга багышланган шигъри юллар да Равил Гозаиров иҗатында байтак урын били. Алардан шул биниһая кадерле җаннарны чын күңелдән олылау, якты истәлекләрен сакларга омтылу хисләре ташып тора:

*Дан җырлыйк без*
*Мәңге сүнмәс мәхәббәткә,*
*Саф сөюгә һәм, әлбәттә,*
*Изге җаннар- газиз әти-әниләргә,*
*Бишек җырын көйләгән әбиләргә,*
*Милләт нигезе булган бабайларга!-*
*Без омтылган якты киләчәккә*
*Янәшә баралар бит алар да!*

Коточкыч сугыш елларында кадерле ирләрен, газиз улларын югалтып, гомерләрен ялгызлыкта үткәрергә дучар булган тол хатыннарга багышланган «Хәсрәт утларында яналар» дигән шигырьдә түбәндәге юллар бар:

*Ятим калды күпме сабыйлар,*
*Тол калдылар күпме аналар...*
*Ялгыз тартып заман арбасын,*
*Хәсрәт утларында яналар!*
*Карашлары моңсу аларның,*
*Күзләрендә хәсрәт күлләре...*
*Ничек түзә Солдат хатыны,*
*Ничек түзә Бала йөрәге!*

Р.Гозаировның ата-аналарга багышланган шигырьләренең берничәсенә көйләр дә язылган. Бу җырлар Казагыстанда яшәүче татарлар арасында танылып, бик күпләр тарафыннан яратып кабул ителде инде...

Мәхәббәт темасы, әлбәттә, шагыйрь иҗатындагы төп юнәлешләрнең берседер. Аның «Бер чибәргә гашыйк булдым», «Чакырсаң әгәр мине», «Насыйп ярым», «Ләйсән яңгыр», «Исемеңне белеп куйганнар», «Китмә, иркәм!», «Син -Кояш күк миңа» һәм башка байтак шигырьләр саф сөю хисләре белән сугарылганнар. Шушы темадагы әсәрләрнең эчтәлеген тасвирлаучы мисал итеп шагыйрьнең сөекле хәләл җефете Галия ханымга багышланган «Сусавымны бары син басасың» дигән шигырен биредә тулысынча китереп үтәсем килә:

*«Чәчкәм!»-диеп, Сиңа сөеп дәшәм,-*
*Син-чәчкәсе Тормыш гөлемнең!*
*Шул чәчкәне багып һәм кадерләп,*
*Үтте минем күпме гомерем...*
*«Чишмәм!»-диеп, Сиңа мин дәшәмен-*
*Челтер-челтер килә тавышың.*
*Сусавымны бары син басасың,*
*Сиздермисең гомер агышын!...*
*«Бәхеткәем!»-диеп, Сиңа дәшәм-*
*Томышымның гаме, тәме Син!*
*Ал таңым син минем, бөрлегәнем,*
*Бердәнберем, яшәү яме Син!*

Шушы кыска гына язмадаа Равил Якуп улы Гозаировның күпкырлы иҗатын һәм аның үзен, танылган шәхес рәтендә, тулысынча ачып булмый, әлбәттә.

Ләкин менә биредә әйтелгәннәре, шушы ачылганнары да Равил әфәнденең фидакарь хезмәтен, аның үзенчәлекле иҗатын югары бәһаларга мөмкинчелек бирә, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, Казагыстандагы татар җәмгыятьчелеге Равил Якуп улы Гозаировны милләтнең күренекле бер вәкиле дип таный. Аның исеме һәм киң кырлы эшчәнлеге «Татары в Казахстане. Энциклопедический словарь» исемендәге затлы китапка да кертелгән.

## ЭЧТӘЛЕК

Рабит Батулла.Җирсү........................................................3
Роберт Миңнуллин.Сәйяр җанлы гайярь татарыбыз......4

## МИЛЛӘТЕМ, БЕРДӘНБЕРЕМ...

Ата-бабам..........................................................................14
Бөркет баласы....................................................................17
Милләтем..........................................................................18
Җирдә...............................................................................19
Татармын..........................................................................20
Кыпчак каны......................................................................21
Борынгы юлда....................................................................22
Азатлык каһарманнары.......................................................24
Изге туфрак.......................................................................25
Давыллар дәвамы...............................................................27
Дала..................................................................................29
Атилла...............................................................................31
Алтын Урда........................................................................32
И Булгарым........................................................................33
ОлугМөхәммәт....................................................................35
Ватаным............................................................................36
Уйгур кардәш.....................................................................38
Карлы буран......................................................................40
Ата-бабам мирасы..............................................................42
Татар моңы.......................................................................44
Татар китабы.....................................................................45
Татарга дәүләт кирәкме?....................................................47
Тату микән татар?.............................................................49
Хат язам бүген..................................................................51
Ана телем.........................................................................53
Туган халкым.....................................................................54
Мин милләтче бугай...........................................................55
Замандашыма....................................................................57
Җебегәнме татар?..............................................................59
Сөембикә манарасы............................................................61
Картәткәемә хат................................................................62

Дога....................................................................................65
Мулла бабай........................................................................68
Мөселман фарызы...............................................................70
*ГАЗИЗ ХАЛКЫМ-ТАТАРЫМ...*
Милләтемә сүзем бар....................................................71
Татарның милли хисе....................................................72
Дуслыкны ныгыту чарасы..............................................73
Урыс татары....................................................................75
Татар тарихы..................................................................77
Һәйкәлләр.......................................................................79
Татар мәктәбе................................................................82
Атам-анам теле.............................................................83
Татар теле кирәкме?......................................................85
Коллык галәмәте............................................................86
Татарлык хасияте..........................................................88
Идел-Урал йорт..............................................................90

## ТУГАН-ҮСКӘН ЯКЛАРЫМ...

Шул якларга сәлам.............................................................92
Кайтыр юллар.....................................................................93
Идел-Урал яклары...............................................................95
Зимагур...............................................................................97
Тауларым.............................................................................99
Кайтам әле авылыма.........................................................100
Туган ягым........................................................................102
Сагыну...............................................................................103
Көянтә................................................................................104
Ата-бабам нигезе...............................................................105
Кайту белән китү...............................................................107
Яңгыр.................................................................................109
Күк арбасы........................................................................110
Урман аланы......................................................................111
Сукмаклар..........................................................................112
Көзге яфраклар..................................................................113
Карлар ява.........................................................................114
Ай уйный...........................................................................115
Ак каен...............................................................................116

Ак болыт....117
Яз житте....118
Гүзәл яз....119
Яз көннәре....120
Колын....121
Күбәләк....122
Урман юлында....123
Алтын туй чәчәге....125
Туган якның инеше....126

## ХӘТЕР ЯНЧЫГЫН АКТАРГАНДА...

Нигә?....127
Ай-һай дөнья....128
Гөнаһлы бәндә....129
Үтте гомер....130
Яшәү җырым....131
Ялгыз әнкәем....132
Яшел читек....133
Гомер йомгакларын сүткәндә....134
Булдым да булалмадым....136
Юллар,еллар....138
Әйрән тәме....139
Яшь гомер....140
И тәкъдирем....142
Әллә кердең микән төшемә....143
Әткәем....145
Исеңдәме, әнкәй?....147
Кайталмадым....149
Яшьлек кыска гомерле....150
Күңел яшь минем....152
Картнәемә....153
Сагыш сүзе....154
Апаларым....155
Юллар чакыра мине....156
Җаның рәнҗемәсен....157
Иске зират....159
Әткәемкарамасы....161

Күктән йолдыз атылганда....................................163
Ярый әле, туганмын....................................165
Кычкырмале, кәккүк....................................167
Үткән яшьлек....................................168
Нихәтле бар сулар агасы....................................170
Күрше карчык....................................172
Биш кашык он....................................174
Ир егет....................................176
Кораб....................................178
Кышкы урманда....................................179
Поездда....................................181
Алмагачым....................................183
Соңладым шул....................................185
Ышанам....................................186
Үткәннәрне сагынам....................................187
Урманда....................................189
Яшьлегемдә калдың....................................190
Дәрья....................................191
Шигырь....................................192
Жырлап китәсем килә....................................193
Фатихалар....................................194
Зәңгәр күгем....................................195
Бүтән мин хәзер....................................196
Юлларда....................................197
Гомер үтә диләр....................................198
Никтер килми китәсем....................................199
Әдерәсмән....................................200
Яшисе дә әле, яшисе....................................202

**ЯШЬЛЕГЕМ КАЙТАВАЗЫ...**

Мин һаман гашыйк сиңа....................................203
Татар хатынын мәдхия....................................204
Акрын гына кар ява....................................207
Синең кулларың....................................208
Йөрәктәге кояш яктысы....................................209
Адашмам бураннарда....................................210
Очрашулар....................................211

Ялгыз калмассың ....................................212
Яшьли сөйгән ярыма хат....................................213
Жаныма юк урын....................................215
Язмышым син....................................216
Хатлар....................................217
Бакчада....................................218
Искән жилләр....................................219
Гүзәл....................................220
Китәм еракларга....................................221
Соң инде....................................222
Гөлләр....................................223
Озатып калдың....................................224
Югалттым....................................225
Хатлар көттем....................................226
Була икән, диләр....................................227
Төшер исеңә....................................228
Күңелем сине эзләде....................................229
Яшьлегем кайтавазы....................................230

## КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР...

Чылбыр божрасы....................................231
Ерак буыннарга....................................232
Һәркемнең үз жыры....................................235
Комда калган эзләр....................................236
Диңгез дулкыны....................................238
Юл чатында....................................239
Туктама....................................242
Картлык хисабы....................................243
Фәрештә....................................245
Корыган елга....................................248
Югалтулар....................................250
Тәлгәш-тәлгәш карлар....................................251
Таулар белән әңгәмә....................................253
Картлар һәм яшьләр....................................256
Күзләр килә....................................259
Көт әле....................................260
Елга....................................261

Бәхетле бул бүген....263
Балакаем....264
Эзләр....265
Ниләр булыр мин киткәч....267
Һәйкәл....269
Аксак чебеш....270
Үлән....271
Килер буыннар....272
Балама нәсыйхәт....274
Васыять....275
Оныкларым....276
Утрау түгел син....277
Оныгым белән әңгәмә....279
Кечкенә оныгыма....281
Нәниемә....282
Елмай, елмай....284
Сурәтең алдында....285
Оныгыма хат....286
Юлың туры булсын....288
Атлар кешни....289
Сүзләрем сиңа кала....291

## ӘЙДӘ, ДУСТЫМ, ҖЫРЛАП ҖИБӘР...

И Тукай....292
Эй татарлар....293
Әй Казан....294
Казан каласы....295
Без кайтырбыз әле....296
Кайтам әле илләремә....297
Сагынам язларымны....298
Кайтчы, яшьлегем....299
Сылуым....300
Китәм инде....301
Иртыш моңнары....302
Бәгырем....303
Насыйп булмаган....304
Сагынам сине....305

Әнкәем....................................................................306
Изге туган җир............................................................307
Кондырышым минем...................................................308
Эх Кормаш буйлары.....................................................309
Казаклар авылы көе....................................................310
Нигә төшләремә керәсең.............................................311
Печән исе...................................................................312
Казлар китә.................................................................313
Күл буенда..................................................................314
Кара бөдрә чәчләрең..................................................315
Гармун........................................................................316
Ялгыз аккош...............................................................317
Яна йөрәк....................................................................318
Белә идең сөюемне.....................................................319
Җыр бәйрәме...............................................................320
Тәнзилә.......................................................................321
Адашып йөрмә әле......................................................322
Идел ярында...............................................................323
Сагынам......................................................................324
Җырлыйбызмы?...........................................................325
Оҗмах кайда?..............................................................326
Сайрамачы, былбыл....................................................327
Мәхәббәтем минем......................................................328
Кипкән чәчәк..............................................................329
Китмә, җаным..............................................................330
Әнкәемнең зәңгәр күзләре.........................................331
Сагынулар...................................................................332
Су сорыйлар гөлләр....................................................333
Тальян гармун.............................................................334
Карурман.....................................................................335
Соң булыр...................................................................336
Дөнья иркен, дөнья киң.............................................337
Җырлап яшик..............................................................338
Эзлим сине..................................................................339
Сызлама, йөрәк...........................................................340
Ташлама мине.............................................................341

Бергә барыйк..........342
Аерылма илеңнән..........343
Ник очрамадың икән?..........344
Агым сулар..........345
Себер татарлары..........346
Ямансу..........347
Аерылышу сагышы..........348
Яшьлегемне эзләдем..........349
Онытa алмадым..........350
Гармун уйныйм әле..........351
Барысы да истә..........352
Елмаеп бер карале..........353
Серләшербез..........354
Көләч кыз..........355
Газиз туган илкәем..........356
Агыла ла сулар..........357
Туган җирем..........358
Борылып карарга онытма..........359
Туган як жилләре..........360
Сабантуй..........361
Яшьлек язым..........362
Тәрәзәңне ачып куй..........363
Яфраклар коелганда..........364
Кайда син?..........365
Сөю..........366
Беренче мәхәббәтем..........367
Төнге йокыларым качты..........368
Чикләвек..........369
Бирче дару..........370
Карурманнарга керәм..........371
Үпкәләмә, жаным..........372
Аерылышу..........373
Әйдә, дустым, жырлап жибәр..........374
Асыл кошым..........375
Яшь чакларда гына..........376
Үпкәләмим сиңа..........377

Зәңгәр күзләр....................................................378
Әлфия....................................................379
Гомерем буе сине эзләдем....................................................380
Синең өчен....................................................381
Хуш инде, хуш....................................................382
Туган илкәем....................................................383
Көт мине, иркәм....................................................384
Ничек түзәрмен....................................................385
Һаман сокланам....................................................386
Сирень....................................................387
И җаным, и күз алмам....................................................388
Эзләмә мине....................................................389
Намаз....................................................390
Вәгаләйкем-әссәлам....................................................391

**ШАЯРЫП, КӨЛЕП КЕНӘ...**

Тәүбә иттем....................................................391
Телефон газабы....................................................393
Эмансипация....................................................394
Гаиләдә кем хуҗа?....................................................396
Дуамал эт....................................................398
Камали үгетләре....................................................400
Буа буарлык....................................................402
Артистлар....................................................403
Уены бар, чыны бар....................................................405
Җиңги бераз ялгышкан....................................................406
Чибәркәй....................................................407
Чегән кызы....................................................408
Сиңа кем кирәк тагын?....................................................409
Татар мунчасы....................................................411
Әби буламыни?....................................................412
Ирлек хикмәте....................................................413
Өйләнергә уйладым....................................................414
Автобуста....................................................415
Вокзал....................................................418
Очрашу....................................................419
Елмаясың....................................................422

***ТАҺИР БАБАЙ...***

Авылымның Хуҗа Насретдины....................................423
Аучы............................................................................424
Балыкчы........................................................................426
Ярты бакча кәлҗемә..........................................................427
Ашап кем туйган...............................................................429
Мунча...........................................................................431
Киндер күлмәк..................................................................432

**ШӘХЕСЛӘР...**

Рабит Батулла..................................................................434
Разил Вәлиев....................................................................441
Роберт Миңнуллин.............................................................454
Айдар Хәлим-публицист.....................................................461
Хатыйп Миңнегулов...........................................................465
Әхәт әйнетдин улы Нигъмәтуллин.......................................472
Равил Гозаиров шигъриятенә бер караш.................................476

ТИМЕР ЗАҺИТ

# ДӨНЬЯ БИТ УЛ

Утверждено в печать 18.07.17.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Palatino Linotype».
Печать офсетная. Условных печатных листов 30.75.
Тираж 100 экз. Заказ № 73547,
Отпечатано в ТОО «Таугуль-Принт»,
Республика Казахстан, г. Алматы, мкр.Таугуль,
ул. Центральная 3б